Безнең МИРАС

02

февраль 2016

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

17 гыйнварда башкалабыз Казанда «Туым Җондозы» – «Рождественская звезда» – 2016» дип аталган VIII Бөтенроссия конкурс-фестиваленең йомгаклау тантанасы булды. Керәшен халык җырларын башкаручы яшьләрнең әлеге фестивален Татарстанның керәшеннәр җәмгыяте, «Туганайлар» газетасы һәм «Бәрмәнчек» Дәүләт фольклор ансамбле оештырган. Бу юлы Гран-прины Башкортстанның Бакалы районыннан килгән «Сандугач» фольклор ансамбле алды.

Йолдызлар балкышы

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең мирас 12 +
2(49)
февраль 2016

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

112

6 ЧЫҢГЫЗХАН ХӘЙЛӘСЕ.
Әзһәр Мөхәммәдиев

59 КҮН ЧЕМОДАНДА САКЛАНГАН ХӘЗИНӘ.
Рабит Батулла

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 *М.Җәлил*

ТАРИХИ МИРАС

4 **Болгар. Кара пулат.** *Н.Шәйдуллина*
6 **Чыңгызхан хәйләсе.** *Ә.Мөхәммәдиев*
12 **Бөек татар әмире — Мамай.** *И.Миргалиев*
16 **Акчуриннар һәм Фатыйма Мөхтәрова.** *Н.Таиров, И.Таиров*
18 **Хәлең ничек, Бараба иле?** *Т.Галиуллин*

ТАТАР ГАМЕ

22 **Татар матбугаты һәм мирас.** *(Түгәрәк өстәл)*
31 **Замана фаҗигасе.** *С.Шәйхулла-Әнәле*

ДИНИ МИРАС

36 **Исламияттә музыка.** *М.Галләм*
39 **Галиев мәчете**

ПЕДАГОГИК МИРАС

40 **Гаилә дәресләре.** *Ф.Сөләймания*
43 **Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

44 **Байгара яланында төче кумәч.** *З.Зәйнуллин*
46 **Тарихи спектакльләр.** *Н.Фәттах*

ӘДӘБИ МИРАС

50 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Й.Баласагуни*
54 **«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе календаренда (1905) Акмулла шигырьләре.** *М.Акмулла*
56 **Балалар әдәбиятына йөз белән.** *Ш.Рәкыйпов*
59 **Күн чемоданда сакланган хәзинә.** *Р.Батулла*
60 **Бәрәкәтле мирас ядкярләре.** *Р.Мәрданов*
64 **Каракүз.** *К.Тинчурин*
78 **Тукай энциклопедиясе.** *И.Ямалтдинов*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

80 **Салих Сәйдәшев**

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
Рүзәл Мөхәммәтшин
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

СӘНГАТИ МИРАС

82 **Театр белеменең йөзек кашы.** *Н.Игъламов*
87 **Безнең замандашыбыз Камал.** *Р.Игъламов*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

94 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
97 **Могҗизаи ана телем!** *Ә.Кәримуллин*

СӘНАИГЫ НӘФИСӘ

100 **Бөек остазга иң якын рәссам.** *Р.Фәизова*

ХӘТЕР САГЫНДА

108 **«Алтын битлек»** *Г.Җәләлева*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

110 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның февраль ае.** *Л.Гобәйдуллин*

СПОРТ

112 **Башкала, спорт һәм җитәкчеләр.** *Ә.Фәйзрахманов*
115 **Без — көрәшче халык.**

ШАЯН МИРАС

116 **Көлке куа килә...**

119 **Мирасворд**
120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Февраль*

Заказ №М-175. Тираж — 1500 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 28.01.2016
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә — «Алтын Урда. Бату хан Болгар яланында ау вакытында». 2002. Киндер, майлы буяу. *Р.Шәмсетдинов рәсеме*

Муса Җәлил
(1906-1944)

***

Эчтә ялкын, көчле ташкын яшерен утлар яндыра...
Зур яра каннар сава, бер агарта, сызландыра.
Мең дәвалар файдасыздыр, мең табибта файда юк,
Бер дәва тик: серле күзле, нурлы йөз бер җан гына.

***

Мин тормышта тирән һәм ялкынлы сөя беләм. Мин табигатьне дә, кошны да, чәчәкне дә, музыканы да һәм намуслы хезмәтне дә, ялкынлы иҗатны да, тиңдәшсез илемне дә шулай ук янып, кайнарланып сөям. Бу минем эчке тирән бер сыйфатым инде.

***

Семья — безнең җәмгыятьтә <...> бергәлек җенес мөнәсәбәтләренең иң дөрес формасы булганын мин аңлыйм. Алай гына да түгел, мин семьяны хәзерге җәмгыятьтә дә идеал төстә өр-яңадан матур чәчкә атарга тиеш форма итеп саныйм.

***

Мин — бик бирелеп иҗат итәргә тиеш кеше. Мин — бөтен акылым һәм талантымны дөрес туплап, планлы, системалы эшкә җигәргә тиешле кеше, мин — бөтен вакытымны җитди рәвештә дөрес бүлеп, эшкә бирергә тиешле кеше. <...> Шагыйрьлек миннән шуны сорый.

***

«Бәндә хатадан хали түгел», ди. Бардыр. Бик күп җитешмәгән якларым бардыр. Бер кеше дә идеальный була алмый. Шагыйрь ул элекке буржуа карашындагы шикелле, нурдан яратылган «сәмави» көч түгел, ә гади кеше.

***

Яратылмаудан яратылуга караганда бәла азрак. Бәла, михнәт, җәфа күбрәк шул яратылу нигезендә туа.

***

Матур әдәбият бастыруның канәгатьләнерлек куелмавы һәм гонорарның бик түбән түләнүе — язучының иҗат эшендәге иң җитди кыенлыкларының берсе.

***

Безнең әдәбиятыбызның җитди кимчелеге — эчтәлеге һәм күләме буенча зур, мөһим әсәрләр булмау. Җитди тарихи проблемаларны һәм безнең чынбарлыкны чагылдырган тирән эчтәлекле калын романнар яисә тагын да зуррак әсәрләр язылмый.

***

Зур әсәрләр җиңел генә туа алмый.

***

Әдәби мирас мәсьәләләре җитди кайгыртучанлык, культуралы мөгамәлә күрергә һәм тирәнтен өйрәнелергә тиешләр. ■

БОЛГАР. КАРА ПУЛАТ

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.



Кара пулат — Алтын Урда чоры Болгарының (XIY гасыр) безнең көнгә кадәр иң тулы сакланган биналарыннан берсе. Ул туфтан һәм известьташтан төзелгән. Бу дүрт катлы корылманың түбәсе купол рәвешендә куелган. Аскы кат кырыйларында зур булмаган бүлмәләр урын алган. Һәрбер катның бөтен дүрт диварына тәрәзәләр уелган. Дүртенче кат сигезпочмак рәвешендә төзелгән. Икенче катның гөмбәзле, тәрәзәле залы сәнгати бизәлгән: штукатурланган диварларда гипска бизәкләр уелган, баскычларга кысалар ясалган, тәрәзәләргә рәшәткәләр куелган.

Берничә катлы бердәм архитектура комплексыннан бары тик үзәк өлеш һәм аның интерьер кисәкләре генә сакланган. Деталь билгеләре буенча (төзелеш материалын исәпкә кертмичә) Кара пулат Урта Азиянең XIY гасыр корылмаларына якын тора. Көнчыгыш төзелеш сәнгатенең сакланып калган истәлекләреннән Бакудагы Диванханә аның баштагы кыяфәтенә охшаган. Мәгълүм ки, ул ханның хөкем итү урыны булган.

XYIII гасырда монда монастырьның монахлар төзегән ыслау йорты булган. Бәлки аның исеме дә шуннан килеп чыккандыр. Кара пулатның сакланып калуы нәтиҗәсендә XIX гасырның 70 нче елларында, Казан университеты каршындагы археология, тарих һәм этнография җәмгыяте биредә борынгы әйберләр музее оештырган. Монда кабер ташлары, Болгар җимерекләрендә табылган зур архитектура детальләре җыелган. Кара пулат археологлар тарафыннан 1957 һәм 1966 елларда тикшерелгән. Пулатка реставрация 1884-1926, 1956, 1976, 1987 елларда ясалган. 2010-2011 елларда бу үзенчәлекле истәлектә — Болгарда сакланып калган бердәнбер гражданлык бинасында гидроизоляция һәм гидрофобизация, ураттма галереяның консервация кирпечен сүтү буенча киң колачлы эшләр башкарылды. ■

Редакциядән:
Н.Ханзафаровның Кара пулат тарихына кагылышлы «Кара пулат» — нинди бина?» язмасын «Ватаным Татарстан» газетасының быелгы 13 гыйнвар санынннан укый аласыз.

ЧЫҢГЫЗХАН ХӘЙЛӘСЕ

Әзһәр Мөхәммәдиев

БӨРҖАН КИРМӘНЕ

Үргәнеч каласы өстендә төнге караңгылыкны ярып, берничә урыннан төтен һәм ялкын баганалары калыкты… Шәһәр халкы аерган умарта күчедәй гүли башлады. Ара-тирә дөя акырганы, ат кешнәгәне, йә булмаса ярсынган, куркынган кеше тавышлары, кылычка-кылыч бәрелеп чәкелдәшкән корыч чыңлавы ишетелә. Кала ныгытмаларыннан беркадәр читтәрәк урнашкан һәм саман кирпечләреннән салынып, шундый ук дувал[1] белән әйләндереп алынган зур гына йорт күренә. Аның киереп ачып ташланган ишеге төбендә сабыеннан алып, карт-корысына кадәр — өй-эче белән кылычлап ташланган берничә мәет ята. Алар янына җиз тас, палас, комган ише өй җиһазлары чыгарып өелгән. Шунда ук, тузанда, кул-аяклары бәйләүле бер төркем үсмер бер-берсенә елышкан. Баскыч яркасында җәрәхәтле сул беләген бәйләп маташкан монгол нүкәре[2] утыра. Аның җирдә аунап яткан һәм урыны белән кан таплары катып калган кылычы өстендә сирәк-мирәк очкан төнге чебеннәр мыжгылдый…

Бераздан ачып калдырылган капкадан атын чаптырып килеп кергән тагын бер монгол нүкәре күренде. Ул, куллары бәйле, куе җитү чәче йөзен каплаган унөч-ундүрт яшьлек бер үсмерне сөйрәтеп килгән җиреннән атын кинәт кенә туктатты да, малайны баудан ычкындырып, башкалар янына тузанлы җиргә ыргытты. Аннары, кире борылып, атын чаптырып китеп тә барды. Җирдә аунап калган бу малай Бибарс иде…

***

Алар Иделнең уң ярында урнашкан болгар кирмәне Бөрҗаннан эшкуар әтисе белән башта өчәүгә — өч җилкәнле корабка утырып, Машаек[3] шәһәренә төштеләр. Аннары Идел тамагының сул як агынтысы булган Актүбәнең аръягында яшәгән күчмә кыпчак җәйләүләреннән, шактый бәягә төшереп, көтүе белән диярлек елкы сатып алып, Иделнең сул як яры өстеннән борын-борын заманнардан бирле яшәп килгән һәм тапталып беткән сәүдәгәрләр юлы буйлап бирегә куып китергән иделәр. Ерактан манаралары күренеп торган Машаек (борынгы Әстерхан) тирәләренә

[1] Дувал — ихата.
[2] Нүкәр — җайдак. Хәрби эшләр язусыз-сызусыз гына башкарыла алмаганга күрә, Чыңгызхан үз дәүләтендә уйгыр язуын кулланышка кертә. Моның өчен күпләгән язу таныган уйгыр хезмәткә алына. Алар белән берлектә борынгы төрки империяләреннән сакланып калган хәрби титуллар: каган, хан, төмән (ун меңлек), хәтта дәүләт системасы атамалары да көнкүрештә кулланыла башлый. Мәсәлән, Чыңгыз һәм аның уллары — бөек ханнар чорында идарә итү органы булган Алтын Урда Монголиянең башкаласы Каракорымда урнашкан була. Ә соңрак аның оныгы ханнар ханы Хубилай дәверендә Алтын Урда инде Кайпинга (Пекинга) күчерелгән, хәтта Кытай башкаласы Кайпин да төрки исеме алып, Ханбалык (Хан башкаласы) дип атала башлый.
[3] Х йөздә үк барлыкка килгән хәзерге Әстерханнан аз гына түбәндәрәк урнашкан шәһәр.

Р.Заһидуллин рәсеме

килеп җиттек дигәндә генә, әтисе елкыларга хуҗа булып маташкан бер төркем кыргый нукәрләр белән бәрелештә һәлак булды. Ә аның үзен бирегә аларның берсе китереп ташлады. Ул ни уйларга да, ни эшләргә дә белмәде. Якты һәм матур дөнья кинәттән генә тома караңгыланып, үзгәрде дә куйды...

Мангул нукәре тоткын иткән бу малайларны хезмәтчелеккә яки коллыкка сатарга җыенуларын Бибарс аңлап алган иде инде. Аның күз алдына янә әтисе килеп басты. Ул елкы куалый торган камчысы белән бер төркем кораллы дошман җайдакларына каршы берүзе чыкты, аларның бер-икесен сугып та екты, ләкин бу кыргый нукәрләрдә егетлек яки намус дигән нәрсә юк иде, күрәсең, алар аны тиз арада канга батырып ташладылар. Күңелендә баскынчылардан үч алу хисе уянды, ләкин һични кыла алмады, бәгыре катты. Ниһаять, ул авызындагы канлы тузанны төкерә-төкерә торып утырды. Артка каерып бәйләнгән кулларын янында утырган үсмернең авызына ук китереп терәде һәм «чиш», дип пышылдады. Сугыш ыгы-зыгысы булса да, нукәр аның кулларын шактый нык итеп бәйләп өлгергән иде, ләкин теге малайның тешләре үткер булдымы яки бик тырыш булып чыктымы, ул төенне чишә алды.

Бибарс оеган кулларын угалап торды, аннары бер мизгелгә генә мангул нәүкәренә күз салып алды да, ярсынган һәм ачулы яшь юлбарыстай, җирдә хуҗасыз яткан кылычка сикерде. Нүкәр абайлап өлгергәнче, ике кулы белән кылычның сабыннан тотып, бөтен көче белән тегесенең муенына китереп чапты. Ул бер якка авуга, Бибарс малайлар янына килеп, аларның кул богауларын чишәргә кереште…

Шулвакыт капкадан бер кочак затлы кием-салым күтәргән баягы нүкәр тагын атын чаптырып килеп керде. Ул чабып килгән уңайдан кочагындагы әйберләрен башка өй җиһазлары яткан өемгә ташлады да аннары кан эчендә яткан аркадашын һәм кылыч тотып катып калган Бибарсны күргәч, барысын да аңлады. Аннары аргамагыннан сикереп төште дә, ярсынып: «У-у-у, татар эте!» — дип малайга ташланды.[4] Нүкәр әлеге сүгенү сүзен Чин иленә басып кергәч, үзләре акыртып талаган бер кытайлы авызыннан ишеткән иде. Күрәсең, моның файдасы булгандыр — ул үзе дә әлеге малай кебек шул ярсып әйтелгән сүзләрне ишетеп, аптырап катып калган иде…

Юк, чабып үтермәде ул Бибарсны. Бу бик җиңел үлем булыр иде. Ул аңа сугып җибәрде һәм аны типкәли-типкәли кыйнарга кереште. Ахыр сулышына җиткән Бибарсны, изүеннән тотып сөйрәп аягына бастырды да, бар көченә тагын чигәсенә сугып җибәрде. Бибарс, очып китеп, дивар буена барып төште. Куркудан түгел, ә җан ачуыннан Бибарс бармакларын комга батырды. Ул бар вөҗүде илә нүкәрнең үзенә таба атлавын һәм аның кизәнеп, кылыч белән чабарга җыенуын… әҗәле җитүен тойды. Бөтен ихтыярын җыеп, кинәттән сикереп торды да учындагы комын нүкәрнең күзенә тондырды. Һич тә моны көтмәгән нүкәр ике кулы белән ком тулган күзләрен каплап, ярсынып үкерә башлады…

Бибарс бер мизгел эчендә кылычын эләктереп алды да, селтәнеп, нүкәрнең муенына китереп чапты…

Бу хәлгә котлары очып катып калган үсмерләргә күзе төшеп, Бибарс: «Малайлар, качыгыз!» — дип кычкырды һәм җил тизлегендә әлеге нүкәрнең иярле аты янына барып җитеп аңа сикереп менеп атланды да капкадан чыгып, үкчәләре белән атын куалап, дала ягына юл тотты…

***

…Киң далада юл-мазарның әсәре дә юк. Даланы белмәгән кеше аны өстәл кебек тип-тигез бер кыр, дип уйлый. Юк, дала ул — түбәнлекләрдән, комлы калкулыклардан торган һәм үләне көеп беткән киң бер сахра. Тик арыган һәм сусаудан хәлсезләнгән юлчы: «Бусы соңгы сырттыр, бусын менгәч, алда, шәт, берәр нәрсә, һичьюгы күләгәсе төшәрдәй агач булса да шәйләнер…» — дип өметләнеп барса, алда янә бер коры үзән күренә, аннан бераз баргач, тагын шундый ук сырт пәйда була һәм бер-берсенә охшаган мондый калкулыкларның һәм үләне корыган үзәннәрнең чиге булмаган дала икәнлегенә инана.

Чәнечкеле дөя үләне белән капланган калкулыкларга бер менеп, бер төшеп Бибарс озак чапты, ләкин аңа барыбер качып китәргә насыйп булмады. Мангул гаскәрләре борынгы Үргәнеч шәһәрен төрле яктан урап алганнар иде. Ак күбеккә баткан аргамагын куалый-куалый ул алардан качып китәргә омтылып карады, ләкин аты нык йончыган иде шул… Аны тиз арада куып җиттеләр. Куа килгән беренче нүкәр аның кулыннан тезгенен тартып алды да, атын җитәкләп, бер коры ерганак янына алып китте…

[4] Монгол тарихчысы Чулууны Далай сүзләренә караганда, бу чорда монголлар кытайлылардан ишетеп,үзләрен «да-да», ягъни «татар» дип атаганнар.

Аны куллары бәйләнеп бер-берсенә тагылган тоткыннар төркеме янына алып килделәр. Ул, атыннан төшү белән, чәнечкеле үлән үсеп утырган җиргә егылды. Мангул нүкәрләренең нәрсәдер кычкырып боерганын, икенче берәвенең ышандырырлык итеп нидер аңлатканын томанлы аңы аша тыңлап яткан Бибарс янә һушыннан язды. Калаун исемле колсатарга юк кына бәягә сатып җибәрелүен Бибарс сизмәде дә.

Шәһәрне хәтерләткән бер торлакка җитү белән Калаун, артта калган җирләрдә — мангуллар ягында табышның мул булуын исенә төшереп, колларын тиз генә сатып, кире китәргә ният кылды. Аларны, озак та тотмыйча, эш куллары кирәк булган кешеләр сатып алып та бетерделәр. Тик арбада яткан һәм кыйналып ташланган хәлсез малайны гына берәү дә сатып алырга ашыкмады. Чөнки эшкә ярамаган мондый артык тамак кол берәүгә дә хаҗәт түгел иде, күрәсең...

Калаун аны юл буенадагы сукмакка ташлап китмәкче булган иде, Тәңре ярлыкады булса кирәк, ниһаять, миһербаны килгән бер карчык яулык очына төйнәлгән берничә бакырын чишеп, артык сатулашып тормаган колсатардан малайны сатып алып калды.

***

Иделнең аръягында җәелеп яткан иксез-чиксез киң дала артында еракта күгелҗемләнеп торган офыктан кояш чыгып килгәндә, текә яр башында салынган кирмән өстендә мәшһүр Иделдән күтәрелгән аксыл томан акрынлап таралганнан-тарала башлады...

Болгар кирмәне Бөрҗан — иңгә дә, буйга да бары берничә йөз адым гына зурлыкта булып, дүрт яктан да чуер ташлардан төзелгән дивар белән әйләндереп алынган. Ә илле-алтмыш адым саен күзәтче-сакчылар өчен диварга терәп дүртпочмаклы биек таш каланчалар салынган иде.

Кояш нурлары белән бергә кирмән халкы да уянды, хәрәкәткә килде һәм кул җәемедәй тар гына урамнарда басуларга эшкә ашыккан кешеләр, намаздан кайткан мәхәллә картлары күренгәли башлады.

Әлеге кирмән сәүдә юлында урнашкан бердәнбер болгар йөзәге (застава) булып тора иде. Дөрес, көнбатышка таба бары тик бер көнлек юлда, Тын елгасының Иделгә иң якын урнашкан борылышы яры өстендә «Борҗан базары» дип аталган шундый ук икенче бер кирмән дә бар. Иделнең дә, Тын елгасының да түбән агымында, әлбәттә, болгар шәһәрләре җитәрлек, ләкин алар ерактарак урнашканнар. Ә менә Иделне аркылы кичеп, көньяк-көнчыгышка таба меңәр чакрым барсаң да бер генә авыл яки кирмән булмаган далалар җәелеп ята, диләр. Анда бары тик җирле кабиләләр генә бер җәйләүдән икенчесенә күченеп йөриләр икән...

***

Беренче әтәч кычкыру белән үк үзенә кадәр сакта торган күзәтчене алыштырып, аның урынына баскан Бибарс киң дивар өстеннән каланчага таба атлады. Җирдән аткан ук сакчыларга тимәсен өчен өске дивары ике аршын чамасы итеп күтәрелгән каланчага кергәч, сөңгесенә таянган хәлдә күзләрен ерактагы офыкка текәде.

Аның өстендә эченнән ак киндер күлмәге күренеп торган көмеш каптырмалы күн артук (мәрхүм әтисеннән калган), билендә үгез тиресеннән ясалган зур аелы киң каеш, ә мондый очракларда кизүдә торганда гына киелә торган болгар сафиянынннан тегелгән итек кунычына сөяк саплы пычак тыгылган иде. Ул әле егет булып килгән үсмер генә булса да, үзенең ышаныч казануына сөенә-сөенә, берничә атна инде Идел кичүеннән Тын елгасына бара торган сәүдә юлына са-

лынган шушы Бөрҗан кирмәнендә мәрхүм әтисе урынына чираттан сакта тора...

Менә Иделнең түбән ягыннан салмак кына аккан агымга каршы барырга омтылып, әле бер як ярга, әле икенче яккарак боргаланып, биш җилкәненә дә җил тотарга тырышып, бишән көймә күтәрелеп килә. Зурлыгына карап фикер йөрткәндә, ул Хәзәр диңгезеннән үк булса кирәк. Юк, бишән Бөрҗанга туктарга җыенмый, ул шәһри Болгарга ашыга, күрәсең. Анда, башкала буларак, шәһәр дә зуррак, әлбәттә, сәүдә дә көчлерәк. Бибарска каланчадан корабтагы кешеләр дә, бигрәк тә бертуктаусыз көймәне җил уңаена турырак тотарга тырышкан койрыкчы да ачык күренә. Бөрҗанга, гадәттә, өчәннәр генә туктый. Бишәннәр туктарга теләгән очракта, аларга кирмән урнашкан биек ярны әйләнеп узар өчен һәм тиешле урында туктар өчен корабның арканнары да һәм тартыр өчен борлаклары да булырга тиеш...

Әле яз башы гына. Барлык тирә-як: Иделнең бирге кирмән астындагы ярлары, яр буендагы куаклар, бөдрә өянкеләр, күзгә ямь биреп торучы табигать гүзәллеге — барысы да бердәй яшел-зәңгәр төскә кергән. Өстән, каланчадан караганда, урыны-урыны белән яшел куаклар арасыннан Иделгә килеп коя торган кечерәк елга борылышлары, иске агынтылар, көмештәй якты һәм түгәрәк күлләр җәелеп ята. Аларны Бибарс бик яхшы белә, чөнки бу тирәдә аның ауда да, балык та тотып йөргәне бар. Кирмән тирәсендәге уйсулыклар, чәчүле басулар, яшел тугайлар ерак-еракларга җәелеп, офыкка барып тоташалар...

Бибарсның ишетүе буенча, Идел арьягында көнчыгышка таба еракта — офык артында да шундый ук гүзәл җирләр бар икән, тик анда кирмән халкы гына яши алмый — җирле кабиләләр тынычлык бирми. Алар еш кына үзара сугышалар, йә булмаса берләшеп алып, уран салып, ара-тирә Бөрҗанга да һөҗүм итәләр. Ләкин болары инде аның, дөнья күргән кешеләр әйтүенчә, ничек кенә булмасын, кыз бирешкән, егет өйләндергән тугандаш кырагай кабиләләр. Гадәттә, алар Иделнең аръягында була торган базарга көтүе белән елкы яки башка төрле малтуар куып китереп, кирмән халкы белән сату-алу итә. Мондый вакытта кирмән халкы иркенрәк сулый...

Ләкин ач бүредәй каяндыр ерак-еoriginallyраклардан килеп чыккан, викинглар кебек бары тик үтерү яки кеше малын талау белән генә шөгыльләнгән илбасарларның, йә булмаса кыргый күчмә кабиләләрнең һөҗүм итүләре куркынычрак. Шуңа күрә, кирмән халкы басуда җир эшкәрткәндә яки елга буенда тугайда печән чапканда да һәрчак үзе белән корал алып йөри. Кирмән тормышы хәрби станны хәтерләтә. Кырда эш кайнап торган чакларда да халык бер күзен һич тә каланчадан алмый: анда ягылган ут яки төтен баганасы — шомлы ишарә күренү белән коралына ябыша һәм кирмәнгә ашыга.

...Кояш кайнар кызыл шар булып күтәрелгәннән күтәрелә бара. Көн тагын эссе булырга охшый. Бибарс игътибар белән Иделнең түбән агышындагы офыкны күзәтә. Чөнки анда нәрсәдер күренгән кебек тоела. Үткен күзләре белән ул озак кына текәлеп карап торды. Үсмер күңеле шан-шөһрәт тели иде. Әгәр дә алай-болай нindidер ят кешеләр пәйда булса, аларны башка каланчаларда торган сакчылардан да алдан күреп алып, кирмән әмиренә тизрәк хәбәр итәсе килә иде аның.

Ерактагы ноктала хәрәкәтләнәләр кебек һәм аларның кешеләр булуы бик ихтимал! Кирмәнгә таба юл тоталар, ләкин һөҗүм итүчеләр түгел, ә нindidер җәяүле халык төркеме булса кирәк. Дөрес, юлаучылар кирмәнгә көн саен диярлек килеп тора, ләкин, барыбер, Бибарс тиз арада барып, бу турыда хәбәр салырга булды...

Ерак илләрдән килгән һәм кирмән аша узучы сәүдә кәрваннары, ә кайчак

бер-берсенә аркан белән тагылган колларны әйдәкләгән колсатучылар бирeдән үтеп-сүтеп тора. Алар, гадәттә, Тын елгасы буенда Бибарс басып торган Бөрҗан кирмәненнән бер көнлек юлда урнашкан икенче бер кирмәнгә — Бөрҗан-базарга юл тоталар. Аннан колларны Румга яки Византиягә илтеп саталар, ә тегеләре исә һич кенә дә үзләре эшләргә яратмый, сугышып, шуның хисабына акча табып, коллар сатып алалар да, барлык эшләрен колларга гына эшләтәләр булса кирәк…

Кирмән халкы сөйләве буенча, табыш артыннан болгар сәүдәгәрләре ерак-ерак җирләргә — төньякта урнашкан Бисув, ягъни «Бөек су» дигән Боз океанына кадәр барып җитәләр икән. Анда кышын бертуктаусыз төн тора, ә җәй көне кырык көн буенча кояш бер генә булса да батмый — гел көн тора икән. Сәүдәгәрләр исә бозлавык җирләргә җиткәч, ат тояклары тайганга күрә, чаналарына этләрен җигеп китәләр икән…

Шул Бисув буенда ниндидер бер генә күзле кыргый һәм зур гәүдәле кешеләр — алыплар да яши, имеш… Шуңа күрә болгар сәүдәгәрләре үзләренең сатарга дип алып килгән тауарларын боз өстендә генә калдырып китәләр. Икенче көнне килсәләр, үзләре калдырган тукыма, тоз, савыт-саба, пычак, йөзек-беләзек, башка төрле бизәнү әйберләре өеме урынында төрле җәнлек тиреләре һәм су үгезе — морж тешләреннән торган өемнәр күрәләр һәм шуңа риза булсалар, алып китәләр, ә риза булмасалар, тагын нәрсә дә булса өстәп, бер чама вакытка китеп торалар икән…

Соңгы көннәрдә исә бу Бисув — Бөек боз диңгезе буенда яшәгән кыргый халыклар турындагы дулкынландыргыч хәбәрләр дә әһәмиятен беркадәр югалттыюгалтуын. Бөрҗанның әмире һәм башка идарә даирәләре дә килүче-китүчеләрне игътибар белән күзәтеп торуны заруррак күрә башлады. Чөнки Үргәнечтән килгән сәүдәгәрләр еракта, көнчыгышта — далалар һәм ялан-япан артында ниндидер дәһшәтле һәм явыз мангул дигән кабиләләр берләшеп, «уран» салып, Үргәнечне алганнар һәм Иделгә таба юл тоталар икән, дип кирмән халкына шом салды.

Хәер, мангул нүкәрләрен һәм аларның явызлыгын Бибарс үз күзләре белән күрде һәм үз башыннан кичерде. Ләкин үзенең күргәннәрен, ничек итеп аны бер ялгыз әбинең сатып алуы, кол булып әбигә тугрылыклы хезмәт итүе һәм ул чирләп вафат булганнан соң, ничек итеп сәүдәгәрләргә ялланып бик авырлык белән генә кире әйләнеп кайта алуын, кемгә генә сөйләп-сөйләп караса да, бөтен тирәнлеге белән аңлаучы булмады. Кеше башыннан кичкән авыр михнәтне аңлар өчен аны үз башыңнан кичерү кирәк иде, күрәсең…

Шуңа күрә әнисе аңа: «Улым, кеше ышанмас нәрсәне беркемгә дә сөйләмә, йә акылдан язган икән бу диярләр үзеңне», — диде. Бибарс сул күзендәге акны күрсәтеп: «Ә бу нәрсә соң, әни?!» — дип сорады. Әнисе аны кочаклап алып: «Улым, мин синең һәр сүзеңә ышанам. Моңа әтиеңнең һәлак булуы да дәлил. Мин башкалар турында әйтәм, кеше үз күзләре белән күрмичә, үз башына төшмичә, кеше кайгысын аңлый алмый, кеше сөйләгәнгә ышанып бетми… — диде.

Дәвамы бар ■

БӨЕК ТАТАР ӘМИРЕ – МАМАЙ

Илнур Миргалиев
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге җитәкчесе

Ханны тәхеткә утырту. 1330 нчы еллар

Татарда «Мамай заманыннан калган» дигән гыйбарә бар. Димәк, бабаларыбыз бу бөек шәхесне онытмаган.

Тарихи әдәбиятта әмир Мамай турында күп язылган. Билгеле, күпләр аны мыскыл итеп тасвирлаган. Бигрәк тә Куликово аланындагы сугышта аны «көчсез» шәхес итеп күрсәтүне максат итеп куйганнар.

Мамайның урта гасырлар тарихында тирән эз калдыруында шөбһә юк. Бу бөек шәхес халкына, иленә хезмәт итә, аны дошманнардан бар көч-куәте белән саклый.

Әмир Мамай, чыңгызлылар нәселеннән булмаса да, дивандагы бөек дүрт әмирнең берсе, бәкләр бәге, ягъни сугыш вакытында бөтен татар гаскәренең башлыгы булган. Алтын Урдада бәкләр бәге вәзирдән дә өстен саналып, ханга иң якын әмир булган. Шуның өстенә **Мамай** әмир Бирдебәк ханның кызына өйләнгән. Шулай ук Мамай Алтын Урданың Кавказ, Кырымнан алып бөтен көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш олысларын саклау вазифасын да башкарган.

Мәгълүм ки, Алтын Урдада XIV гасырның 60 нчы елларында фетнә-чуалышлар башлана. Бу вакытта Алтын Урданың үзара көрәшүче ике «ханлыкка» бүленүендә Мамайның да роле зур була.

Бирдебәк ханнан соң **Көлнә**, **Нәүрүз** һәм **Хызыр** ханнар идарә итә. Бу ханнарны Алтын Урдада кабул итәләр. Алар исеменнән Хәрәзмдә, Сарайда, Азак һәм Гөлстанда акча сугыла. Әмир Мамай да бу ханнарның өчесенә дә буйсына, итагать итә.

1361 елда Хызыр хан үтерелгәннән соң гына, тәхет өчен барган ыгы-зыгылар сәбәпле, әмир Мамай эчке сәясәткә кысылырга мәҗбүр була.

Сарайдагы татар аксөякләре арасында бердәмлек булмый. Үз араларыннан сайланган Көлнә белән Нәүрүзне үтерәләр. Тәхеттә көчле хан күрергә теләүчеләр Күк Урда идарәчеләрен ханлыкка чакыра, әмма Сарай әмирләренең бер өлеше бу ханнарга буйсынырга теләми. Шул ук вакытта Алтын Урданың Ак Урда олысында да, башкалада да көчле хан булырдый чыңгызлы табылмый.

1361 елда Хызыр хан үтерелә һәм чуалышлар башлана. Ханнар тәхеттә озак утырмый: йә үтерелә, йә куып җибәрелә. Олыс әмирләре дә Сарайдагы ханнарга буйсынмый. Алтын Урданың Хәрәзм олысы акчаларына фәкать ислам символикасын гына баса башлыйлар. Сарай әмирләре чуалышларда актив роль уйный. Тәхет өчен Күк Урда һәм шәйбанилар олысындагы Җуҗи (Җучи) нәселеннән килгән огланнар көрәш башлап җибәрә. Ак Урда олысында Җуҗи нәселеннән көчле шәхесләр булмау сәбәпле әмирләр Мамай әтрафында берләшә.

Хызыр хан үтерелгәннән соң бик кыска гына вакыт **Тимер Хуҗа** хан булып тора. Урыс елъязмачылары: «Тимер Хуҗаның ханлыгының җиденче көнендә төмән башлыгы Мамай гыйсъян итте», — дип язып калдырган. Сәбәбе — Тимер Хуҗаның Хызыр ханны үтереп, гаделсезлек белән тәхеткә утыруы. Тимер Хуҗадан соң **Урда Мәлик** хан була, Мамай аңа итагать итә. Әмма **Урда Мәлик** тә тәхеттә озак утыра алмый. Аның урынына үзен мәрхүм **Җанибәк хан**ның улы дип игълан иткән **Килдебәк** утыра. Мамай Килдебәк ханны да кабул итә. Соңрак Сарай әмирләре Килдебәккә каршы көрәшен башлап җибәрә һәм аны башкаладан куалар. Килдебәк Азак шәһәренә кача.

Урыс елъязмачылары: «Сарай әмирләре **Мурат**ны хан итеп игълан иттеләр», — дип яза. Мурат хан, 1362 елның җәендә, дошманының гаскәрен тар-мар китереп, Килдебәкнең үзен үтерүгә ирешә. Әмир Мамай бу сугышларга катнашмый, әмма бераздан

Мурат ханга буйсынмый башлый. Чөнки Күк Урдадан килгән ханнарга буйсынырга теләмәгән әмирләргә каршы Мурат ханның репрессив сәясәте Мамайга да куркыныч тудыра. Ул үзенең олысында **Мөхәммәт Үзбәк** ханның нәселенән **Абдулла**ны хан итеп игълан итә.

Мамай гаскәрен җыеп Сарай шәһәренә юнәлә. 1362 елда Сарайдан Муратны куып чыгара һәм Абдулланы хан буларак бөтен илгә игълан итә. Әмма Абдуллага да Сарайда озак утырырга туры килми һәм ул, башкаланы калдырып, кире Мамай олысына китә.

Мамай берничә тапкыр Сарайны кулга төшерә, әмма, озак кулында тота алмый. Сәбәп нидә? Юкса, Ак Урда олысын тулысынча контрольдә тота. Урыс кенәзлекләре Мамай урдасындагы ханнарга буйсынып тора. Мамайга каршы көрәшүче Күк Урдадан килгән огланнарның да бит гаскәре зур булмый.

Безнең фикеребезчә, сәбәп Мамайның гаскәриләре азлыгында яисә аның начар гаскәр башлыгы булуында түгел. Мамай татар дәүләтенең чикләрен дә сакларга тиеш булган. Моңа өстәп Ак Урданы да идарә итү, урыс олысын һәм Кырымдагы итальян колонияләрен дә контрольда тотуын онытмыйк. Ак Урданың чикләре Кавказ, Кара диңгез һәм Көнбатышта Маҗарстан, Польша һәм Литва белән чиктәш була. Нәкъ менә көнбатыштагы христиан дәүләтләре, Алтын Урдада чуалышлар башлангач, татарларга каршы золым, басып алу сәясәте үткәрә башлый. Бигрәк тә урманда яшәүче валаш-молдован кабиләләре вәхшилекләре белән аерылып торган. Мамай аларга каршы аяусыз көрәш алып бара.

1362-1363 елларда Литва кенәзе Ольгерд Киевны ала һәм Подолиядә өч татар әмиренең гаскәрен тар-мар итә. Берничә ел каты көрәштән соң, татарларны Днестр һәм Прут елгалары буеннан да кысрыклап чыгаралар. Татарлар күп сугышлар белән бары тик Дунай елгасының түбәнге өлешләрен генә саклап кала ала. Литвалылар һәм молдованнар басып алынган җирләрдә татарларны кырып бетерә, чәчәк атып утыручы татар шәһәрләре урынында җимерек харәбәләр генә кала. Бүгенге көндә ул җирләрдә татар исемен йөрткән берничә шәһәр һәм Добруҗада кайбер татар авыллары гына сакланып калган.

Мамай, тәхет өчен көрәштә көндәшләр күп булганлыктан, үз олысын ныгытырга керешә. Бөтен Ак Урда әмирләре аңа буйсына. Аларны берләштерер өчен Мамай башта Абдулланы хан итеп тота, ә соңыннан **Мөхәммәт** исемле огланны хан игълан итә. Мөхәммәт ханнан соң, Мамай беркемне дә хан итеп күтәрми, үзенең хатыны (Бирдебәк ханның кызы) **Тулунбәк ханым** исеменнән идарә итә башлый.

Бу сәяси үзгәрешләрнең сәбәпләренә чыганаклар ачыклык бирми. Аның сәбәбе, әлбәттә, Ак Урдада көчле Җуҗи нәселе калмавына бәйле. Бирдебәк ханнан соң Батый хан нәселе бетә, ә нинди дер Мөхәммәт Үзбәк ханга, йә Җанибәк ханга кардәшлектә булган огланнар тәхеткә кабул ителми. Мамайга Алтын Урданы берләштереп булмаса да, Ак Урданы таркатмаска кирәк була. Әгәр дә Ак Урда таркалса, көнбатыштагы дошманнар татарларны тәмам басып алырга тырышачак.

Алда язганыбызча, Мамай Күк Урдадан килгән беренче ханнарны кабул итә, әмма соңгыларының үзара көрәше һәм Ак Урда әмирләре тарафыннан кабул ителмәүләре аны эчке сәясәткә катнашырга мәҗбүр итә. Әмма ул куйган Абдулла белән Мөхәммәтне Сарай әмирләре дә, Күк Урда һәм Шәйбани олысларының әмирләре дә кабул итми. Ихтимал, Ак Урда халкы да ул ханнарны кабул итеп бетермәгәндер. Шунлыктан Мамай Сарай шәһәре өчен

көрәшне 1376 елдан соң тулысынча туктата. Ә Ак Урдада, элеке ханнарның абруена таянып, Бирдебәк ханның кызы исеменнән идарә итә башлый.

1374 елда **Хаҗи Чәркәс** Мамайны җиңә һәм Сарайдан куып чыгара. Моннан соң Мамай тулысы белән урыс олысы мәсьәләләре белән шөгыльләнә башлый. Эш шунда ки, Мамай Хаҗи Чәркәстән җиңелгәннән соң, урыс кенәзләре әмирнең ханнарына буйсынмаска тырыша. Мамай, үз чиратында, урыс олысында башбаштаклыкларга юл куймаска кулыннан килгәнне эшли.

Алтын Урданың гаскәр башлыгы.
М.В.Горелик реконструкциясе

Баскаклык институты бетерелгәч, Мөхәммәт Үзбәк хан заманыннан башлап, татарлар хан олысы булып саналган Мәскәү кенәзлеген алга чыгара башлыйлар. Бөек кенәзләр арасыннан Мәскәү кенәзенә «Урыс олысының бөек кенәзе» дигән ярлыкны еш бирәләр. Шуның өчен Мәскәү кенәзенә татар ханының легитим булуы бик мөһим булган, ә Мамайның ханнары Урдада яши, Урдада акча суга.

Бу вакытта, татар аксөякләре арасында яңа идеология ныклап формалаша. Илне бер йодрыкка тупларга, башбаштаклыкны, фетнәләрне туктатырга, тәхеткә Җуҗи нәселеннән килгән көчле кешене утыртырга кирәк, дигән фикер үзара көрәшүче татар оглан-әмирләрен дә берләштерә башлый. Бу вакытта Алтын Урдада Җуҗи династиясенә караган **Тукай-Тимер** һәм **Шәйбани** нәселләре иң алдынгы вә көчле саналган. Сарай әмирләре дә бу нәселләрне яклый. Берләшү фикере башка татар олысларында, бигрәк тә татар шәһәрләрендә тамыр җибәрә һәм урыс олысына да нык тәэсир итә.

Туктамыш 1380 елда бөтен Алтын Урданы берләштерүгә ирешә. Мамайның гаскәрләре дә сугышмыйча Туктамыш хан ягына чыга. Мамай үзе үтерелсә дә, аның улы Мансур Туктамыш ханның әмирләре арасында йөри. Соңыннан Ак Урдада да Мамай токымы бөек татар аксөякләре арасында яшәвен дәвам итә.

Әлбәттә, Мамай лидер була. Ак Урда лидеры. Шуның өчен ул көчле һәм легитим лидер чыккач яшәмәскә тиеш була. Куркыныч, әмма, гадел канун. Шәхесләр милләтенә, диненә, Ватанына, халык кабул иткән лидерга үзләрен корбан иткәндә генә — дәүләт бөек һәм көчле! Бу тәгълиматны бабаларыбыз яхшы аңлаган. Бөек әмир Мамай да моны яхшы белгән. ■

АКЧУРИННАР ҺӘМ ФАТЫЙМА МӨХТӘРОВА

Наил Таиров, Илһам Таиров

Фатыйма (Фатма) Саттар кызы Мөхтәрова (1893-1972) 1914-1917 елларда Мәскәүдә С.И.Зиминның мәшһүр опера театры солисты була, хәтта бөек җырчы Федор Шаляпин белән дә бер сәхнәдә җырлый. Опера җырчысы үз заманында Россиядә генә түгел, ә чит илләрдә дә Кармен партиясен иң оста башкаручы булган.

Фатыйма, С.И.Зиминның опера театры сәхнәсеннән кала, Баку, Свердловск, Харьков, Мәскәү һәм башка шәһәрләрдә дә җырлый. Соңрак ул Грузия ССРның атказанган артисты һәм Азәрбайҗан ССРның халык артисты буларак танылa. Шунысын да искәртик: мәшһүр җырчының әтисе фарсы (кайбер мәгълүматлар буенча азәрбайҗан), ә әнисе Сара Хәсән кызы — татар милләтеннән.

Җырчының танылган татар эшкуарлары Акчуриннар гаиләсе белән элемтәсе яхшы булган. Эре фабрикант һәм юмарт химаяче Хәсән Акчурин үзе исән вакытта Фатыйма Мөхтәровага ярдәм иткән. Соңрак ул хатыны белән Мәскәүдә җырчының концертларын тамаша кыла, аның киләчәгенә зур өмет баглый.

Атаклы хәйрияче 1916 елда вафат булганнан соң, Фатыйма аның хатыны Зөһрә Батыргәрәй кызы белән даими аралаша. Зөһрәгә зур өйдән бер бүлмә дә бирәләр. Совет власте елларында җырчы Мәскәүдә аның йортында тукталa. Гастрольләре вакытында да еш кына шунда яши.

Шунысын әйтергә кирәк: Фатыйманың атаклы фабрикантлар белән мөнәсәбәте Хәсән һәм аның хатыны белән генә чикләнми. Безнең ачыклавыбызча, Исмәгыйль Курамша улы Акчуринның кызлары да җырчыны яхшы белгән. Аның гаилә альбомында Зөләйха, Фатыйма, Мәрьям Акчуриналарның танылган опера җырчысы Фатыйма Мөхтәрова белән

Фатыйма Мөхтәрова һәм Зөләйха, Фатыйма, Мәрьям Акчуриналар. 1910 нчы еллар

төшкән фотосурәте бар. Фото 1910 елларга нисбәтле. Җырчының кызлар белән фотога төшкән урыны Сембер каласы яки Акчуриннар биләмәсе — Сөнгәләй өязенең Зөябаш авылы булырга мөмкин.

Акчуриннарның гаилә архивында Фатыйманың үз фотосы да сакланып калган. Бу рәсем дә атаклы фабрикантларның җырчы белән дустанә мөнәсәбәттә булганлыгын дәлилли. Фоторәсемнең алдына «Ф.Мөхтәрова» дигән язу да җырчының үз кулы белән язылгандыр, мөгаен.

Исмәгыйльнең кызы, Сембер кызлар гимназиясен тәмамлаган зыялы туташ — Зөләйха турында аерым әйтергә кирәк. Туганы М.Я.Акчурин сөйләвенә караганда, Зөләйха, 1917 елгы революция сәбәпле, югары уку йортын тәмамлый алмый. Әмма музыка белән шөгыльләнүен Урта Азиядә яшәгәндә дә дәвам итә. Аның еш кына рояльдә уйнап утыруын күргәннәр. Әмма Зөләйха рояльне Бөек Ватан сугышы чорында матди кыенлыклар сәбәпле сатып җибәрергә мәҗбүр була. Ташкентта Зөләйха Акчуринаның Варвара исемле педагогтан музыка дәресләре алуы да мәгълүм.

Акчуриннар нәселеннән булган кызларның музыкага мөкиббән икәнлеген тагын бер чыганак дәлилли. Бу гаиләдәге грампластинкалар безнең көнгә кадәр сакланган. Аларга рус классик музыкасы яздырылган. Кызганыч, пластинкалар арасында татар көйләре юк.

Акчуриннарның бөек опера җырчысы, милләттәшебез Фатыйма Мөхтәрова белән мөнәсәбәтен дәлилләүче чыганаклар менә шулар. Югарыда сөйләнгәннәрдән чыгып, җырчының башка Акчуриннар белән дә таныш булганлыгы турында гөман кылырга була. Бу, беренче нәүбәттә, Ибраһим Курамша улы Акчурин, аның кызлары һәм улларына да кагыла. Чөнки ике гаилә (Исмәгыйль һәм Ибраһим Курамша угыллары) дус-тату яшәгән. Шуннан чыгып фикер йөрткәндә, Ибраһим гаиләсенең дә Фатыйма белән дуслык мөнәсәбәтендә булганлыгы бернинди шик уятмый. ■

ХӘЛЕҢ НИЧЕК, БАРАБА ИЛЕ?

Тәлгат Галиуллин

Кемнәр соң алар бараба татарлары? Кай тирәләрдә яшиләр? Үткәннәре, мәдәни мирасы, тел үзенчәлекләре өйрәнелгәнме? Биниһая күп кавемнең гореф-гадәтен, мәхәббәт-нәфрәтен үзенә сеңдереп, бер милләт булып дөньяга танылган һәм таралган татар халкының «канында» барабалыларның «тамчысы» бармы? Казан федераль университеты 2013 елның ахырында нәшер иткән «Барабинские татары. Страницы духовной культуры» (665 б.) китабының авторлары нәкъ шул сорауларга җавап эзләп ерак юлга сәфәр чыккан. Көнбатыш Себер киңлекләрендә, Иртыш, Обь, Том кебек мул сулы елга буйларында, сазлык, күл эчендәге утрауларда, урман аланнарында үз көннәрен үзләре күреп яшәгән кавемнең тарихын, телен, гореф-гадәтләрен кәгазьгә теркәп калдыру шөгыленә фәнгә ихластан бирелгән фанатиклар гына алына ала. Кемнәр соң бу фидакярләр?

Галимнәр коллективының җитәкчесе — филология фәннәре докторы, КФУ профессоры, күренекле тел галиме, диалектолог **Фәрит Юсупов**. Икенче автор — **Флера Сәйфуллина** — КФУның татар әдәбияты кафедрасы мөдире. Элегрәк Тубыл (Тобол) пединститутында татар әдәбияты кафедрасын җитәкләгән бу ханымга «Бараба татарлары...» китабын төзегәндә, бигрәк тә тел-лөгать үзенчәлекләрен саклап транскрипцияләгәндә, текстларны русчага тәрҗемә иткәндә җирле халык белән аралашу тәҗрибәсе файдалы булгандыр, дип уйлыйм.

Фәрит абыйлары Себергә «эшлекле сәфәр» белән чыкканда, фамилияләре китапның затлы тышлыгында урын алган **Олег Хисамов** белән **Илһам Гомәров**ны үзеннән калдырмый. Нәзберек зәвыклы Ф.Юсупов юк-бар кешеләрне үз тирәсендә йөртмәс, заманча әйтсәк, компаньонга алмас дип, ТӘһСИ директоры К.М.Миңнуллин егетләрнең «авызларына чәчәк балы» каптыра — беренчесен үзенә фәнни эшләр буенча урынбасар итеп чакыра. И.Гомәровны гыйльми сәркатип мөнбәренә утыртта (хәзер Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире). Яшь галимнәргә теләк шул гына: таләпчән Фәрит абыйлары олы фән юлына алып кергәнне онытмасыннар...

Алдыбыздагы китап битләренә таянып, кыскача гына булса да, бараба татарларының тарихына, мәдәни мирасына күз салыйк.

Хезмәт авторлары, кайбер тикшерүчеләрнең Себергә төрки кабиләләр IV гасырда гына күчеп килгән, дигән фаразларын кире кагып, яңа табылган чыганакларга таянып, дөнья бишеген дер селкеткән, иң борынгы бабаларыбыз һуннарның Бараба һәм Тубыл тирәсенә 55, 93, 155 елларда ук килеп, бер өлешенең шунда урнашып калуын дәлилли.

Көнбатыш Себердә VI гасырда Бөек Төрк каганаты, соңрак Уйгыр (VIII), Кыргыз (IX), Кыпчак һәм Кимәк (IX-X) каганатлары оешу да ул якларда төркиләрнең тамырлары борынгыдан килүгә дәлил була.

Төрки, өлешчә фин-угор кабиләләренең тел, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләрен, йола-гадәтләрен сеңдереп I-II йөзләрдә үк формалашкан бараба татарлары иксез-чиксез киңлекләрдә ярым күчмә тормыш алып барып, мал үрчетеп, шул ук вакытта иген игеп, агач, тимер эшкәртү һөнәрләрен дә үзләштереп, тыныч кына яшәп яткан. Бохара шәехләре белән казан татарлары аларның күңеленә ислам нурын иңдергәнче, үзләре ясаган курчакларга табынып, мәҗүсилек чорын кичергән. Һәртөрле им-томнары, барабан кагулары белән шаманнар XX гасыр уртасына чаклы халыкны «агарткан». Дөрес, ислам динен кабул иткәч, барабалылар татар дөньясының бер өлеше булып киткән.

Күрше, бигрәк тә төрки кабиләләр белән уртак рухи катлам сакланган. Алтай, якут, хакас кебек кавемнәр һәм татарлар арасында киң таралган «Мижик Алып», «Кадыш Мәргән», «Кузы Көрпәч», «Цонтай Мәргән» кебек героик дастаннар, шулай ук иң тулы нөсхәсе Себердә язып алынган «Идегәй» дастаны да бараба татарларын гомуми мәдәни агымга алып чыга.

Казан, мишәр, керәшен татарлары, башкортлар шикелле үк, барабалылар да шатлык-кайгыларын, киләчәккә өмет-хыялларын, күңел ярсуын «Сәҗидә», «Агыйделкәй», «Ах, җанашым, Мәрфуга», «Әбәйлә, алмам», «Тәф(п)тиләү», «Юлбикә» кебек уртак җырларга салган.

Тел үзенчәлекләре (күбрәк, фонетик) буенча бараба татарларының бәетләре, җырлары беркадәр аерылып торса да, сурәтләү чаралары, ритм, кафия, кабатлаулар җәһәтеннән жанрларның кануни таләпләрен үти.

Барабалылар арасыннан исеме, язмышы риваятьләрдә сакланган, мәхәббәт шигырьләре безнең көннәргә килеп җиткән Айтүкә (Әлмөхәммәт) тәхәллүсле чәчән, җырчы-шагыйрь үсеп чыккан. Аның тормыш юлы шактый гыйбрәтле.

Егет, авылның бай малаена ярәшелгән иң чибәр кызы Фатыймага (Батышка) гашыйк була, кыз да аны ярата. Рәсми никахка рөхсәт булмагач, яшьләр качып китеп, Иртыш буенда чокыр казып, шунда яши башлый. Сөйгәнен ачы җилләр бимазаламасын дип, Айтүкә тирә-юньгә ак каеннар утырта, көндезләрен казакъ баеның көтүен көтә. Әмма яшьләрне табып, авылга алып кайталар һәм Айтүкәне байлар җәзаларга җыена.

Язмыштан узмыш юк, дип күрәчәгенә

ризалашкан Айтүкә, үлеме алдыннан үз җырларын башкаруга рөхсәт сорый. Мәгъшукасына багышланган, тирән кичерешле, лирик аһәңле, моңлы тавыш белән башкарылган җырлар тыңлаучыларны тетрәндерә һәм халык шагыйрьне җәзалауга юл куймый. Иҗат кешесенә яшәргә ирек бирмиләр, сөйгәне белән аеру гына җитмәгән, ике тапкыр төрмәгә утырталар. Ул аннан бик картайгач кына иреккә чыга. Фатыймасы аны эзләп «тапканда», ул инде өч ел элек фани дөньяны ташлап киткән була. Айтүкәнең халык ирекe, азатлык турындагы шигырьләре, мәхәббәт җырлары халык телендә, күңелендә яшәвен дәвам итә.

Халык мәнфәгатьләре турында онытып, үз кысыр хәсрәтләре белән генә яшәгән бәндәләр Себер татарлары арасында да аз булмаган. 1555 елда хакимиятне кулына төшергәч, үзен Себер ханы дип игълан иткән Ядегәр, Иван IVне Казанны алуы белән котлый һәм үзләрен рус дәүләтенә кушуны сорап мөрәҗәгать итә. Әмма үтенеч җавапсыз калдырыла. Сатлык Ядегәрдән котылу өчен сугыш 7 ел дәвам итә. Ниһаять, 1563 елда хакимияткә Чыңгыз хан нәселеннән Күчем килә. XVI гасыр уртасыннан себер татарлары башкаласы Искер төзелә. Себер ханлыгына ханты, манси, ногай, хотан, кара кыпчак кебек кабиләләр дә кушыла.

Яулап алу сәясәте белән агуланган рус патшасы хөкүмәте Күчем биләмәләрен тынычлыкта калдырмый. Строгановлар, Уралдагы биләмәләрен саклау сылтавы, чынлыкта ул яклардагы байлыкны талау, анда гомер иткән халыкны буйсындыру нияте белән, юлбасар казак атаманы Ермакны (халык телендә Ярмак) яллый. 1581 елның сентябрендә башлаган сугыш хәрәкәтләрендә ул әүвәл вогул, иштякларның авылларын талап, өйләрен яндырып, татар җирләренә бәреп керә. Шулай итеп Казан, Әстерхан ханлыклары яшәүдән туктагач, яклаучысыз калган табигать балалары — Себер халыкларының җирләрен үзләштерү башлана. Бу тарихи фаҗига бараба татарларын да әйләнеп үтми. Ядегәр белән көрәштә шактый көчен югалткан Күчем хан сугышка чын-чынлап әзерләнеп өлгерми, ушкуйникларны Тура белән Тобол елгалары кушылган җирдә очрата.

Үз илләрен, җирләрен яклап, баскакларга каршы күтәрелгән, әмма уклар, балталар белән генә коралланган Күчем нүкәрләре җиңелә. «Себер батыры» истәлеге бу орышка нәкъ шундый бәя бирә: *«Ермакның отряды мылтыклар белән коралланган булган. Мылтыклы кешеләргә коралсыз, сугышка әзерләнмәгән халыкны буйсындыру җиңел»*. Беренче каты бәрелештә җиңелсә дә, Себер «хуҗасы» бирешми, Бараба далаларында яшәүчеләрдән яңа көчләр туплап, улларын, туганнарын югалтып, сукыраеп, колаклары ишетми башлаганчы иярдән төшми, көрәшне дәвам итә. 1601 елда урыс патшасына сатылган нугайлар тарафыннан үтерелә.

Җанкыяр Ермак 1585 елның 6 августында фани дөньядан китә. Явызны ничек, ни рәвешле, кем үтерүе турында әллә ничә сөйләк сакланган. «Бараба халкы турында»гы истәлектә әйтелгәнчә, Ермак әүвәл Күчем ханда ике ел көтү көткәннән соң, үзенә җир кишәрлеге алып, баеп, Явыз Иван белән элемтәгә кереп, Күчем ханга каршы сугыш ачкан. Бер оста татар мәргәне угын Ермакның маңгаена төбәп аткан. Теге Иртышка егылып төшеп, суга батып үлгән.

Себернең байлыгына күз салган патша хөкүмәте гаскәри көчләрен, төзүчеләрен җибәрүдән туктамый. 1587 елда Күчем ханлыгының башкаласы Искер янында Тубыл шәһәренә нигез салына.

Киң далаларда, иркен сулы елга буйларында, кеш кебек иң кыйммәтле җәнлекләр белән тулы урманнарда хөр яшәгән халык, коллык белән килешмичә, кат-кат күтәрелеп караса да (1628 елгы восстание тарихта теркәлеп калган), аяусыз рәвештә бастырыла килә. Шул сугышларда себер татарларының 90%ы кырыла. Россиядә

Профессорлар Ф.Юсупов һәм Ф.Сәйфуллина китапка материал туплый

аз санлы халыкларга нисбәтән алып барылган мәкерле сәясәт сакланса, тиздән бараба татарлары да яшәп киткән халыклар исемлегенә теркәләчәк. Югалып барган кардәшләребезнең телен, үткән юлын, гореф-гадәтләрен тарихта калдыруның бердәнбер юлы — аларның авыз иҗатын, тарихларын, үзенчәлекләрен фәнни җирлектә, архив материалларына, истәлек-чыганакларга, элгәреләрнең язмаларына таянып, китап итеп бастырып калдыру.

«Бараба татарлары...» хезмәтенең сәяси, милли әһәмияте дә бар. Бер яктан, татар мәктәпләре ябылуы, матбугатның кысылуы, массакүләм мәгълүмат чараларның бер телдә генә алып барылуы сәбәпле, аз санлы ыруларның телләрен югала баруына игътибар юнәлтү булса, икенче тарафтан, Аурупа дәрәҗәсендә эшләнгән китап бер кабилә язмышын үзәккә алып, себер татарларының татар милләтенең аерылмас өлеше булуын фәнни раслый, ике төрле уйлануга урын калдырмый. Олы сәясәтнең мәкерен, йомшак җәеп катыга утыртуын аңлап җитмәгән, себер татарлары шивәсе нигезендә әлифбалар, дәреслекләр төзү турында хыялланып йөргән «акыллы башларга» да бу китапта җавап бар.

Бер укый, таныша башлагач, аерыла алмыйча, себер татарларының тыйнак, саңгырау, көйле шивәсендә туган дастаннарны, җырларны, сөйләкләрне тәкъдим иткән китапның соңгы битен япканчы, бу мәҗмуганың кем ярлыкасы белән дөнья күрүен әйтми үтү гөнаһ булыр. Бәяләмә бирүчеләре Татарстан Республикасының традицион мәдәниятне үстерү үзәге мөдире **Фәнзилә Җәүһәрова** һәм фәнни хезмәткәре **Марсель Бакиров** булса, аның фәнни мөхәррире, филология фәннәре докторы, профессор, институт директоры **Рәдиф Җамалетдинов**.

Әйдә, рәхим ит, бараба татары, үз нигъмәтләрең белән түребезгә уз!

Редакциядән: *Хөрмәтле укучыларыбыз! Журналыбызны даими укып барсагыз, хәтерлисездер: Себердә яшәүче милләттәшләребез турында (Булат Сөләйманов хакында Марсель Галиевнең «Күчем ханның оныгы» (№9, 2014), Ләбиб Леронның «Хатларда — юллар, юлларда — еллар» (№5, 2015), Рәшит Минһаҗның «Искер — изге җир» (№6, 2015), Мөнирә Сәгыйдуллинаның «Искермәгән Искер» (№10, 2015) язмалары дөнья күрде. Бу эшне алга таба да дәвам итәргә ниятлибез.*

ТАТАР МАТБУГАТЫ ҺӘМ МИРАС

Түгәрәк өстәл

Узган елның декабрендә «Безнең мирас» журналы редакциясе «Татар матбугаты һәм мирас» дигән исем астында «түгәрәк өстәл» оештырды.
Редколлегия утырышы кысасында узган әлеге эшлекле чарада Татарстанның халык шагыйре, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Мәгариф, мәдәният, фән һәм миллли мәсьәләләр комитеты рәисе **Разил Вәлиев**, Татарстанның халык депутаты, Халыклар Дуслыгы йорты директоры **Ирек Шәрипов**, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары **Сөмбел Таишева**, Татарстанның халык шагыйре, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе **Равил Фәйзуллин**, Татарстанның халык шагыйре **Зиннур Мансуров**, Казан федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры, филология фәннәре докторы **Рәдиф Җамалетдинов**, Татарстан Фәннәр Академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, профессор **Ким Миңнуллин**, Татарстан Министрлар Кабинеты карамагындагы Баш архив идарәсе җитәкчесе **Ирада Әюпова**, филология фәннәре докторы **Марсель Әхмәтҗанов**, «Безнең мирас» журналының баш редакторы **Ләбиб Лерон**, шулай ук «Татарстан» һәм «Азатлык» радиолары журналистлары **Нәсим Акмал**, **Рөстәм Исхаков**, «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре **Марат Закир**, **Рәдиф Сәгъди**, **Рүзәл Мөхәммәтша**, **Ленар Гобәйдуллин** катнашты.

Ләбиб ЛЕРОН:

— Башлыйк әле сүзне шигырьдән:

Кан кардәшем минем, туганкаем!
Милләттәшем, газиз татарым!
Татар иле — синең Ватаның ул,
Татар иле — минем Ватаным!

Минеке дә, синеке дә... Димәк...
Ул — безнеке! Барыбызныкы!
Татар иле — безнең мирас бит ул!
Безнең мирас — бары безнеке!

Әйе, безнең мирас — чит-ятларныкы түгел, бары тик — безнеке! Бүген дә сүзебез, нигездә, әлеге кыйммәтле ядкяребез — кадерле мирасыбыз хакында барыр. Журналның «Безнең мирас» исеме астында чыга башлавына да инде ел ярым вакыт үтеп китте. Кем әйтмешли, дөрес юлдан барабызмы? Мәсләгебезгә тугрымы? Без — һәрвакыт хәрәкәттә, даими эзләнүдә. Юаныч булырдай куанычларыбыз да, җитешсезлекләребез дә бардыр. Шунысы шатландыра: журналны укыйлар, абунәчеләребез бөртекләп кенә булса да артуга таба бара. Бихисап укучыларыбыз «Безнең мирас»ны туганнарына, иң якын кешеләренә бүләк итеп яздырта икән, дип ишетеп торабыз. Безнең өчен күңелле хәл, әлбәттә. Әмма ләкин сөенергә иртә әле. Барыбызны да борчыган, уңай чишелеш көткән бер мәсьәлә бар. Ул — безнең иң авырткан җиребез — тираж мәсьәләсе.

Разил ВӘЛИЕВ:

— Тираж — иң мөһим әйберләрнең берсе, әлбәттә. Хәзер шундый заман килде: бөтен товарны китереп бирәләр. Халык китереп биргәнгә ияләнде. Без дә хәзер китереп бирергә, алып барып җиткерергә өйрәнергә тиеш. Мәдәният министрлыгы китапханәләргә «Безнең мирас»ны 450 данә яздыра *(министрлык 2016 елның беренче ярты еллыгына «Безнең мирас»ны нибары 350 данә генә алдыра башлады. — **Ред.**)*. Ничек кенә булса да ТР Фән һәм мәгариф министрлыгы тармагына

Разил Вәлиев

Нәсим Акмал, Равил Фәйзуллин

Әгәр дә без милләткә рух иңдерергә җыенабыз икән, халыкның тарихы белән, мирасы белән таныштырырга телибез икән, журналларсыз бу эшне эшләп булмый.

да үтеп керәсе иде. Шуның хәтле үк китапханә Мәгариф министрлыгы системасында да бар, ә аларда мондый язылу юк. Мәгариф министрлыгының мөмкинлеге зуррак, бюджеты 39 миллиард сум. Бу суммадан ничек кенә булса да өлеш чыгарырга булыр иде. Редакторлар җыелышып барасызмы, әллә үзегез аерым гынамы, ничек тә хәлне аңлатып, 500 данәне алардан да эшләтә алсагыз, бик яхшы булыр иде.

Тагын бер эшләнмәгән эш бар, ул да булса — Бөтендөнья татар конгрессы. Мин анда бюро әгъзасы, үзем дә әйтермен. Сез әйтсәгез, тагын да яхшырак, сезне тыңлаячаклар. Без бит конгрессны оештырган вакытта аның бөтен татар милләтенә, мәгарифенә, мәдәниятенә эшләячәк хезмәтен күз алдында тоттык. Аларның Татарстаннан читтә 140лап оешмасы бар. 140 оешма һәр татар журналын берәр данә генә булса да алдырса, тиражга хәл кадәри йогынты ясар иде. Алар бит татар халкына рух иңдерергә тиешле оешмалар! Ә рухны ничек инде журналларсыз, әдәбиятсыз, сәнгатьсез иңдереп була? Болай сөйләшеп кенә булмый бит ул. Дөрес, эшкуарларны җыю, аларның эшләгән эшләре дә кирәк. Әгәр дә без милләткә рух иңдерергә җыенабыз икән, халыкның тарихы белән, мирасы белән таныштырырга телибез икән, журналларсыз бу эшне эшләп булмый. Сез татар конгерссына барып, моны алардан эшләтүне мәҗбүр итсәгез иде!

Без яшь вакытта Язучылар берлегендә бик әйбәт традиция бар иде: атаклы әдипләребезнең мирасын барлау, өйрәнү, дөньяга чыгару буенча махсус комиссия эшләде. Бүгенге көндә ул эш тукталды, әмма элекке вакытта эшләнгән эшләр, җыелган мирас бардыр. Алар кайда икән хәзер? Шуларны табып, дөньяга чыгарырга иде. Алар җыелган, халыкка күрсәтергә генә кирәк.

Кабер ташлары... Бу турыда журналыгызда язылды, әмма тагын да активрак язарга иде... Ташландык зиратлар бездә, Татарстанда шактый күп.

Зиннур Мансуров, Ирада Әюпова

Марсель Әхмәтҗанов

Авыллар бетә, авыллар үлә, зиратлар утырып кала. Зират — таш китап. Олы Мәңгәрдә «Таттелеком» оешмасының генераль директоры Лотфулла Шәфигуллин зиратны, кабер ташларын киртә белән уратып куйды. Анда XVI нчы гасырга нисбәтле ядкярләр дә бар. Андый ташлар башка районнарда да саклана. Бу зиратларны, андагы кабер ташларын өйрәнүчеләр бүген бик сирәк. Шуларны җәлеп итеп активрак эшләсәгез иде, чөнки алар югалып бара.

Бер кызыклы хәлгә тап булдым. Мин АКШка баргач, милләттәшләребез бездә борынгы китаплар бар, диде һәм Казанга 30дан артык кулъязма һәм басма китап җибәрде. XX гасыр башына караган басмаларының кайберләре Милли китапханәдә һәм университет китапханәсендә дә юк. Бу китапларның тарихы бик кызык булып чыкты. Заманында алар Казанда яки аның тирәягында күчереп язылган яки басылган. Шуннан соң мөһаҗирләр белән бу китаплар Кытайга, аннары Япониягә, Көньяк Кореяга, Төркиягә һәм хәзер менә АКШка барып эләккән. Менә шул китапларны милләттәшләребез ничек кадерләп саклаган, мәктәпләрдә шул китаплар буенча укыган. «Кичләрен кычкырып укый идек», диләр. Бу китаплар, яңадан, Җир шарын әйләнеп, Казанга кайтты. Менә шундый бик кызык тарихлы китаплар бар. Китап тарихы да журналда яктыртылсын иде.

Журнал җанланды, журналның җаны бар! Бер шаблон белән генә язылмый. Укыла... Язучыларның, әдипләрнең һәм башка шәхесләрнең истәлекләре бик кызык. Аннары күбрәк конкрет шәхесләр турында язылсын иде. Татарның күренекле бөек шәхесләре турында... Бу яшь буын өчен дә, безнең өчен дә кызыклы. Без аларның кайберләрен белеп тә бетермибез...

Рәдиф ҖАМАЛЕТДИНОВ:

— «Безнең мирас»ның үз йөзе бар, журнал белән кызыксынып торабыз. Аның һәр санын, һәр мәкаләсен укып, танышып барабыз.

Без үзебез дә «ТАТАРИКА» дип исемләнгән журнал чыгарабыз. Нигездә әлеге басманы фәнни даирә өчен бастырабыз. Ул дөньядагы барлык китапханәләргә дә таратыла. Сездәге кайбер авторларга без дә мөрәҗәгать итәбез, алар белән хезмәттәшлек алып барабыз. Ә инде «Безнең мирас»ны алга таба тагын да яхшырту, абру-

Ирек Шәрипов, Ким Миңнуллин, Рәдиф Җамалетдинов

ен күтәрүгә килгәндә, беренчедән, шәхесләр мәсьәләсенә аерым рубрика кирәк түгелме икән? Без аны үзебезнең «ТАТАРИКА»да булдырдык. Әмма «Безнең мирас»ның мөмкинлеге тагын да күбрәк, чөнки сез фән әһелләрен генә түгел, җәмәгать эшлеклеләре, язучылар, шагыйрьләр һәм башка алдынгы милләттәшләребез турында да мәкаләләр бастыра аласыз.

Әгәр дә без Татарстаннан читтә дә укучылар табарга телибез икән, миңа калса, анда яшәүче татарлар турында да аерым рубрика эшләргә була торгандыр. Журналга язылу турында сөйләгәндә, без, җитәкчеләр, институтыбыз өчен нинди кызыклы темалар бар икән, дип карыйбыз. Даирәне киңәйтергә телибез икән, журнал шул юнәлештә, аның укучыларына да кирәкле мәкаләләр бастырырга тиеш.

Кызганыч, студент халкы газета-журнал яздырырга бик ашкынып тормый. Дөрес, яшьләр укый, кызыксына, бүгенге көндә башка форматта да матбугат белән танышу мөмкинлеге бар бит. Нигездә алар шуңа өстенлек бирә. Ә укытучылар белән без алга таба да хезмәттәшлек алып барырбыз, дип өметләнәм.

Р.ВӘЛИЕВ:

— Россиянең һәр шәһәрендә диярлек татар бистәләре булган. Әмма аларны ныклап өйрәнгән кеше юк. Татарның бик күп зыялылары, әдәбият-сәнгать әһелләре шушы бистәләрдән чыккан. Алар күбесе, бәлки, авылдан килгән булгандыр, шулай да, авыл һәм шәһәр мәдәниятен бергә кушып, алар бик үзенчәлекле мохит тудырган, әмма тормыш рәвешләре башка төрле булган. Менә шушы татар бистәләре турында язарга иде, аларның тарихын күрсәтәсе иде журналда. Татарстан Фәннәр Академиясенең моңа әлегә кулы җитми, алар авыллар белән шөгыльләнә.

Л.ЛЕРОН: Без кулыбыздан кил-

гәнне эшләргә тырышабыз. Басмабыздагы язмаларның барчасы да укылырга тиеш, дип саныйбыз! Бик катлаулы язмаларны да, хәл кадәри гадиләштерергә омтылабыз. Укучыны җәлеп итү — хәзерге вакытта безнең өчен үтә мөһим эшләрнең, алмаксатларның берсе.

Ирек ШӘРИПОВ:

— Район башлыклары арасында да укый торган, татарча фикерле белгән кешеләр күп. Әмма ерак районнарыбызга язучы-журналистларыбыз барып җитә алмый. Татар җанлы хакимият башлыклары, шулай ук депутатлар да журналны үстерүгә күпмедер дәрәҗәдә өлеш кертә ала, дип уйлыйм. Актаныш укучысы журнал битләрендә Актаныш турында мәкалә күрергә тели… Менә шулай итеп, районнарга кармаклар салгаласак иде. Язардай әйберләребез бар бит!

Л.ЛЕРОН:

— Сүз дә юк, булган барлык мөмкинлекләрдән дә файдалану мәслихәт.

Ким МИҢНУЛЛИН: Дөресен әйтергә кирәк, республикада чыгып килгән бер генә журнал да шуның кадәр сандагы авторларны җәлеп итеп, аларга үз басмаларында мәкаләләр бастырырга мөмкинлек бирә аладыр, дип уйламыйм. «Безнең мирас»ның авторлары күп. Алар үзенчәлекле шәхесләр һәм, әйтергә кирәк, алар төрлесе төрле өлкәдә эшли. Берсе — тарих, берсе — тел, берсе — сәнгать… Бер генә басма да эшне шушы рәвешле алып бара алмый. Зур санда булмаган редакция хезмәткәрләре дә һәр өлкәдән хәбәрдар булырга, аларның һәр өлкә буенча белгечлеге булырга тиеш. Бу журнал өчен әйбәт, әзерләүче журналистлар өчен катлаулы. Журналның бизәлеше, дизайны буенча да институтта сөйләшкәнебез бар. Дөрес, хуплау сүзләрен әйтергә кирәк. Шул ук сайтның булуы да кызыксынуны арттыра. Мин журнал шактый гына

Халык иҗатының 25 томын басмага әзерлибез икән, ул — тулысынча затлы мирас.

үзгәреш кичерде һәм инде аның укучыларны җәлеп итәрлеге бар, дип саныйм.

Сезнең даими авторларыгыз булып торган безнең галимнәребез бар. Алар журнал эшчәнлегендә мөмкин булганча катнаша, аерым сәхифәләр алып бара. Шуңа күрә алга таба институт белән бергә эшләү мөмкинлеге бар, бездәге мәдәни байлыклар белән эш итәргә дә була. Бездә 200гә якын шәхеснең фонды бар, аларның бер өлеше тасвирланган. Бу мирасның сакланып, тәртипкә китерелеп, мирасханәдә урын алуы зур әйбер, чөнки алар якын киләчәктә эшкәртелеп бетәчәк.

Бу юнәлештә алга таба нәрсә эшләргә? Монысы бик катлаулы. Шәхси архивларны мирасханәгә алу проблемасы да бар. Кайберәүләр аны аңлап та җиткерми. Мин үзебезнең галимнәрнең дә мөнәсәбәтен бик аңлап бетермим. Ни өчен материалларны, шул ук шәхси фондыңны бөтен мөмкинлеге булган оешмага тапшырып аны мәңгеләштермәскә? Киләчәктә алар юкка чыгачак бит. Без инде үзебездә максатчан эш алып барырга тырышабыз. Бу бит инде галимнең исемен мәңгеләштерү дигән сүз. Ул аларның исеме белән теркәлә, урнаштырыла, алга таба өйрәнү мөмкинлеге туа. Һәм инде яшьрәк галимнәр аны мөмкинлек булганда фәнни әйләнешкә кертәчәк. Өйдә телне начар белгән балалар, оныклар кулында мирасны калдыруга караганда, бу юл фән өчен яхшырак. Сезнең журнал моңа игътибар итәргә тиеш.

Тираж — һәр милли басманың проблемасы. Без үзебез дә 180 битлек «Фәнни Татарстан» журналын чыгарабыз. Татар телендә фән белән кызыксынучылар бар. Шулай ук татар

телендә материал бирә алмаучылар да бар. Мирасханә белән текстология бүлегендә елына 1-2 мәртәбә чыга торган альманах та оештырырга уйлыйбыз. Чөнки зур әсәрләрне дә дөньяга чыгару проблемасы бар.

Сезнең журнал газетадан да, безнең фәнни басмалардан да аерыла, әшегез тагын да катлаулана төшә. Журналның

Татарның мирасы биниһая зур. Аны колачлап бетерү мөмкин түгел, ул күп катламлы. Якын һәм ерак чит илләрдә татар эзе бар. Андагы архивларда да без белмәгән материаллар күп.

үз урынын һәрвакыт, бертуктаусыз раслап, аны танытып торырга кирәк. Чөнки һәрбер фәнни оешманың үзенең журналы бар, тарих, археология институтлары үзләренең басмаларын чыгара.

Ярый, бүген өлкән буын галимнәребез бар. Аларда материаллар бар, алар мәкаләләр язып бирә ала. Аз гына яшьрәкләргә мөрәҗәгать итәбез икән, аларның кулларында бу дәрәҗәдәге материал юк. Тагын да яшьләргә килсәк, алар диссертацияләре һәм планлы эшләреннән тыш берни тәкъдим итә алмый. Үзебездәге журнал-китапларга план буенча эшләп утыра торган әйберләрен генә бирәләр. Сезгә кадәр аларның эшләре барып җитә алмаячак, чөнки, әйткәнемчә, аларның кулында әллә ни материал юк. Бу ситуациядән ничек итеп чыгарга? Аны инде бергәләп уйларга кирәк.

Халык иҗатының 25 томын басмага әзерлибез икән, ул — тулысынча затлы мирас. 8 томлык әдәбият тарихы эшләнеп килә. Бу да бәһасез мирас. Бәлки аларны «Безнең мирас»ка кыскача биреп булыр. Гомумән, институттагы һәр бүлекне алып карасак та, алар — мирасның бер юнәлеше.

Шулай ук районнардагы тарихчылар, мирас белән кызыксынучылар, төбәкне өйрәнүчеләр белән дә элемтә җитеп бетми. Алар янына сезнең белән бергәләп, районнарга чыгып, ниндидер семинарлар, төрле чаралар оештырып булыр иде. Чөнки төбәкне өйрәнүчеләр үз материалларын дөньяга чыгара алмый, ничек итеп басмага әзерләргә икәнлекне белми. Нинди дә булса матди мәсьәләләрне күз уңында тотып районнарга чыгабыз икән, һичшиксез, ул төбәк тарихын да өйрәнергә, аны журналда күрсәтергә кирәк.

Кыскасы, журнал үзенең йөзен, юнәлешен тапкан, рубрикалар белән бүлгәләнеше дә, дизайны да, барысы да үз урынында. Шушы юнәлешне югалтмыйча, булганны бетермичә алып бару турында һәрдаим уйланып торырга кирәк булачак, чөнки дөнья аз гына да туктап торуны кичермәячәк.

Л.ЛЕРОН:

— Безнең янибызда олпат шагыйрь, тәҗрибәле редактор утыра. Ул — Равил ага Фәйзуллин. Әйдәгез могтәбәр каләмдәшебезнең дә чыгышын тыңлыйк әле.

Равил ФӘЙЗУЛЛИН:

— Беребез дә бәхәскә кермәс, «Безнең мирас» — кирәкле журнал! Ничек менә шушы хәзинәне кешеләргә, яшь буынга ирештерергә?

Татарның әллә ни матди байлыгы сакланмаган. Рухи мирас, дибез икән, ул — безнең әдәби-мәдәни мирасыбыз. Җәмгыять шактый авыр хәлдә, авыру хәлдә. Аны дәваларга кирәк. Һәрбер авыруның да дару әчәсе, укол кадатасы килми. Укол кадасаң, авыру, яхшы, әйбәт булды әле, мин тазарып киттем әле, ди. Җәмгыятьне дә шприц белән мәҗбүри дәваламасаң, нәтиҗә юк.

Бездә басмалар шулхәтле күбәйде ки, кая барма, кая керма, кая карама — әллә нинди басмалар күрәсең. Ә эчендә җаны, иманы булган басмалар бик аз. Ә халыкка нәрсә? Аңа «Колхоз» базарына барды ни, «Вьетнам» базарына барды ни… Ул аны аермый!

Ялтырыймы, ялтырый! Затлы мирасны, чын байлыкны халыкка ирештерә алмыйбыз. Кияүгә чыга алмаган кыз шикелле. (Ул саф, матур, яхшы, әмма ул күренмәгәч, үзен күрсәтеп йөрмәгәч, аны алучы юк.)

Безнең халык укымый, димәс идем, ул нәрсәдер укый, ләкин аның күңелен бүтән нәрсәләр яулап алган. Шәхси басмалар... «Акчарлак», «Уртак түшәк», «Себерке», «Кәеф ничек?»... Ә халык барысын да ала алмый. Берне ала... Уйлый: кара, яхшы бит! Аңа шул җиткән, ул шуңа канәгать. Безнең бурыч — яхшы, затлы әйберне халыкка ирештерү, дип уйлыйм мин. Шәхси басмалар безнең укучыларны яулап алды... Әмма үзләре чабып йөреп, үзләренең акчасына моңа ирешә.

Дөрес, журнал әйбәт чыга. Чөнки анда шәп егетләр эшли: язучылар, шагыйрьләр, галимнәр...

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенә теркәлгән жрналларның санын алтмышка якын, диләр. Мин аларны үзем дә белеп бетермим. Әмма милләтебез, яшь һәм киләчәк буын өчен кирәк булган журналлар алай ук күп түгел. «Казан утлары», «Безнең мирас», «Идел», «Сөембикә» — алар кулның биш бармагына сыя. Мин үзем, шәхсән, «Безнең мирас» журналын бик кирәкле журнал, дип саныйм. Ул тагын да камилләшер, иншаллаһ...

Зиннур МАНСУРОВ:

— «Безнең мирас» журналының үз тарихы бар. Байтак еллар «Мирас» исеме белән чыкты, аннары «Чын мирас» исеме белән яңарды. Шулай да «Безнең мирас» исеме белән чыга башлагач, чын мәгънәсендә яңарыш кичерде, дип әйтәсем килә. Мин аны өйгә алдырам, һәрбер саны килгәнен түземсезлек белән көтәм. Кулга алуы рәхәт, башыннан ахырына кадәр укыйм һәм үзем өчен бик күп кызыклы мәгълүмат алам. Хәтта, бу мәгълүматлар миңа киләчәктә кирәк булачак, дип, журналны читкә алып куям. Баксаң, үземә киләчәктә кирәк булыр, дип, аның 12 санын да алып куйганмын икән. Бу чыннан да шулай... Бу нәрсәдән килә, чөнки «Безнең мирас» журналының үз мәсләге, концепциясе бар.

Безнең Татарстанда бик күп газета-журналлар чыга. Аларның байтагының, кызганыч ки, ачык, тәгаен концепциясе юк. Дөресен әйткәндә, алар мәкаләләр тупланмасы булып чыга. Монда бернинди стратегик юнәлеш юк, миллләткә хезмәт итү дигән асыл максат күренми. Менә бу җәһәттән караганда, «Безнең мирас» журналының концепциясе бар. Бу концепция бер стратегик максатка нигезләнгән, ул да булса — халкыбызның бай мирасын өйрәнү. Менә шул җәһәттән «Безнең мирас» журналы камилләшеп бара, әлбәттә, сан саен төп концепцияне үзгәртү кирәкми, әмма, шулай да ул күпмедер дәрәҗәдә яңартылып барырга тиеш. Буыннар алышына, укучыларыбызның зәвыгы үзгәреп тора. Төп концепцияне саклаган хәлдә мирас журналы үзенең рубрикалары белән яңарып барырга тиештер, дип уйлыйм мин.

Татарның мирасы биниһая зур. Аны колачлап бетерү мөмкин түгел, ул күп катламлы. Якын һәм ерак чит илләрдә татар эзе бар. Андагы архивларда да без белмәгән материаллар күп. Галим Искәндәр Гыйләҗев Германиягә барып Беренче Бөтендөнья сугышына бәйле архивны алып кайтты, яңа материаллар ачты. Бер яктан, чит ил архивына бару күп чыгым таләп итә, ләкин сирәк булса да, безнең галимнәребез чыккалап тора. Менә шуңа күрә журнал Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән дә, безнең Баш архив идарәсе белән дә, башка институтлар белән дә, галимнәр белән дә бик якын элемтәдә торырга тиеш.

Журнал яхшы мәгънәсендә чуар булып чыга. Укучы өчен шунысы бик кыйммәтле дә инде. Дөрестән дә, журналда төрле катламнар, төрле-төрле материаллар булырга тиеш.

Без язучылар белән районнарга еш йөрибез, мәктәп, авыл музейларына керәбез һәм бөтен музейда да безгә мамонт тешен күрсәтәләр. Әйтерсең мамонт теше – татарның төп экспонаты.

Минем берничә тәкъдимем бар. Урта битләрдә «Сүз һәм сурәт» рубрикасын алып барасыз. Ул бик кызыклы булды. Әмма аны яңартырга кирәк. Безнең районнарда, авылларда, мәктәпләрдә бик күп музейлар эшләп килә. Без язучылар белән районнарга еш йөрибез, мәктәп, авыл музейларына керәбез һәм бөтен музейда да безгә мамонт тешен күрсәтәләр. Әйтерсең мамонт теше – татарның төп экспонаты. Әлбәттә, бу кызыклы… Ул төбәктә мамонт яшәгән. Әмма татар милләтенә ат, кәҗә күбрәк хезмәт иткән бит! Әйтерсең мамонттан башка туган якны өйрәнү музейларында экспонат юк. Ә бит бар! Бар, җәмәгать. Район, авыл музейларында бик күп уникаль экспонатлар бар. Ә нигә аерым рубрика ачып, шундый бер экспонат турында журналда язмаска! Бу рубрика журналны районнар белән дә бәйләр иде, милләткә дә хезмәт итәр иде.

Гаилә ядкярләре була. Алар буыннан-буынга мирас булып күчеп килә. Бик кызыклы гаилә ядкярләре бар. Болар турында да, бәлки, аерым сәхифә булыр.

Балтач районында шәҗәрә бәйрәме уза. Бу бик кызык бит! Җиде буын бабаңны белү… Нигә бер бит кенә булса да мәктәп укучысы әзерләгән шәҗәрәне журналга биреп бармаска? Ул башкалар өчен дә кызыклы гына дәрес булыр иде…

Татар тарихы журналда әйбәт бирелә. Безнең милли сәнгать төрләре бар. Рәсем сәнгате, музыка, архитектура… Боларның бөтенесенең тарихы бар бит, җәмәгать! Милли төсмердәге тарихы бар. Без кайчакта әдәбиятка ныграк авышабыз. Бу инде журналны язучылар чыгаруга бәйледер. Бәлки гел-гел әдәбиятка гына авышырга ярамый да торгандыр, башка сәнгать төрләренең дә тарихына тукталырга вакыт җиткәндер.

Кыскасы, шушы рухны дәвам итәргә, ләкин, барыбер, журнал эзләнүдән, камилләшүдән туктамаска тиеш. Әз генә эзләнми башлыйсың икән, аннан нафталин исе килә башлый. Әгәр дә без укучыларыбызның игътибарын үзебезгә җәлеп итәргә телибез икән, яңаруда, эзләнүдә булырга тиешбез, дип уйлыйм мин.

Ләбиб ЛЕРОН:

– Милләтебезнең күренекле шәхесләре бүгенге утырышыбызда бик әтрафлы чыгышлар ясады. Барчасына да рәхмәт. Безнең әйтер сүзебез, минемчә, бетмәде әле. Уйлы-гамьле, тирән эчтәлекле, үтемле, фикерле язмаларга әйләндереп, ул күркәм сүзләребезне, әлбәттә, «Безнең мирас»ның алдагы саннарында һәрдаим ирештереп торырбыз, дип уйлыйм. Килгән кунакларның һәммәсенә рәхмәтемне җиткерәм. Эшегездә, гаиләгездә уңышлар, куанычлар, бәхетшатлыклар һәрчак юлдаш булсын. Исән булыйк!

***Редакциядән:** Хөрмәтле укучылар! «Түгәрәк өстәл»нең аудиоязмасы һәм фоторепортаж белән www.beznenmiras.ru сайтында танышырга мөмкин.*

Журналны алга таба ничек күрергә телисез? Анда нинди мәкаләләр укыр идегез? Тәкъдимнәрегезне сайтның «кунакханә» бүлегендә язып калдыра аласыз. Сезнең һәрбер фикер һәм тәкъдимегез безнең өчен кызыклы һәм алар, һичшиксез, игътибарсыз калмаячак. ■

1991 елда, халыкка карата кулланылган кысулар, законсызлыклар һәм баш-баштаклыклар нәтиҗәсендә гаепсезгә репрессияләнгәннәрне аклау башлангач, «Сәяси репрессия корбаннарын реабилитацияләү турында»гы федераль закон кабул ителде. Татарстанда исә республика реабилитация комиссиясе 1995 елда оештырылды.


СССР ПРОКУРАТУРАСЫ
ТАТАРСТАН АССР
ПРОКУРАТУРАСЫ
420084. Казан ш. Ленин ур. д. 14
№ 120989 13-47-89
На № ______ от ______

ПРОКУРАТУРА СССР
ПРОКУРАТУРА
ТАТАРСКОЙ АССР
420084. Казань, улица Ленина, д. 14

420004, г.Казань
ул.Горьковское шоссе,39-68
Минуллиной С.Х.

Ваше заявление прокуратурой Татарской АССР рассмотрено с проведением соответствующей проверки. Выселение Минуллина Шайхуллы Минулловича, 1898 года рождения и его семьи в 1949 году из дер.Ст.Енали Апастовского района ТАССР в Амурскую область признано прокуратурой необоснованным.

О.М.Антонов

ЗАМАНА ФАҖИГАСЕ

Сәгъдулла Шәйхулла-Әнәле

Сәяси репрессия чорында күпме кешенең нахакка гаепләнүе бүгенге көнгә кадәр төгәл билгеле түгел. Шулай да Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты Юлий Рыбаков «Россия» газетасының 2001 елгы 5 апрель санында басылган мәкаләсендә: *«1991 елда Эчке эшләр министрлыгыннан алынган рәсми мәгълүматлардан күренгәнчә, Сталин хакимлек иткән чорда сәяси репрессиягә дучар ителүчеләрнең саны 50 миллион 170 мең кеше исәпләнә»*, — дип язган иде.

Бүгенге көндә Татарстанда нахакка хөкем ителеп, аннары реабилитацияләнгән кешеләрнең саны 150 меңгә якын. Туган төбәгем Апас районыннан гына да 200дән артык алар. Туган авылым Иске Әнәледән 20ләп кеше репрессиягә дучар булган. Республика буенча репрессияләнгәннәрнең исемнәре һаман табыла, ачыклана. Димәк, бу сан арта гына бара.

Әти-әнием һәм без — балалар, туган җирне ташлап, Себергә сөргенгә китәргә мәҗбүр ителсәк тә, хәзер туган авылыма еш кайтам, кайткач, уйланам да, моңланам да. Авылда нигезебез дә юк инде. Зиратта — әби-бабаларыбызның, әниемнең (әтиемне Казанда җирләдек), сөт туганнарымның каберләре…

1941-1945 елгы сугышны һәм сугыштан соңгы еллардагы хәлләрне үз күзем белән күреп белгәнгә, алар кабат хәтерне яңарта, йөрәкне әрнетә. Колхозда көнетөне эшләгән өчен хезмәт көне генә яздылар, бер грамм да ашлык бирмиләр иде. Урып-җыю башлануга, район түрәләре ашлыкны дәүләткә тапшырта. Халык ничек яшәргә тиеш булгандыр, анысы берәүне дә кызыксындырмады. Ач балалар, карчыклар, качып-посып кына, комбайн урганнан соң калган башакны җыя иде. Чөнки авыл куштаннары, колхоз һәм авыл советы рәисләре башак җыйганны күреп калса, басудан алып кайтып кыйнады, колхоз ашлыгын урлый, дип, хөкем итү очраклары да булды. Башак кырда калып чересә-чересен, әмма кешегә генә булмасын. Дәүләткә бөтен ашлыкны тапшырганнан соң, язгы пычракта 15 чакрым ераклыктагы «Каратун» тимер юл станциясеннән чәчүлек орлыкны жилкәләренә күтәреп ташый иде авылдашларым. Орлык ташудан без — укучы балалар да читтә калмадык.

Хуҗалыкта терлек-туар, кош-корт булмаса да, дәүләткә 50 кило ит, 300 литр сөт яисә 15 кило атланмай, 200 данә йомырка, хәтта брынза ясарга сарык сөтен дә бушлай бирергә мәҗбүр иттеләр. Әгәр колхозчының бәрәңге җире 25 сутыйдан аз гына артса да, артык җиргә утыртырга рөхсәт юк иде. Шуңа бәйле бер вакыйга истә калган: төп йорт янындагы җир (йорт һәм каралтыларны да кертеп) 10 сутый гына булганлыктан, Нурулла бабайлар янындагы урыннан безгә 15 сутый җир бирделәр. Без ул җирне бәрәңге утыртырга дип, көрәк белән казыдык. Килеп үлчәделәр дә, 2 сутыйга күбрәк булган, ахрысы, ул җиргә утыртырга рөхсәт итмәделәр. Анда алабута үләне генә үсте. Нинди гаделсезлек!

Сугыштан соңгы елларда, халыкның авыр тормышына карамастан, сигезенче сыйныфтан башлап, укыган өчен акча түләттеләр, вакытында түләмәсәң, яхшы укысаң да, мәктәптән чыгаралар иде. Акча түләргә мөмкинлеге булмаган байтак кына балалар укуларын дәвам итә алмады.

Җәй көннәрендә, качып-посып кына печән әзерләп, кечкенә арба белән ташый идек, ә кыш көннәрендә урманнан кечкенә чана белән утын (вак-төяк чыбык) алып кайтулар әле дә хәтеремдә.

Авыл кешесен әнә шулай матди яктан да, рухи яктан да кыстылар, рәнҗеттеләр. Авыр тормышка чыдый алмыйча, авылдашларым, язылып, (вербовка белән) Урта Азиягә, Украинадагы шахталарга, Россиянең төрле өлкәләренә бәхет эзләргә китте, теленнән, туган җиреннән аерылырга мәҗбүр ителде. Татарстанның барлык авылларында да шундый ук хәл иде!

Шуңа күрә дә бүген татарның күбесе үз иленнән читтә яши.

Әй, язмыш, язмыш... Еллар үтеп, олыгая барган саен күңел нечкәрә дә нечкәрә. Узган юллар, узган еллар, мизгелләр кинодагы кебек күз алдыннан үтә. Һәркемнең тормышы үзенчә була. Миңа да гомер юлымда ниләр генә күрергә туры килмәде?! Инглиз драматургы Уильям Шекспир: *«Һәр кабердә олы бер дөнья ята»*, — дигән. Әти-әниемне уйлыйм да, әлеге сүзләрнең хакыйкать булуына инана барам. Әтием Шәйхулла Миңнулла улы, әнием Сәкинә Хәсәнҗан кызы Апас районындагы Иске Әнәле авылында игенче гаиләсендә туган. Әти-әнием, бергә тормыш корып, 50 ел тигез гомер итте. Шатлыкларын да, кайгыларын да урталашып бик тату яшәделәр. Алар икесе дә чибәр, уңган, сөйкемле, ягымлы, сабыр холыклы, кешелекле иде.

Әтием Беренче Бөтендөнья сугышында кан, тир түккән, яраланган. 1917 елгы түнтәрелеш вакытында аңа 19 яшь була. Мөгаен, ул большевикларның «Сугышны бетерәбез, игенчеләргә җир бирәбез, үз телегездә укырсыз, язарсыз, үз динегезне тотарсыз», — дигән сүзләренә ышангандыр. Чөнки моңа кадәр халыкка андый сүзләрне әйтүче булмаган. Чыннан да, НЭП елларында халык бераз яхшы гына яшәп ала, ләкин бу озакка бармый.

1941-1945 еллардагы сугышта да әтием өч ел дәвамында катнашты. Ленинград фронтындагы хәрби инженерлык батальонында сапер булып хезмәт итә, күп медальләр белән бүләкләнә. 300 йортлы авылыбызның 200ләп кешесе шул сугышта һәлак булган. Бәхетебезгәдер инде, әти 1945 елның 5 августында сугыштан исән-сау кайтты. Без бик тә шатландык. Сугыштан кайткач ук, колхозда тимерчелектә эшли башлады. Ул вакытта авылда техника белгечләре юк иде әле. Әтиебезнең җитмеш төрле һөнәре бар иде, дисәм дә ялгыш булмас.

Без биш бала идек, иң олысы — мин. Ул вакытта унынчы сыйныфта чыгарылыш имтиханын биреп йөрим. Энем, үгез җигеп, Каратун тимер юл станциясеннән колхозга керосин ташый. Сеңелләремнең берсе — өч, икенчесе — биш, өченчесе сигез яшьтә. Әниебез колхозда төрле эштә йөри.

Шулай тыныч кына яшәп ятканда, 1949 елның июнь аенда, өебезгә хәрби киемле ике кеше төнлә белән бәреп кереп, әтиебезне алып китте. Берничә көн үткәч, аны яңадан авылга алып кайттылар. Район партия комитетының киңәйтелгән бюро утырышы булды. Район үзәгеннән дә 15ләп кеше килде ул утырышка.

Әтиебезне: «Колхоз техникасын вата, начар эшли, шуның өчен Себергә сөргенгә җибәрәбез», − дип гаепләп, башта партия райкомының беренче секретаре Зәки Фәйзуллин чыгыш ясады. Аннан соң район башкарма комитеты рәисе Бари Мифтахов, район комсомол комитетының беренче секретаре Харис Заһретдинов һәм колхоз рәисе Галимулла Габидуллин сөйләде. Ахырда безнең гаиләне Себергә сөргенгә сөрергә дип, карар кабул иттеләр. Ни сәбәпле? Нинди «корткычлык» өчен? Сталин элек сыналган алымын сугыштан соң да менә шулай кулланды. Республикаларга, өлкәләргә сөргенгә озату өчен разнарядкалар җибәрелә, диделәр. Авылның иң тырыш, һөнәрле кешеләрен ерак җирләргә озаттылар. Әтием кебекләрне сөргенгә озатуның сере «даһи» Сталин үлгәч кенә билгеле була: Себергә үзе теләп беркем дә күчми, чөнки яшәү шартлары начар, фатир һәм башкасы... юк. Ә Себер якларында хәрби сәнәгатьне үстерү өчен кешеләр таләп ителә. Сталин, гадәтенчә, мәсьәләне үзенчә, җиңел хәл кыла...

Әти-әниемә туган нигездән аерылуы бик авыр булгандыр. Авылда шәп-шәп нарат бүрәнәләреннән салынган бик таза йортыбыз, сыерыбыз, башка мал-туар калды. Безнең гаилә менә шулай туган җирне ташлап китәргә мәҗбүр ителде.

Сәгъдулла Шәйхулла улы.
Амур өлкәсе, Тында. 1953 ел

***

...Тәрәзәләргә аксыл яктылык иңә башлаган иде инде. Ниндидер шомлы сизенүдән микән, уянып киттем. Чаршау артында әтиемнең тирән итеп тын алуы ишетелә.

Кинәт тупас итеп тәрәзәне кактылар. Йөрәгем жу итеп китте — безнең авылда болай итеп беркем дә тәрәзә какмый бит. Хәтта бригадир Фарук абый да...

— Ачыгыз!..

Әтием авырлык белән урыныннан кузгалды. Ул арада ишектән хәрби киемле ике кеше килеп керде.

— Миңнуллин Шәйхулламы? — дип сорады алдан керүчесе.

— Әйе... — диде әтием.

— Җыен тизрәк, контра!

Аны алып киттеләр.

Безнең өйгә көтелмәгәндә кергән кайгы авыл өстенә таралды: «Тимерче Шәйхулланы өтермәгә алып киткәннәр!»

Берничә көннән аны кире авылга алып кайттылар. Без дә аны күрергә бардык. Әтиебез янына хәтта безне — балаларын да якын җибәрмәделәр. Икенче көнне, ашъяулыкка ризыклар төреп, Апас төрмәсенә юл алдык. Тик аның белән күрешү насыйп булмады. «Аны инде Казанга алып киттеләр», — дип кенә әйттеләр.

Әниемнең нигезгә ятып елаганы әле дә хәтеремдә. Ул авылдан бер тапкыр да читкә чыкмаган, шуңа күрә, нигездән аерылуы аңа аерата авыр булгандыр. Барасы юлның никадәр сикәлтәле, дәһшәтле булуын башыбызга да китермәгәнбез шул...

***

Казаннан безне товар вагоннарына төяп җибәрделәр. Вагон шыгрым тулы — барысы да Татарстанның төрле төбәкләреннән сөрелгән кешеләр... Эшелон көчле сак астында көнчыгышка сөйрәлә. Тимер юл станцияләрендә торкыннарны жәлләгән халык вагоннарга якынлашырга тели: кайсысының кулында пешкән бәрәңге, кайсысыныкында — икмәк сыныгы. Ләкин сакчылар аларны безгә якын җибәрми: сүгенү тавышы, бурзайларның ырылдавы колакны тондыра...

Бер ай шулай юлда үтте. Ниһаять, «Большой Невер» станциясендә төшереп, безне йөк машиналарына утыртып алып киттеләр. Автомат көпшәләренә карап, тын гына барабыз, елый-елый күз яшьләре кипкән иде инде. Безне Тында бистәсеннән 200 чакрым читтәге бер төбәккә урнаштырдылар. Монда тагын берничә гаилә бар иде. Барыбыз да күзәтү астында яшәдек. Соңыннан белдем — бу җирләрдә яшәүчеләрнең һәммәсе дә сөрелгән кешеләр икән.

Әтием тимерчелектә эшли башлады. Ул, авылдагы кебек үк, алны-ялны белми намуслы хезмәт итте. Архивымда аны мактап язган уңай характеристикалар әле дә саклана. Сеңелем Тында бистәсендәге интернатта торып укый башлады. Безне бик сагына иде. Интернат, торган җирдән 200 чакрым ераклыкта булса да, еш кайтырга тырыша иде, чөнки аның янына барырга рөхсәт бирмәделәр.

Әлбәттә, дөнья көтү авыр иде. Ләкин күңелне иң түбәнсеткәне — үзебезнең гаепсез икәнне, нахакка рәнжетелгәнлегебезне тоеп яшәү булды. Әтием гаепсезгә сөрелүебез турында берничә мәртәбә Казанга, Мәскәүгә язып карады, ләкин җавап булмады. Сталинның үлүен ишеткәч, аның йөзе яктырып китүе исемдә: «Түзегез, балалар, — диде ул, — болай булгач, чит җирләрдә интегүебез озакка бармас».

Әтиебезнең зирәк акыллы булуы һәрвакыт сокландыра иде. Беркөнне кайтты да, болай диде:

— Милләттәшләрем чокыр казый иде. «Сталин үлгәч, нишләрбез инде хәзер?», — дип, бик кайгыралар. Мин аларны: «Бер дә кайгырмагыз, патша вакытында да, Сталин чорында да татар халкы яхшылык күрмәде, сез бит һаман жир казу эшендә, шул эштә булачаксыз...», — дип, «тынычландырдым» әле.

Еллар үтте. Алты елга якын Себердә торганнан соң, 1955 елның мартында безгә сөргеннән китәргә, Татарстанга кайтырга рөхсәт иттеләр. Мөмкинлек булуга ук, кубарылып, без апрель башларында Казанга кайттык. И, туган җирнең гүзәл тарту көче... Ә бит күпме кан кардәшебез чит-ят туфракта каберен тапты, күпмесе шунда төпләнеп калды... Безнең сагынуга чикләр юк иде...

Тик Иске Әнәле авылыннан тамырлар аерылган иде инде. Без Казанда төпләндек. Әтиемне, һөнәрләре күп булу сәбәпле, эшкә тиз алдылар, хәтта фатир да бирделәр...

***

Әтиемне аклауда үземнең дә катнашуыма сөенәм. Халыкны кысулар, законсызлыклар һәм башбаштаклыклар нәтиҗәсендә гаепсезгә репрессияләнгәннәрне аклау башлангач, без дә, әтиебезнең «эш»ен тикшерүне сорап, Татарстан Республикасы прокуратурасына мөрәҗәгать иттек. Беренче үзгәреш көннәрен әтиебез үзе генә күрә алмады, шунысы бик кызганыч. Әтиебезне нахакка гаепләгән «эш», кырык елдан соң, 1989 елда Татарстан Республика прокуратурасы тарафыннан яңадан тикшерелде, карар кабул ителде. Гаделлек җиңде — ул акланды. Әлеге карар — документта болай диелә: *«Сезнең үтенечегез Татарстан прокуратурасы тарафыннан тикшерелде, 1898 елда туган Миңнуллин Шәйхулла Миңнулла улының һәм аның гаиләсенең ТАССРның Апас районы Иске Әнәле авылыннан Амур өлкәсенә мәҗбүри җибәрелүе прокуратура тарафыннан дәлилсез, дип табылды»*.

Шулай итеп, бу коточкыч хәлләргә кырык ел вакыт үткәч, хакыйкатьнең тантана итүенә ирештем. Әтием, әнием һәм без — балаларының исемнәре сәяси репрессия корбаннарының «Хәтер китабы»на кертелде. Димәк, ул — дәһшәтле чор, газаплы көннәр, аерым язмышлар мисалында гыйбрәт булып тарихка кереп кала дигән сүз. Бу бүгенге көн өчен генә түгел, киләчәк өчен, ул көннәрнең яңадан кабатланмавы өчен дә кирәк. Ул язмышлар — тере хәтер, киләчәккә кисәтү...

Ике сугышта канын түккән, авыр яраланган яугиргә, биш бала атасына, 52 яшендә туган җиреннән аерылып, әнә шундый кайгы-хәсрәтләр күрергә язган булган...

Сталин чорында нахакка җәзаланучылар турында хәзер күп сөйләнә. Никадәр күренекле шәхеснең каны коелган, күпмесе лагерьларда һәлак булган. Сталин корбаннары арасында исемнәре билгесез миллионлаган кешеләр бар. Алар үзләре турында истәлек китаплары яза алмый. Шул хурлау-кимсетүләрне исән-имин үтә алучыларның йөрәкләрендә мәңгелек яра... Шушы язмам адәм ышанмаслык михнәтләрдә дә намусын, туган җиргә мәхәббәтен югалтмаган якташларым һәм әтием Миңнулла улы Шәйхуллага бер дога булып ирешсен! Күңелдә олы теләгем бар: караңгы еллардагы гаделсезлекләр, вәхшилекләр, күз яшьләре кабатланмасын иде!.. Беркайчан да!.. ■

ИСЛАМИЯТТӘ МУЗЫКА

Мөхәммәт Галләм,
Уфадагы «Ислах» мәчете имам-хатыйбы

Музыка, көй-моң – ул хисләрне һәм тойгыларны тавыш, авазлар хәрәкәте белән аңлату сәнгате яисә тавыш моңының гармониягә – тәртипкә салынуыдыр.
«Музыка» сүзе мәҗүсилек заманнарда борынгы Грециянең Мауза-муза исемле алласына бәйләнешле.

Музыка – милләтләрнең инану-ышануларына, гореф-гадәтләренә нык үтеп кергән тавыш чыгару сәнгатедер. Музыка коралының иң башта кайда кулланыла башлавы хакында мәгълүматлар юк. Шулай да, фәнни эзләнүләр нәтиҗәсендә, дөньяның төрле төбәкләрендә төрле музыка кораллары булуы билгеле.

Борынгы грекларда лира дигән уен коралы, соңыннан Борынгы Мисыр, Анатолия, Мессопотамия, Кытай, Һиндстан һәм Ерак Көнчыгыш кавемнәренең үзләренә генә хас күптөрле музыка кораллары кулланылган.

Исламият – мәдәни тормышыбызның һәр мәсьәләсендә иң тугры мәгълүматлар бирүче. Музыка, аның адәм баласына тәэсире, файдасы яисә зарары хакындагы хөкемнәр дә дини китапларда урын алган.

Тәннең һәм рухның ихтыяҗлары аерым-аерымдыр. Тәнебезнең ихтыяҗлары карашыннан, кеше хайвани мәхлуклар белән охшаштыр. Ләкин хайвани мәхлукта рух юк. Кешенең рухы исә Аллаһы Тәгалә разый булган нәрсәләрне теләр. Мәсәлән, гүзәл һәм моңлы тавыш ишетү күңелгә хуш килер.

Күңелендә Аллаһыга сөю, хак диннәрнең мөкатдәс кадрияләренә хөрмәт вә ихтирам тойгысы булган кешеләр Аллаһы Тәгаләнең сөйгәннәрен хәтерләткән Коръән Кәримне тыңлаудан, догалар һәм мөнәҗәтләр укудан вә тыңлаудан ләззәт алыр.

Шулай, хаҗга китәргә әзерләнүчеләрнең Мәккә-и-Мәдинә көйләрен тыңлаулары, гаскәри көчләрдә хезмәт итүчеләрнең батырлык-каһарманлык җырларын башкарулары кешеләрдә нечкә вә ләззәтле хисләр уятадыр.

Илаһи диннәрнең соңгысы Ислам инсанны Аллаһы Тәгаләне сөюгә китергән рухка хис-тойгы, ләззәт бир-

гән гүзәл тавышларны тыңлауны ясак итмәгән яки һич кенә дә тыймаган. Киресенчә, кешеләрне азгынлыктан читләштереп, аларның рухларын канәгатьләндергән вә йөрәкләрендә Аллаһ сөюен арттырырга ярдәм иткән тавышларны тыңлау — агар суларга, яшеллеккә вә чәчәкләрнең матурлыгына карап сөенгән кебек булыр.

Аларны карау күзгә ләззәт биргәне кебек, тәмле исләр борынга хуш килгәне кебек, ләззәтле ризык авызга татлы булганы кебек, фәнни хезмәт акылга муафыйк булгандай, моңлы тавыш колакка рәхәт бирә.

Кешеләрнең азгынлык эшләвенә сәбәпче булмаган, аларга зарар китермәгән, аларның рухларын туклындырган вә йөрәкләренә Аллаһны сөюен арттыруга ярдәм иткән микъдарда, музыка тыңлау — хәтта савaптыр. Адәм баласына зарар биргән, гөнаһ һәм начарлыкка юнәлткән музыкалар бөтен илаһи диннәрдә дә тыелган. Ислам динендә бу бәлаләрдән саклау өчен, музыка төрле төрләргә бүленә һәм дә зарарлы булганнары хәрам кылынмыштыр.

Исламият кешене Аллаһы Тәгаләдән ераклаштырган, рухны үтереп, нәфесне кабарткан музыкаль тавышларны башкару вә тыңлауны тыйган.

Ислам тарихыннан бер риваять: Рәсүлуллаһ (ﷺ) Мәккәгә гаскәре белән кергән заман алдында бер якыны бәетләр, мөнәҗәтләр, шигырьләр укып бара. Гомәр (رضي الله عنه) моны күргәч:

— Пәйгамбәребез алдында шулай шигырь укылырмы? — ди. Рәсүлуллаһ:

— Куйчы, я Гомәр, каршы килмә! Бу бәетләр кяферләргә ук атудан да ныграк тәэсирледер, — дип боера.

Моңардан аңлашыладыр ки: кяферләргә зарар бирүче, аларны өзгәләүче шигырьләрне уку, бәетләр әйтү — дөрестер.

Гөнаһларны, гаепләребезне, ахирәт газапларын аңлаткан, тәүбәгә сәбәпче булган музыка тыңлау — савaптыр.

Җәдидчелек хәрәкәтенә кадәр татар

халкында музыкаль әсәрләрне башкару һәм аңлау, аларны җитди өйрәнү түбән дәрәҗәдә булган. Күпчелек дин әһелләре бу шөгыль дә Ислам диненә каршы килә, дип исәпләгән. Октябрь түнтәрелешенә кадәр төрле уен коралында уйнау, аңа кушылып җырлау күп очракта зур бәйрәмнәрдә генә башкарылса да, музыка хакында уңай фикерләр әйтелмәгән. Гармунда, кубызда, курайда гадәттә аулаграк урыннарда яки качып уйнаганнар. Шулай булса да, татар халкы моңсыз, җырсыз, музыкасыз яшәмәгән. Качып уйнаучыларны музыканы аңлаудан ерак торган бәндәләр саклап торып нык кыйнаган яисә уен коралларын идәнгә салып таптаган. Моны күбрәк иске фикерле фанатик дин әһелләре кушуы буенча шәригать хөкемнәрен һәм аның тәртипләрен белмәгән надан кешеләр башкарган. Шундыйрак хәлләрне Ризаэддин Фәхреддиннең энесе Салих ага да, Кичүчат авылы картлары да еш телгә ала иде.

Дөрестән дә, Ислам дине музыканы тыйганмы? Бу турыда бүген

теләсә кайсы дин әһеленнән сорасаң да, канәгатьләндерерлек төпле җавап бирүче табылмас. Әмма үз заманында музыка турында дин галимнәре Ризаэддин Фәхреддин, Шиһабетдин Мәрҗани, Зыя әл-Камали, Муса Биги, Бәдиуззаман Сәед Нурси, Гатаулла Баязитовлар үз фикерләрен бик анык итеп язып калдырган. Гади халык исә музыкага тискәре караштa яши биргән. Чөнки бу турыда ныклы аңлату чаралары кулланылмаган. Музыка алымнары, җырлар барысы да Көнбатыш цивилизациясе дип кабул ителгән. Әмма тарихи төп чыганаклар моның киресен исбатлый.

Көйләр көйләнү, музыка коралларында уйнауны һәм тыңлауны хәрәм һәм мәкруһ дип дәгъва итүе кыен. Коръәндә музыка коралларында уйнауның, аларның тавышларын тыңлауның хәрәм булуы хакында сүз юк. Мәшһүр мәзһәпләрнең башлыклары булган имамнарның да бу хакта ачык аңлаткан сүзләре барлыгын белмиләр. Рәсүлуллаһ хзрәтләренең гает көннәрендә, туй вакытларында уен уйнаудан тыймаганлыгы билгеле. Бу турыда хәдисләр өйрәнүче галимнәрнең иң мәшһүрләреннән булган Сәхыйх Бохари күп яза. Башта ук хәрәм булган нәрсә ничек итеп гаеттә һәм туйда гына хәрәм булмый калсын, ди? Шуны әйтәбез ки, уен коралларының моңлы тавышы кешеләрнең кайгы-хәсрәтен киметә, җаннарына тынычлык, рәхәтлек һәм сабырлык бирә. Заман табиблары хәзер рухи хасталарны музыка белән дәваларга да киңәш итә.

Сандугач сайравы белән скрипка кылларыннан чыккан тавыш арасында нинди аерма бар? Ни өчен сандугачны тыңларга ярасын да, соңгысын тыңлау хәрәм булсын, ди. Бозык, хәрәм эшләрне үз эченә алмаса, ягъни әшәкелеккә сәбәп булмаса, уен коралларында уйнау, музыка иҗат итү, җырлау һәм тыңлау Ислам динендә тыелмаган. Музыканы тыючыларның тәнкыйтьләре гел бозык нәрсәләрне генә күз алдында тотудан киләдер, мөгаен. Безнең татар-башкорт арасында музыканы тыю чамадан тыш булган, бигрәк тә хатын-кызлар өчен. Әйтик, кубыз уйнап торган унике яшьлек кызны, толымыннан тотып, башын баганага бәреп үтергәннәр. Болар бит очраклы гына булмаган.

Бозык урыннарга йөрүче һәм начар юлдашларга ияр үче яшьләрне музыка тыңлау үзенә җәлеп итәргә һәм алар өчен хәрәм юлларны бикләргә тиеш.

Хәрби ахун Гатаулла Баязитов түбәндәгеләрне әйтә: *«Музыкальная гамма»ны Көнбатыш илләре гарәпләрдән — ислам дөньясыннан алган, ә гарәпләр бу гамманы Һиндстаннан алган. Бу хәл — ислам дөньясында музыканың тыелмаганлыгын күрсәтүче дәлил»*.

Ризаэддин Фәхреддин үзенең хезмәтләрендә шигырь һәм музыка турында, гомумән Ислам мәдәнияте мәсьәләләре буенча, бик еш телгә алып язган. Галимнең «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләре», «Җәвамигуль-кәлим шәрхе» дигән китапларын укып чыгу гына да безнең зиһенебезне ача. Ислам дөньясында көйләп догалар, мөнәҗәтләр, бәетләр уку игътибар үзәгендә булган. Коръәнне мәкам белән уку аеруча абруйлы эш санала. Манарадан яңгыраган азан тавышы бөтен шәһәр һәм авыллар өстендә илаһи моң булып яңгырый. Ризаэддин Фәхреддин үзе дә музыкадан бик хәбәрдар булган. Аның курай, гармун, флейта, скрипкада уйнаучыларны дикъкать белән тыңлавы турында замандашларыннан язма мәгълүматлар бар. Халкыбызның иң нечкә хисләрне уятырлык борынгы көйләре — «Сакмар суы», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү», «Урал», «Сандугач» галимнең иң яраткан әсәрләре булган. ■

1798 елда Орнашбаш авылы сәүдәгәре Муса бине Мөслим бин Мамыш әс-Сәрдәви акчасына салынган мәчет, төзекләндерүдән соң, узган елның декабрь аенда яңадан ачылды. Заманында бу мәчетне «Муса бай мәчете», «Бишенче мәхәллә мәчете», «Тихвин урамындагы таш мәчет», «Тихвин һәм Печән базары почмагындагы мәчет», «Галиев мәчете» дип тә йөрткәннәр. Соңгы исеме тарихка кереп калган. Мәчеттә беренче намаз 1800 елда укылган.

ГАЛИЕВ МӘЧЕТЕ



ГАИЛӘ ДӘРЕСЛӘРЕ*

Фәхрелбәнат Сөләймания

ГЫЙФФӘТ

Вәрәгъ [тыелу] — шәригатькә, гакылга, кешелеккә муафыйк булган яхшы эшләргә даимчылыктыр ки, изге эшләрнең һәрберсенә мәхәббәт берлә керешмәк бу фазыйләтнең җимешедер.

Интизам [тәртип] — эшләрнең кирәгенчә вә мәслихәткә муафыйк рәвештә эшләнүенә көч җитмәктер. Ягъни бер эшнең ничек булуы, лаек вә ни рәвештә эшләнергә кирәк вә мәслихәткә ничек муафыйк булса, шул рәвешчә эшләргә кулдан килеп, шулай эшләргә тырышмак — интизамдыр. Ашауда, эчүдә, йокыда, эш вә кәсептә, гомумән, һәрбер эштә интизамнан чыкмаган адәм бәхет вә сәгадәткә ирешер.

Сәха [юмартлык] — лаек булган нәрсәне лаек булган кешегә, лаек булган кадәрле бирмәктән гыйбарәт булган инсаниятkә лязим бер фазыйләттер. Сәха алты төрледер.

1) Керемнән бер нәрсәне җиңеллек берлә, күңел хушлыгы берлә бирәсе килеп бирмәктер.

2) Исардыр — үз кирәгенә тотмыйча, үзенә кирәк була торып, кешегә бирмәктер (*ягъни малны бик юмарт тарату — ред.*).

3) Бирә торган нәрсәсен сөенә-сөенә бирмәктер.

4) Дус вә ишләр мөшарәкәте [катнашы] берлә бергә малны өләшмәктер.

5) Өләшү важиб [тиеш] булмаган малны бернәрсә өмид итми бирүдер.

6) [Кире] кичү [бирү] лязим [тиеш] булмаган нәрсәне шәфкатьтән кичмәк мәгънәсендә. Мәсәлән: бер адәм икенче адәмдә булган алачагын бер мөкяфәт [бүләк] өмете булмый кичмәк, я бер микъдарын һибә кылмактыр [бүләк итү]. Юмартлык гадәттән артык булса, исраф булыр, диндә хәрәм, гакылга салып караганда, начардыр. Бик киме дә — саранлыктыр, бу да бик гаептер. Юмарт адәмнәрне һәркем сөя. Юмартлык — әҗер вә савапка сәбәп булган мәкъбүл [кабул ителә торган] эшләрдәндер. Сәдака — бәлаләрне кайтара торган бер дәвадыр. Бер фәкыйрь, үзе эшләп акча табарга көче җитмәсә, сәдака алырга мөстәхикътыр [хаклы]. Вә аңа сәдака бирмәк важиб булыр. Ләкин тап-таза булып та теләнчелекне һөнәр вә сату коралы итеп йөрүчеләргә акча бирмәк, аларны хәйләкәрлеккә вә сорану хурлыгына кызыктыру булып, аслән дөрес түгелдер.

ХИКМӘТ

Хакимнәр хикмәтне киләчәктәге рәвешчә тәгъриф кылалар [аңлаталар].

---

* Дәвамы. Башы журналның 1 нче санында

Хикмәт шундый бер хәлдер ки, рух ихтыярлы булган эшләрнең һәрберсендә тугрыны хатадан аерыр. Яки хикмәт бернәрсә хакында иң тугры хөкемне табып чыгармактыр.

Хикмәтне бик ачык белер өчен аннан туган берничә фазыйләтләрне белмәк лязимдер ки, алар да шушылардыр:

1) Сафвәт зиһен; 2) җәүдәти фәһем; 3) зәка; 4) хөсне тәсаувыр; 5) сөһүләт тәгаллем; 6) хифыз; 7) тәхаттыр.

Сафвәт зиһен — теләнелгән нәрсәне уйлап чыгаруда зиһен чуалып, нәфеснең мәшәкатькә төшми тиз уйлап чыгаруыдыр.

Зәка — зиһеннең, эшнең әүвәленнән ахырына бик тиз күчмәкедер ки, моны аңламак, гакыл җитмәк дип тә әйтерләр.

Хөсне тәсаувыр — бер нәрсәне аңлап чыгаруда аңар катнашы булмаган башка нәрсләрне катыштырмый яхшы аңламак куәтедер.

Сөһүләт тәгаллем — артык мәшәкатьләнми теләгән нәрсәне үгрәнмәк куәтедер.

Хифыз — укып аңланган нәрсәне күңелгә бикләмәктер. Күңелгә беркетмәк куәте булмаса, дөнья бу көнге тәрәккыйләргә ирешмәс иде.

Тәхаттыр — күңелгә бикләнгән нәрсәне теләнелгән вакытта мәшәкатьсез хәтергә китерә алудыр. Бу кеби адәмгә «җавабы кесәсендә», диярләр.

Менә гыйльме әхлакча без аңлый ала торган хикмәт шул саналган холыклар вә фазыйләтләр берлә табылыр. Хикмәт иясе булганнарга хаким диярләр.

Хикмәт гыйлем куәтенең уртача хәле булып, артыгына — хәйләкәрлек, бик азына аңгыралык, диярләр.

ГАЛИҖӘНАБЛЫК

Галиҗәнаблык — бер куәттер ки, адәмнең байлыкка, фәкыйрьлеккә вә халыкның мактау вә хурлавына каршы хәбәрләнми вә дөньяның алмашынуларыннан кайгырмый, гайрәтенә вә гали һимматенә [дәрәҗәсенә] кимчелек китермәүдер. Ягъни бай булса — зурланмый, фәкыйрь булса — хурланмый, халыкның мактавына куанмый, яманлавына кайгырмый, дөньяның алмашынуларына һич исе китми, һәрбер вакытында бертөрле булып, үзенең дәрәҗә вә һимматен саклый алуыдыр.

Газме һиммәт — адәм һәрбер вакытта чын гүзәллекне вә адәмнең үзендә булган кәмалатне күзгә алып, дөньяның ни алга баруыннан артык шат вә ни артка китүеннән кайгылы булмауларыннан гыйбарәт булган бер хасияттер.

Сабыр — кайгы вә катылыкларга каршы чыдамлы вә түземле булудан гыйбарәт булган бер файдалы эштер ки, моңар тотынганнар, билгеле, артык кайгырып үзләрен бетерүдән котылырлар. Бу урындагы сабыр батырлык кыйсеменнәндер.

Нәҗат — хәтәрлеккә очраганда үзен куркудан саклаудан гыйбарәт булган батырлыктыр ки, бу фазыйләт адәмне тәһликәле [һәлакәтле] бер тиешсез эш эшләп ташлаудан саклар. Яисә нәҗат — адәм үзенең түзә алуына ышануыдыр ки, мөшкел эшләрне бетермәк моның берлә генә мөмкин булыр.

Хилем — ачу-кычу вакытында юаш булмактыр ки, зур фазыйләтләрнең берсе дә будыр. Ачуның бик кызу вакытында күңелнең ашкынмый тыныч тора алуы адәмне бик күп хәтәрләрдән вә начарлыклардан саклар. Йомшак күңелле кешеләрне һәркем сөяр.

Сөкүн — тавыш-гауга вакытында җиңеллелек вә кызулык күрсәтми акрынлык вә сабырлыкны сакламактыр. Кызулык сыйхәткә, хәттә тереклеккә дә зарар бирер. Бу кызулык вә җиңел ачулылык һәр заман иясен оятка калдырыр. «Ачу берлән саргайган — үкенеч берлә кызарыр», дигән сүз бик тугры сөйләнмештер.

Тәвазыг — адәмнәрнең үзләрендә бер артыклык бар, дип уйлап, үзләрен халыктан зур дип белмәүләре, байлык, мәртәбә вә зурлык җәһәтеннән үзләреннән түбән дәрәҗәдә булганнарын үзләреннән кечкенә санамауларын-

нан гыйбарәт булган бер яхшы эштер. Үзен һәркемнән кечкенә күргән адәм — олугтыр. Түбәнчелек — инсаниятнең бик зур артыклыгыдыр. Алай да моны бик арттырып җибәреп хурлыкка төшмәк муафыйк булмас. Һәрбер эшнең уртачасы гүзәлдер.

Шәһамәт — дәрәҗә артуга вә яхшы исемгә сәбәп булырлык зур вә күркәм эшләрне эшләргә нәфеснең кызыгуыдыр.

Тәхәммел — күркәм сыйфатларны вә гали эшләрне кәсеп итү тугрысында иҗтиһадны өскә алып тәннең мәшәкатьләнүедер.

Хәмиять — намус вә динне вә инсаниятне саклау юлында иренми тырышмактыр.

Рикъкать — бер адәмнең җенестәшләрендә күренгән кайгы вә хәсрәтләре өчен үзендә дә кайгы хасил итүедер. Йомшак күңеллелек рәхимле булырга сәбәптер. Хисле күңел һәрвакыт йомшак булыр. Ләкин бу тугрыда коры кайгырудан гына бер файда да килмәс. Бәлки кайгылы кешедән кайгыны җибәрү сәбәпләренә керешеп, аның котылуына чара эзләмәк кирәктер ки, йомшак күңеллелекнең тәмам мәгънәсе менә бу урындадыр.

Бу холыкларның адәмдә җыелмагы дөнья вә ахирәт бәхетенә сәбәп булыр. Шуны да әйтеп китмәк лязимдер ки, һәрнәрсәнең бик артык вә бик кимендә зарар бардыр. Эшләрнең артыграгы вә гүзәлрәге уртача булганыдыр. Югарыда саналган гыйффәт, хикмәт вә шәҗагатьнең [батырлыкның] җыелуыннан гаделлек дигән инсаниятнең күз нуры хасил булыр.

ЭШ ВӘ ТЫРЫШУ

Җәнабе Хак «Адәм үзе иҗтиһад итсә, тырышса гына таба» мәгънәсендәге аять кәримәсе илә тырышмакның фарызлардан булганын колларына белдермештер. Һәмширәләр!* Адәмнең тәнен идарә кыла торган димаг, ягъни «ми» фикер вә уй куәте өчен бер билгеле урындыр. Ми фикер вә мәгърифәт нуры берлән нурланмаса тонык булып калыр. Үзенә тиешле вазифасын кирәгенчә кыла алмас. Ул вакытта ми дә тәнне яхшы идарә кылудан гаҗиз калыр. Фикернең нурлануы исә эш вә тырышлык берлә хасил булыр. Бу эш ялгыз мигә генә махсус түгелдер. Адәмнең тәнендә булган һәрбер әгъза эшләргә вә хәрәкәтләнергә мохтаҗдыр. Хәрәкәтләнмәсә авыруга, кимчелеккә дучар булыр. Хәттә җан да тырышмак, эшләмәк берлә тәрбияләнер вә камилләнер. Алай булса эш эшләмәк, тырышмак адәмнең тәненә матди вә мәгънәви сырхаулар килүгә каршы иң нык, иң камил булган бер калкандыр. Уйланылса беленер ки, адәмнәр бер кабым икмәкне йотар өчен дә чәйнәмәк гайрәтенә мохтаҗлардыр. Адәмнәр туган вакытларындагы кеби калсалар, дүрт аяклы хайваннан нинди аермалары булыр иде? Димәк ки, безне адәм иткән нәрсә — тырышмактыр. Тырышмак булмаса тәрәккый вә сәгадәтләребезне кайдан табар идек.

Сыйхәт, гыйлем, байлык, бәхет кеби адәмнәрне рәхәтлеккә ирештерә торган нәрсәләр күктән яулыкка төйнәлеп төшми. Болар бар да тырышу аркасында гына табыладыр. Хайваннарга кадәр, яшәмәк өчен тырышырга, бер кабарлык ризык табар өчен йөгереп эзләргә үзлекләреннән мәҗбүрләрдер.

Эшләмәк, тырышмак адәмнәрнең яратылышыннан булган бер вазифаларыдыр. Тәкъдирдә булса, булмый калмас, диеп утырмак, «алма пеш, агызга төш», дигәнчә көтеп тормак адәмнәрне бәхетле итмәс. Һәрнәрсәне тәкъдиргә сылтап, үзе булыр әле, дип көтмәк — наданнар эшедер.

Һәр эш тәкъдир иләдер,
Әмма тырышмак берлә бергәдер.
Тырышмак илә тәкъдир —
Ике игез тугандыр.

Дәвамы бар ■

*Һәмширәләр — сеңелләр.

Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре

● Кеше үзенең нинди адәм икәнен беләсе килсә, күршеләренең сүзләренә колак салсын.

● Кулыңнан килсә, форсат тисә — галим бул, бу эш насыйп булмаса, шәкерт вә гыйлем эстәүче бул, бу да мөяссәр булмаса, гыйлем мәҗлесләрендә гыйлем тыңла, бу да булмаса, гыйлемне дус күр. Инде моннан башка булырга ярамый. Чөнки һәлаклек шундадыр.

● Әгәр дә мөселманнарның башкалар рәвешендә дөньяда рәхәт вә бәхетле торасылары килсә, моның бердәнбер чарасы — башкалар кабиленнән тәртипле рәвештә гыйлем хасил итүдер.

● Сәләфләр гасырында мәҗбүр булмаган кешеләр үз телләре белән сәдака сорамыйлар вә соралмый биргәнне дә кабул итмиләр, үзләре сәламәт вә кәсепкә кодрәтле булган хәлдә кешеләргә кул сузуны хурлык вә сәфаләт саныйлар иде. Әмма безнең заманыбызда бу сәдака ысулы бөтенләй бозылды, сәдака җыю макталган кәсеп рәвешенә керде, ислам рухының вә максудының тәмам киресенә китте.

● Бирүче кул, алучы кулга күрә, әлбәттә, яхшырак.

● Адәм балалары үзләре өчен генә түгел, үз гаиләләрен, якыннарын да тәрбия кылу вә бәлагә дучар булган дин вә нәсел карендәшләренең ярдәмнәренә җитешү берлә дә йөкләтелгән. Шуның өчен дә кәсеп кылырга вә мал табып байлык хасил кылырга мәҗбүрләрдер.

● Бу дөньяга кызыгу, акча вә байлыкка мәхәббәт кылу, мөселманнар өчен кәсеп кылу дөрес түгел, диючеләр ялгыш вә асылсыз һәм мәгънәсез сүз сөйлиләр. Мондый эчтәлектәге сүзләр беркатлы адәмнәрнең малларын, байлыкларын йолкыр вә сөлек урынына суырыр өчен фани дөньяга рәгъбәт итүчеләр вә җиңеллек белән генә акча табарга тырышучылар тарафыннан әйтеләдер.

● Дөньяда иң ләззәтле икмәк, адәм баласының үз кәсебе вә кул көче берлә табылган, маңлай тирләре агызу сәбәпле кулга кергән икмәк булыр.

● Дөкяненңне яхшы карасаң, дөкянең сине яхшы карар, ач вә ялангач итмәс.

● Адәм баласы никадәр зирәк вә зур гаиләгә ия һәм дә бай булсын, кулы берлә бер эш эшләү, тир агызып байлык табу аңа һич гаеп булмас вә аны үз дәрәҗәсеннән аз гына да төшермәс.

● Һөнәр — фәкыйрьлектән саклый торган калкандыр.

● Дөнья елдан-ел үзгәрә, тереклек көннән-көн башкара, кичәге һөнәрләр бүген ярамый. Бу көнге кәсеп иртәгенең хаҗәтен үти алмый. Авылларда чалгы вә ураклар машиналар белән алмашынып бара, чалгы чүкү урынына машинаны бозмый йөртә белү, бозылса төзәтә алу һөнәре кирәк буладыр. Юкса, дөньяны һөнәрле адәмнәргә тапшырып, бер тарафка китү вә комачаулап йөрмәү кирәк буладыр.

Ленар Гобәйдуллин *әзерләде.* ■

БАЙГАРА ЯЛАНЫНДА ТӨЧЕ КҮМӘЧ

Зәки Зәйнуллин

...Байгара кырларында жнейка белән без өчәү бодай чабабыз. Бездән өч яшькә олы Папай Нигъмәте жнейкада «старший», мин «памушник», ә Хирахау Халите безнең «куних»: атларны карый, ашарга пешерә. Жнейкага өч ат җигәбез: Захмай, Әмәт, Даружный. Иртәгә – Корбан бәйрәме. Өйләдән соң яңгыр ява башлады. Нигъмәт, өч яшьлек, сыер кебек кызыллы-аклы төстәге Ала Тайга атланды да, жнейканың сынган ике шатунын алып, авылга кайтып китте.

– Мин өйдә кунармын. Бетләтте, мунча керәм. Иртәгә сезгә Корбан бәйрәме күчтәнәчләрен алып килермен. Пәрәмәч, коймак-кыстыбыйлар... Көтегез. Азрак он бар анда, төче күмәч әтмәлләгез.

Байгарага килгәнгә өченче көн генә китте. Бригадир Бакыйр Сәвәләй безгә эшне «кисеп» тоттырып китте:

— Ике көннән хатыннар көлтә бәйләргә килә. Көн-төн чабыгыз бодайны, аларга эш җитәрлек булсын!

Көн-төн бодай чабабыз. Шунлыктан, куыш та әтмәлләп тормадык.

Нигъмәт кайтып киткәч, вак кына яңгыр сибәли башлады. Жнейка платформасын күтәртеп терәүләр куйдык та, астына кереп яттык. Үтереп ашыйсы килә. Шунда Халит әйтә миңа:

— Карале, бер төче күмәчлек он бар. Син тал арасыннан коры-сары алып кил, мин камыр басыйм. Жнейка астында, бик кыздырмыйча гына учак ягып, шул төче күмәч камырын көлгә күмик.

— Яңгыр бит...

— Булса соң! Жнейка платформасы калайдан — янмый ул.

Шулай эшләдек тә. Халит камыр баса, мин тал корысын ягып, жнейка астында учак ягам. Бик күп булмаса да, утлы күмер төште. Халит, камыр изеп, түгәрәк кенә бер төче күмәч ясады. Шул төче күмәчнең камырына бер чыбык белән аркылыга сызык сыза.

— Нигә инде ул сызык?

Халит камырга, сызыкның бер ягына «Зәки» дип, икенче ягына «Халит» дип язды.

— Менә бүлдем төче күмәчне. Яртысы — синеке, икенче яртысы — минеке.

— Пешкәч тә урталай сындырыр идең әле.

— Юк инде. Пешкәндә үк кем ашыйсын белеп пешсен!

Һәм... төче күмәч, чыннан да, кем ашыйсын «белеп» пешкән икән. Халит, учак көлен читкә чыбык белән этәреп, төче күмәчне кулына ала башлады. Тик күмәч кайнар иде. Ул төче күмәчне сызык буенча урталай сындырды. «Зәки» дип язылган яртысын миңа биреп, «Халит» дигән яртыны үзенә алды.

Ачыктырган — күмәч бик тәмле иде. Халит үзенә тигән өлешне кабып карады да, чәйнәүдән туктады.

— Аша, Хирахау! Нигә туктадың чәйнәүдән?

— Пешмәгән бит бу. Чи. Синеке пешкәнме?

— Пешкән.

— Бирәле, кабып карыйм.

Кечкенә кисәк сындырып бирәм. Кабып чәйни.

— Пешкән синеке, әй! Ә минем як — чи, камыр гына. Ашарлык түгел.

Үземнең кисәкне урталай сындырам да яртысын Халиткә сузам.

— Тот! Аша!

— Үзеңә әз кала бит!

— Без бит, Халит, дуслар! Шулай булгач, азаккы кисәкне дә бүлешергә тиешбез. Тот, аша!

Ашап бетердек, туймадык. Шул ярым ач хәлдә жнейка платформасы астында ятып йокладык. Иртән Нигъмәтулла абый тавышына уянып, үрмәләп чыгып аякка бастык. Ул, бер зур ашъяулыгына төреп, безгә бәйрәм күчтәнәчләрен күпләп алып килгән: коймак, кыстыбый, вак эчәк бәлешләре...

Атлап йөрмәслек итеп, корсакны тәмле ризык белән тутырдык та, акрын гына кыймылдап, Нигъмәт абый җитәкчелегендә куыш корырга тотындык...

***

Бик күп еллар үтте. Гомеремнең шактый өлешен читтә, хәрби хезмәттә уздырдым. Кайткан-киткән чакларда — Халит белән очрашабыз. Берсендә искә ала бу:

— Исеңдәме, Зәки. — ди. — Байгара яланында жнейка платформасы астында учак ягып, соңгы оннан төче күмәч пешергән идек.

— Исемдә. Син аңа, аркылыга сызып, бер ягына «Халит» дип, икенче ягына «Зәки» дип язып, кайнар көлгә күмгән идең.

Халит, миңа карамыйча гына, сүзен дәвам итә:

— Ы-ы! Сызган идем шул. Сине алдалап... Мин бит анда хәйләләдем. Төчекүмәчнең ярты ягын калын итеп ясап, шул якка «Халит» дип яздым. Янәсе үземә күбрәк итәм инде. Ә синең якны юка иттем. Аллаһы Тәгалә минем комсызлыкны карап торган да: «Мә, сиңа Хирахау Халите! Комсызланганың өчен!» Минем як учакта пешмәгән! Чи калган! Синең як — юка, пешкән!

Исем китеп, өнсез калып, Халиткә карап утырам.

— Менә син мине шуннан соң дус диген инде, йә?!

— Ярар ла, Халит! Ач идек бит! Соң булса да, сөйләдең бит инде. Үкенгәнсең бит.

— И-и, Зәки дус! Үкенү генә дисеңме? Шуннан бирле мин, Аллаһы Тәгаләдән куркып, шүрләп, аңа табынып яшәдем, яшим. Гомерем буена калхузда кара эштә булдым. Калхузныкын, кеше күрмәгәндә, «суккаладым» инде. Калхузныкын урлаудан гөнаһ юк — безне талаган хөкүмәтнеке бит ул. Әмма дә кешенекенә тимәдем, әй! Күз кыза башласа, Байгара яланын, жнейка платформасы астын исемә төшерә идем. Син бит, әй, шунда да комсызланмыйча, үзеңнең «Зәки» дип язган ярты төче күмәчеңне, урталай сындырып, миңа бирдең. Чын дус син, Зәки! ■

ТАРИХИ СПЕКТАКЛЬЛӘР

Нурихан Фәттах

«Итил суы» басылып чыгып беркадәр вакыт узгач, романны сәхнәләштерергә теләк белдерүчеләр барлыкка килде. Аеруча К.Тинчурин театры активлык күрсәтте. Роман, имеш, сәхнәдә күрсәтү өчен бик шәп, отышлы, тарихи һ.б. Сәхнәләштерү, кинолаштыруга минем бик үк күңел тартмады. Әсәрне яратып укыйлар икән – укысыннар, нигә аны тагын ботарларга? Өстәгеләргә (КГБга дияргә туры килә) нәкъ менә аның яратып укылуы ошамаганлыгы соңга табарак аңлашылды. Татар тарихы булмаган, булмаска тиеш. Бар икән, ничек тә аны вакларга, таркатырга, оныттырып юк итәргә кирәк!

Кәрим Тинчурин театрына баш режиссёр итеп Рәшит Заһидуллинны куйгач, ул да сүзне шул «Итил»дән башлады. Өйгә килде, аңлатты, агитлады. Театрны «күчмә» халәтеннән чыгарып, стационар хәленә кертер өчен җитди әсәр куясы килүен әйтте. Яшь, актив, ихлас иптәшкә баш тартасым килмәде. Беренче тамаша 1933

елның 1 ноябрендә булды. Рәшит Заһидуллин, романны үзенчә аңлап, үзенчә, яңача куйды. Спектакльдән соң озаклап кул чаптылар, сәхнәне чәчәк бәйләмнәре белән күмеп ташладылар. Сәхнәгә менгәч, артистлар мине кочаклап алдылар, бу спектакль театрыбызның зур уңышы булды, диделәр. Сезнең аркада яңадан тереләдек, исән калдык, дигән сүзләр әйттеләр.

Элек «Күчмә» дип йөртелгән театрның иҗади үсеш юлында бу спектакль чыннан да күтәрелеш буларак бәяләнерме, юкмы — анысын мин әйтә алмыйм. Монда мин әлеге тамашаның

кайбер башка якларына гына игътибар итмәкче булам.

1 ноябрь кичендә безнең Руфина, ягъни минем хәләл җефет, күбрәк вакытын театрның урам ягындагы ишек төбендәрәк уздырды. (Ул дусларына, хезмәттәшләренә чакыру билетлары тараткан булган, аларга игътибар йөзеннән каршылап торуы булгандыр яисә шунда очрашырга сөйләшкәннәрдер.) Беренче чыгуында ул билетсыз басып торган егермеләп кешегә тап була. Кассир: «Билетлар юк, сатылып бетте», — дип җавап биргән икән. Тамаша залына кереп караса, партерның арткы рәтләре яртылаш буш, ди. «Итил суы» куелган башка көннәрдә дә шундый ук хәл кабатланды: кассада билет юк, ди, тамаша залы — яртылаш буш!

1 ноябрь премьерасы вакытында тагын бер сәер хәл була. Төп рольләрнең берсен башкаручы яшь актриса Җәмилә Әсфәндиярова уен вакытында, аяк астына куелган ниндидер каты әйбергә абынып, аягын яралый. Сәхнәдәге уен өчен бөтенләй кирәге булмаган бу каты әйберне кемдер юри куйган, дип әйттеләр спектакль тәмам булгач. «Скорый» чакыртыпмы, үз машиналарындамы, артистканы якындагы хирургия клиникасына алып барып, ярасын бәйләтәләр. Артистка, тамашаны өзмичә, үз ролен тиешенчә башкарып чыга.

К.Тинчурин театрында сәхнәне яктырту системасы компьютерга көйләнгән була. Тамаша барганда кинәт ут сүнә. Спектакль вакытында болай да яктылык белән караңгылык еш алышынып торганлыктан, тамашачы бу сүнүне сизми кала. Режиссёр сизә, шундук компьютер янына килә. Аны кемдер бозып куйган була. Рәшит Заһидуллин яктылыкны кул белән идарә итү пультына барып утыра һәм тамаша беткәнче ут белән үзе идарә итә.*

*Р.Заһидуллин искәрмәсе: «Чынлыкта, бу хәл генераль репетиция вакытында булды: компьютер рәтлебашлы көйләнмәгәнлектән, кинәт эштән чыкты. Премьераны кичектерергә тәкъдим ясадылар. Спектакль уйналачак, дидем һәм идарә пульты янына үзем утырдым».

1986 елның 2 июлендә шул ук Тинчурин театры бинасында Әлмәт театрының гастрольләре булды. Беренче тамаша, беренче премьера буларак, Н.Фәттахның «Сармат кызы Сәринә» дигән тарихи әсәре куелды. Спектакльне театрның баш режиссёры Рөстәм Абдуллаев куйды. Соңыннан ул шундый хәбәр әйтте: сәхнәдә тамаша барганда кемдер театрның яктырту системасын бозган. Режиссёр моны күреп ала, спектакль тәмамланганчы яктылык белән идарә итү пульты янында үзе утырып тора.

Шулай итеп, ул вакытта да режиссёрның сизгерлеге аркасында гына тамаша өзелмичә дәвам итә ала. Тик шулай да «Сармат кызы Сәринә»нең сәхнә гомере кыска булды. Аны берничә премьерадан башка куйдырмадылар. Ниндидер интригалар оештырып, Р.Абдуллаевны Әлмәт театрыннан китәргә мәҗбүр иттеләр.

«Сармат кызы Сәринә»не куярга әзерләнеп йөргән көннәрдә булган бер очрашу истә бик нык уелып калган. Режиссёр, художник Канәфи Нәфыйков, композитор һәм мин безнең өйдә тарихи костюмнар, кораллар рәсемен тикшереп утырабыз. Тавыш — моң остасы — композитор Ренат Еникеев нәрсәдер сөйли дә сөйли. Фикер алыштык, корал, костюм рәсемнәрен без бертавыштан кабул иттек.

Күпмедер вакыттан соң ишетелде: татар рәсем сәнгатендә тарихи жанрны башлап җибәрүче һәм кыю рәвештә дәвам иттерүче Канәфи Нәфыйковны ниндидер билгесез кешеләр тукмап киткән. Каты яраланып, безнең Канәфиебез хастаханәгә кергән. Берничә елдан мин аны тагын очраттым: элеккечә шат күңелле, сабан туе батырлары кебек таза, сау-сәламәт. Тарихчыга тазалык та, батырлык та, кыюлык та һәрвакыт кирәк.

20 июль, 1998 ел

Язманы басмага Н.Фәттахның хатыны ***Руфина Фәттахова*** *әзерләде.*

Фоторәсемнәр К.Тинчурин театры архивыннан алынды.

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Азатны кол итим, дисәң, билгеле,
Юмарт бул, сыйла һәм яула күңелен.

Башым күккә тисен, дисәң син, торып,
Белек белән эшлә, һәр ягың күреп.

Дөньяга җәелсен, дисәң ат-даның,
Мосафирне сыйлау – чарасы аның.

Кинәнеп яшимче, дисәң өзлексез,
Гафиллекне ташла, и, холкы төп-төз.

Гыйбадәттә булыйм, дисәң Тәңрегә.
Иркенчелек бирмә җан һәм тәнеңә.

Тулы изгелеккә җитим, – дисеңме?
Бастыр һәвәсеңне һәм нәфесеңне.

Бер фикер иясе әйбәт сүз әйткән
(Бу сүзне эшкә тот, и холкы күркәм):

Җан һәм тән теләген үтәп барма син.
Башың шуларга кол булып калмасын.

Шуларга баш исәң – яманлык итәр,
Ә көчләсәң – алар килеп баш ияр.

Сүзен кисеп: – Кардәш, – диде Үгделмеш,
– Менә шулай була юньле көнкүреш.

Мин әйтеп бирдем, син тәмам ишеттең
Һәм тыңласаң инде, ниләр әйтерсең.

УЙГЫРМЫШНЫҢ СОРАВЫ

Җавап биреп, әйтте Уйгырмыш сүзен:
– Төгәл ишеттем мин, и холкы төзем.

Соравым бар инде сиңа тагы бер,
Тыңлап, мәсьәләне миңа ачып бир.

Бу кешеләр белән мин аралашсам,
Барышып-килешеп йөрсәм, булып шат,

Алар, әлбәттә ки, ашка өндәрләр,
Вә үзләре дә еш кына килгәләр.

Ничек барып анда, ничек җийәргә,
Һәм, үзем чакырсам, нәрсә дияргә?

Боларны миңа әйт, булсын билгеле,
Белемеңнән бир бу хакта өлеш.

ҮГДЕЛМЕШ АШКА ЧАКЫРУ ТӘРТИБЕН СӨЙЛИ

Үгделмеш җавапта әйтте: – Кардәшем,
Үзара кирәге була ул ашның.

Төрле-төрле кеше чакырыла ул
Һәм кунак ашы да төрле була ул.

Дөньяга җәелсен, дисәң ат-даның,
Мосафирне сыйлау – чарасы аның.

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.

Шулардан берседер – никах, туй ашы,
Тагын сөннәт ашы һәм бәби ашы.

Йә иш-түшне тиңдәш кеше чакыра,
Олы-кече, якын, кардәш ашына.

Җеназа ашы – бер кеше күмгәндә,
Аш бар бер шәрәфле ат бирелгәндә.

Боларның һәркайсы аш-сулы була,
Барыргамы-юкмы, тик үзең уйла.

Чакырсалар нәсел-нәсәп һәм дус-иш,
Барып шунда кеше хәлләрен белеш.

Яшьләр-ятлар булса әдәпкә өйрәт –
Ашау-эчү күпме һәм ничек кирәк,

Якын, күрше, әшнә сине хөрмәтләп,
Яки дини бәйрәм үткәргән рәттән

Сине чакырсалар, күңелләрен күр,
И, егет, аларны барып сөендер.

Синең өчен махсус зияфәт булса,
Нишләр идең андый ашка бармыйча?

Бүтән зияфәтләр булса, очраклы,
Андыйларга инде бармаган яхшы.

Ярым-йорты булса утырыш-торыш,
Күңелеңә авыр булыр, и, тугрым.

Эчеп исерергә җыелган табын
Ашыңны сеңдермәс, чирләтер тагы.

Ни ди, ишет, ашау дәртен тыючы,
Тамак-бугазына хуҗа булучы.

«Нәфесеңне сакла кеше алдында,
Түбәнлеккә барма, ашка кол булма.

Күпне күрдем – илдә абруйлы ирләр –
Тамак әсирләре түшәлде җиргә.

Күп бай күрдем – тамак колы иделәр,
Шуннан бөлеп ярлы булып үлделәр».

Тамакка табынма – аның төбе юк,
Тамаксау бәндәнең ибе-юне юк,

**Кеше алдындагы нигъмәтне алма,
Шулай ук, ашыңны кешегә салма.**

Каю төрле ашка барган булсаң да,
Ашавыңда тәртип сакла, бел чама.

Хая белмәс берәү – заңсыз, гадәтсез –
Әдәплене күреп аптырый хәтсез.

Табыныңда иң өлкән тәүләп суза кул,
Соңыннан – кем тели, әдәплелек шул.

Тәүдә бисмилла әйт, суз уң кулыңны,
Табындагылар кебек бер бай булырсың.

Кеше алдындагы нигъмәтне алма,
Шулай ук, ашыңны кешегә салма.

Пычак, чәнечкене югары тотма,
Сабырсызланма, үз-үзең онытма.

Туйсаң да әкренләп чәй эч, аша аш,
Юкса күршең сиңа карап, ашамас.

Һәр эшкә куела тәртип, канун, заң,
Йөзең якты була әдәпле булсаң.

Авызга алганны нык чәйнә. Ашка,
Эссе, дип, пуф та пуф өреп маташма.

Шудырсаң тустакны, үзеңә тартсаң,
Кылыксызланудан абруең артмас.

Әдәпсезлек кылма, буйсын әдәпкә,
Әдәпсезлек зыян сала адәмгә.

Ни шәп әйткән, ди бер әдәпле кеше:
«Әдәп ул — җаныңның кипрәне, тышы».

Һәр эшкә куела тәртип, канун, заң,
Йөзең якты була әдәпле булсаң.

Холыксыз, кылыксыз, рәт белмәс кеше,
Адәм арасында боза үз эшен.

Рәхәтләнеп ашап, ашны макта син,
Хуҗабикә моны күреп, шатлансын.

Кеше күп тырышып ашын хәзерли,
Өнәмәсәң ашын, калыр хәтере.

Күңел хушлыгын бик сөйгән бер инсан
Болай ди (сүзенә тирән мәгънә сал):

«Кеше күңле юка – пыялага сан,
Игътибарлап кылан – сыныр, кагылсаң»[1].

Хәтерен калдырсаң, татулык бетә,
Якынлык та китә, шулай ук, эш тә.

Якынлык теләсәң, күңелен күвер,
Күңелен сындырсаң, дуслыктан түңел.

Әдәп-хая саклап ашны аша – җий,
Ни әйткән бу хакта акыллы бәхши:

«Әверелер артык ашың агуга,
Күп ашаучан тарыр чиргә-ауруга.

Тамактан чир керә һәм шуңа күрә
Ашау-эчү белән мавыкма бер дә.

Чир ул — ашамсаклык, хәлсезләндерә,
Дәвасын тапмасаң, үлем күндерә».

Шәп әйткән бу хакта бер табиб-хәким
(Аның сүзен инкяр итәлмәс һичкем):

«Үлем хәбәрчесе хасталык – чирдер,
Үлемне хасталык ияртеп йөрер».

Авыру азагы – үлем торкагы,
Үлемнең исә юк һич яхшы ягы.

Кешемен, диюче Адәм угланы
Белер эссе-суык, яхшы-яманны.

Үз чамаңны белеп, кирәкчә аша,
Куеп тор бер читкә, аш ярашмаса.

Хәтерен калдырсаң, татулык бетә,
Якынлык та китә, шулай ук, эш тә.

Эссе булса, салкын нәрсә тап шундук,
Салкын булса, тизрәк булдыр җылылык.

Егет чагың, гомер язың булганда
Салкынга бар, эссе нәрсә кулланма.

Яшең кырыклардан узса, көз инде,
Тәнеңне җылытып кан йөргез инде.

Яшең алтмыш – гомер кышы чагында
Җылы куллан, суык эшкә алынма.

Сусыл эссе кирәк коры суыкта,
Шушы ике тәнне сәламәт тота.

Дымлы суык исә җаныңа тисә,
Коры җылы шуңа бәрабәр киртә.

Суыктан интексәң, җылы төшкә күч,
Эссе булып китсә, салкын сулар эч.

Эссе дә, суык та артык булмаса,
Үзең шуңа җайлаш, яшә уртача.

Шулай итеп яраш табигатеңә,
Яшим дисәң исән һәм әйбәт кенә.

[1] Хәзерге татар мәкале – «Кеше күңеле — пыяла, каты тотсаң, уала».

Ни ди, ишет, табиб-утачы сүзен,
Вә сүз мәгънәсенә төшен, и, кузый.

Синең вөҗүдең дүрт гонсырдан тора[2]:
Алар — кызыл, сары, ак һәм кап-кара.

Болар бер-бересенә үзара дошман,
Тиңдәшлек бозылса, аурулар шуннан.

Шул көчләр тиңлеген сакларга кирәк,
Моның өчен белеп аша, и, зирәк.

Кешенең хайваннан аермасы шул:
Кеше эшләп ашый, кия, и угыл.

Ни дигән, әнә, бер ак сакаллы карт
(Хәтереңә калдыр, колагыңа кирт):

«Ир урнын белмәсә, кырыкка җитеп,
Тәмам хайвандыр ул – бүтән ни әйтим».

Акылга килмәсә, үзе кичереп,
И, иплем, бармы соң монда кешелек?

Күп күреп нәтиҗә ясый белмәсә,
Кеше түгел, терлек кебек бернәрсә.

Бабай яшендәге сабый дигәндәй,
Хайван, дип атарлык була ул бәндә.

Дөрес әйтә барча табиблар, баксаң:
«Күбрәк елмаерсың, азрак ашасаң».

Исәнлек теләсәң һәм дә чирсезлек,
«Аз» дигән даруны бел син иң элек.

Тынычлык-шатлыкта яшим, дисәң дә,
Бигрәк саклан син «тел» дигән иттән дә…

ҮГДЕЛМЕШ УЙГЫРМЫШКА АШКА ЧАКЫРУ КАГЫЙДӘЛӘРЕН ӨЙРӘТӘ

Кунаклар чакырсаң бермәл әгәр син,
Кара кемлекләрен, кылыгын, эшен.

**Табында сыек аш азрак булмасын,
Тамакка төер таш булмасын ашың.**

Кашыгаяк, тирке[3], кием, өй эчең
Һәм ашың начар булмасын һичберсе.

Матур савытлардан татлы ашамлык
Ашасын кунаклар, саклансын зәвык.

Бел – ашка чакырмау тик бер сөйләнер,
Чакырсаң, сүз китәр, йөзгә төрләнер.

Аш-суларың ару, күп, әйбәт булсын,
Кунакларың ашап канәгать булсын.

Дус-иш, карендәшләр, ерак һәм якын –
Берсен дә калдырма, хакла үз хакын.

Килгәннәре килер, әгәр килмәсә,
Чакыргач, үпкәсе калмый, лабаса.

Яман хис бар – тамак өчен үчегү,
Кайберәүләр махсус килә кичегеп.

Шуны кара – һичкем ашсыз калмасын,
Кичеккәнгә өстәп бир тиеш ашын.

Ашагачтын ашны чәй бир табынга,
Эчеп бетерсәләр, өстә тагын да.

Ашамлыкка һәрчак кирәк эчемлек.
Һәм ашап-эчүдә саклансын тиңлек.

Табында сыек аш азрак булмасын,
Тамакка төер таш булмасын ашың.

Кирәк бозлы су бир, кирәк эссене,
Табынга гөләп куй – төрле төслене[4].

Тагын нинди ашлар табында була,
– Сорама син миннән, белгечтән сора.

Ашагач өлкәннәр, киткәч табыннан,
Кечеләргә табын яса тагын да.

Дәвамы бар ■

[2] Гонсыр – борынгы фәлсәфә буенча «төп элемент». Алар дүрт темпераментка тәңгәл: кызыл – сангвиник, сары – холерик, аксыл – флегматик, кара – меланхолик.
[3] Тирке – «савыт-саба комплекты, поднос» (татар сөйләшләрендә хәзер дә бар).
[4] Гөләп — табын суы — асылда «гөл суы» дигән сүз. Төп текстта гөләпнең — табын суының — төрле төрләре, атамалары китерелә.

«МӨХӘММӘДИЯ» МӘДРӘСӘСЕ КАЛЕНДАРЕНДА (1905)
АКМУЛЛА ШИГЫРЬЛӘРЕ

Мифтахетдин Акмулла
(1831-1895)

***

Мулла булса, кибер[1] булмай, куркак булсын,
Дин юлында җилмаядай[2] җуртак булсын —
....
Дингә зирәк, дөньясына журтак булсын.

Басылу вакыты: 10 март, 1905 сәнә

***

Гыйлемнән берәүгә бераз керсә,
Башыны күтәрә күккә йитсә.
Гыйльме кямиль булган саен тәвазыйглы,
Бөтен фәннән укылып китап бетсә.

***

Адәм улы йөземнең сабагыдай
Гыйлем азда, чәчәк атыр заманыдай
Сылкымланып пешеп йитсә башын бөгәр
Тулып йиткән көнбагыш табагыдай.

Басылу вакыты: 14 март, 1905 сәнә

***

Гыйлем илә мәгъмур ула дөнья вә дин,
Хөсне холыклы улмалы әмма хатын.

Басылу вакыты: 15 март, 1905 сәнә

Гыйлемнең сәмәрасын[3] тиз көтәбез.
Йимеше коелсын, дип селкетәмез.
Корт ашаганнан башкасы төшерелмәс,
Пешеп җитмәгән җимеш файда бирмәс.
Өлгреп җитеп, кызарып тулып җитсә,
Гыйльмемемез дә шулай ук: яхшы белсәк,
Кәмаленә йиткәнче укый бирсәк.
«Әт-таләби, — диде рәсүл, — минәл мәкъд, —
Гомереӊ килеп йитсен, — «аләл ләхед».

Басылу вакыты: 18 март, 1905 сәнә

[1] Кибер — тәкәббер.
[2] Җилмаядай — «яхшы ат» мәгънәсендә.
[3] Сәмәрасын — җимешен.

ШӘҺИД МӨХТӘРӘМ АКМУЛЛА ХӘЗРӘТЛӘРЕНЕҢ ЗАМАНАДАН ШИКАЯТЬ КЫЛЫП ЯЗГАН КАСИДӘСЕ

Адәмнән һава(лану) калмас, гариб булмай
Фокарә сөхбәтенә кариб[4] булмай
Гадәте — я истихза, я хәкарәт,
Сүз сөйләмәс, берәүне җәрех кылмай.
Берәүгә дөнья яхшы хасыйл булса,
Морадына һәвәсенчә васыйль булса,
Нәфсе аның Фиргавендәй дәгъва кылыр,
Бер фетнә, каза күреп, басылмаса.
Бүтәндә хасиятне бар дип белмәс,
Үзенә хөсне занны хасер кылмас
Камильлекне фәкыйр күрер. Һәм, билгакс,
Үзенә адәмне сүзеннән адәм сынар,
Бер-берсен кимсетүгә адәм комар
Кара чебен сау җиргә күз салмайды.
Бар булса җәрх — кутыр анда кунар.
Инсафтан бер мыскал юк эшемездә,
Кинә, хөсет, фәсад тулган эчемезгә.
Һөнәремез я тагаид, я истихфаф
Үз күргән эшемез юк исемездә.
Раббание голамада — ятлау да юк,
Белә торып, бүтән юлга атлау да юк.
Вә ләкин күңелләре пәлид ирер, —
Һәр кемне хурлауга бар, мактауга юк.
Якын барсаң, тимерче гүргәнедәй, —
Ул сине керләүгә бар, пакьләүгә юк.
Кара май чиләгенә тиеп китсәң.
Кара итеп тапларга бар, акларга юк.
Хатаән аяк таеп кулап китсәң,
Башыңа басып атлауга бар, туктарга юк.
Зәррәдәй гаебеңне күрә калса,
Гаурәтеңне ачуга бар, ачмауга юк.
Һәр кемне «мулла» димез, алдаганда,
Чын мулла аз табылыр таңлаганда.
Әмма, — яхшы, Аллаһга масдак канда? —
Күз салып, хакыйкатьне аңлаганда.
Хашиятенең галәмәте шундый заһир,
....
Җүнле килсә, «элү»гә әзер тора,
Кармагы ерак түгел, бармагында.
Яхшы көзге йөздә булганны күрсәтер,
Галәмәт ахирәтең эше башка:
Әүвәл, кавеллә әзяланыр, кармаганда,
Галәмәтне белерсез, бәхет кунса,
Гыйззәтне горурлыкка салмаганда.
Дәрт белән, мәсҗедтә ялгыз калып:
«Раббәна, зәлләмна...» дип зарланганда,
Бавырсак татлы булыр барлаганда.
....
Ярар иде үзегезне карасак без,
Голәманың сәмәрасын арасак без.

Басылу вакыты: 1 апрель, 1905 сәнә

***

Гыйлемнең җимешләре бик татлыдыр.
Аның сине симертүе кыйммәтледер.
Бу сүзнең дөреслеген чыгып кара
Галимнәр арасыннан, фазыйл ара, —
Шушында бик беленер яхшылыгы,
Гыйлемнең сәмәрасы, затлылыгы
Коръәндә: «Коль ястева», — диде мактап,
«Әгъләмна ягълимун» — ирер маһитаб.
Бәхәссездер: «Әлләзинә ля ягъләмун»
Тәнәввел кылганнар «ляяфһемун»...

Басылу вакыты: 21 апрель, 1905 сәнә

М.Акмулланың шигырьләрен басмага
***Мәсгуд Гайнетдин** әзерләде.*

[4] Кариб — якын.

БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫНА ЙӨЗ БЕЛӘН

Шамил Рәкыйпов

Татар совет яшьләр-балалар әдәбияты ниндирәк юнәлештә үсә, аның нинди уңышлары, нинди кимчелекләре бар соң?
Бу сорауга җавап бирү өчен соңгы елларда чыккан әсәрләргә күз салырга кирәк. Әйе, соңгы елларда язучыларыбыз балалар һәм яшьләр тормышын чагылдырган кызыклы гына проза әсәрләре иҗат иттеләр.

Бу уңайдан Г.Гобәйнең «Без үскәндә», Л.Ихсанованың «Саралан малайлары», А.Расихның «Маҗаралы повестьлар», И.Туктарның «Батырлыкта матурлык», Х.Сарьянның «Әткәм һөнәре» кебек әсәрләрен күрсәтергә була.

Яшь каләмнәрнең балалар әдәбиятына кыю атлаулары да күңелле күренеш. Р.Батуллин, Т.Миңнуллин, А.Тимергалин, М.Харисов, А.Хәсәнов һәм башкалар шундыйлардан санала.

Ләкин балалар әдәбиятының бүгенге торышы заман таләпләренә җавап бирерлек түгел әле. Балалар өчен югары идеяле, сәнгатьчә эшләнгән әсәрләр аз, ә укучыларда аларга булган ихтыяҗ үскәннән-үсә бара. Берәүгә дә сер түгел, олы буын язучыларның кайберләре балалар әдәбиятын үги итә башлады.

* Узган санда басылган «Бер бәйләм беркетмә»дә әлеге язма телгә алынган иде. *(Редакция искәрмәсе.)*

«Йөзек кашы» белән балалар, яшүсмерләр күңелен үзенә тарткан Ф.Хөсни, «Агыйдел»е белән сихерләгән М.Әмир, «Катя Сорокина»сы белән сизгер булырга, Ватанны яратырга өйрәткән И.Гази һәм башка язучыларыбыз соңгы елларда балалар өчен аз яза.

Халкыбызның бөек шагыйре Г.Тукай балалар алдында да үзен җаваплы итеп тойган һәм кыен шартларда да якты буяулар белән тулы, энҗедәй җемелдәгән «Эш беткәч уйнарга ярый», «Фатыйма белән сандугач», «Мияубикә», «Шүрәле», «Таз», «Алтын әтәч», «Япон хикәясе», «Исемдә калганнар» кебек үлемсез әсәрләрен язган.

Инде 1940 елларга күз салыйк. Бу чорда Тукай традициясен дәвам иттерүчеләр шактый булган. Вакытлы матбугат битләрендә А.Алиш, Ф.Хөсни, А.Әхмәт, Җ.Тәрҗеманов һәм башка язучылар аеруча актив катнашканнар. А.Алишның «Пионер каләме» журналында басылып чыккан «Боз тавы», Х.Кавиның «Унбер республика буйлап» исемле юлъязмалары, Ә.Исхакның «Өч кыз турында әкият»е — шундыйлардан.

М.Җәлил, Ә.Фәйзи, Х.Туфан, С.Хәким, Н.Баян, Ә.Исхак, Ш.Маннур, Г.Хуҗи, М.Вәдүт, Н.Дәүли, З.Гәрәй, Ә.Юныс һәм башкалар Ленин комсомолының 20 еллыгына багышлап «Яшьлек юлы» исемле поэма язган. Поэмада колхоз комсомолларыннан тракторчы Шакир, бригадир Алсу һәм гражданнар сугышы ветераны Соколовның яңа тормыш өчен көрәше сурәтләнә. Поэмага укучылар югары бәя бирә. Ул башта «Пионер каләме» журналында (№10, 1939 ел, 18-21 битләр), аннары китап булып басылып чыга. Мондый матур традицияләребез кая китте соң әле. Аларны яңарту турында уйланырга кирәктер.

Совет властеның 50 еллыгы, комсомолның 50 еллыгы, ниһаять, бөек Ленинның 100 еллыгы якынлашып килүе һәр язучыга яңа зур җаваплылык йөкли, иҗат активлыгын тагын да көчәйтүне таләп итә.

Безгә революцион традицияләрне дәвам итүче һәм ишәйтүче, ил, халык интересларын шәхси интереслардан өстен санаучы, дөньяга материалистик күзлектән карарга өйрәнгән яшьләр кирәк. Кешедә дөньяга карашның нигезләре яшьтән үк салына. Бу эштә гаилә, мәктәп, пионерлар отряды, комсомол оешмасы һәм язучылар төп рольне үти. Шушы мөһим мәсьәләләр бөтен тирәнлеге һәм нечкәлеге белән әдәбиятыбызда нинди чагылыш таба соң? Әйтергә кирәк, без әле мәктәп тормышына тирән үтеп керә алмыйбыз, элеккечә һаман чебиләр, этләр, күбәләкләр турында гына язабыз.

Балаларда кешегә сизгер караш тәрбияләү мәсьәләсе дә әдәбиятта һаман киң чагылыш таба алмый әле бездә. Бик мөһим, бик кыйммәтле бу сыйфатка ия булмаган егет яки кыз кешегә, аның идеалларына, карашларына, хезмәт җимешләренә зур ихтирам белән карый алмаячак.

Дөрес, бу юнәлештә безнең язучылар кыл да кыймылдатмый, дип әйтү хата булыр иде. Ләкин әсәрләрнең фәлсәфи тирәнлеге чамалы икәнен абайламаска мөмкин түгел.

Быел басылып чыгачак «Югары оч малайлары» (Г.Сәгыйдуллин), «Саралан малайлары» (Л.Ихсанова), «Күл малае» (Э.Касыймов), «Бурзайлар командасы» (Г.Мөхәммәтшин), «Таган» (М.Кәрим) исемле китапларга күз салыйк. Әйбәт китаплар. Ләкин һәммәсендә дә диярлек охшаш ситуацияләр һәм әйтерсең, сүз куешканнар, мәктәп, пионерлар отряды, комсомол оешмасы читләтеп үтелә. Беркемгә дә сер түгел, язучылардан, шагыйрьләрдән романтикага бай, психологик кичерешләрне гәүдәләндергән дулкынландыргыч әсәрләр көтәләр. Шуңа күрә язучыларыбыз мәктәп, техникум, югары уку йортлары ишекләрен ешрак ачып керсеннәр, андагы яшьлек шау-шуы, бәхет, матурлык, гражданлык, батырлык һ.б. мәсьәләләргә карата вакыт-вакыт кабынып китә торган кайнар бәхәсләрне ешрак тыңласыннар һәм яшь характерларны ачып, бик күпләрне дулкынландырган проблемаларны сәнгатьчә тасвирлап, кызыклы әсәрләр иҗат итсеннәр иде.

Илебез халыклары, КПССның XXIII съезды карарлары белән рухланып, коммунизм төзү эшен яңа дәрт, яңа илһам белән дәвам итә башлады. Тормыш диалектикасы кушканча, бу зур эш тигез генә, көрәшсез генә бармый. Ә көрәштә җиңүчеләр дә, җиңелүчеләр дә, батырлар да, елаклар да очрый.

Әмма шунысы бәхәссез: елаклар — бик аз, батырлар — күпчелек. Яшьләр шундый батырлардан үрнәк ала, әдәбиятта шундый геройларның сурәтләнүен таләп итә. Урынлы таләп: безгә хәзерге заман Корчагиннары кирәк!

Андыйларны кайдан алырга, дип сораулары бар. Алар безнең белән бер сафта, арабызда яши. Комсомолның XY съезды делегаты, яшь белгеч Рим Зарипов, Социалистик Хезмәт Герое Рәүф Әһлиуллин, Себер нефтен үзләштерергә киткән Владимир Чернохубов, Ленин орденлы яшь терлекче Валя Александрова, урыныннан кузгала алмаса да, читтән торып вузда укучы һәм берсеннән-берсе ялкынлы әсәрләр иҗат итүче яшь шагыйрь Фәнис Яруллин, тыныч көннәрдә Александр Матросов батырлыгын кабатлап иптәшләрен үлемнән саклап калган комсорг Владимир Грибиниченко, ун тапкыр бөтендөнья рекорды куючы, парашюты ачылмау сәбәпле үлемгә дучар ителгән, әмма комсорг Ибраһим Фәсхетдинов җитәкчелегендә яшь спортчылар кайгыртучанлыгы белән исән калган Юрий Беленко һәм башкалар...

Балаларны һәм яшьләрне интернационализм, патриотизм рухында тәрбияләүдә дә алдыбызда зур эшләр тора. Соңгы елларда әдипләребез балалар өчен Ватан сугышы темасына багышланган әсәрләр язмый башлады. Китап сөючеләр тарафыннан хәрби, бигрәк тә документаль жанрга ихтыяҗ артканнан-арта бара.

Республикабыздагы һәр мәктәптә диярлек «Кызыл эзтабарлар», «Кечкенә җәлилчеләр» әдәби түгәрәкләре эшли. Аларның шактыенда революция һәм Бөек Ватан сугышы каһарманнары турында кыйммәтле мәгълүматлар тупланган. Мисалга Бондюг районының 1 нче номерлы мәктәбен алыйк (директоры — иптәш Щербаков). Бу мәктәп үз стенасы эченнән алты лачын — алты Советлар Союзы Герое үстереп чыгарган. Ни өчен шушы мәктәп, аның горур лачыннары турында «ашаганда кашыкны куеп укырлык» әсәрләр язмаска?!

Хәер, геройлар турында сүз чыкса, алар истәлеге алдында әдипләребезгә күпмегәдер кызарырга туры килә: татар халкының 167 батыры тормышы, аларның мәктәп еллары, сугышчан юллары бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Ә бит аларның һәркайсының биографиясе яңа гүзәл повестьлар һәм романнарга нигез була алырлык!

Балалар әдәбиятына йөз белән килик, дуслар!

(«Тынгысыз каләм», 1970) ■

Кәрим Тинчурин. 1930 нчы еллар

Күн чемоданда сакланган хәзинә

Рабит Батулла

Дәһшәтле 1937 елның 17 сентябрендә Кәрим Тинчуринны кулга алырга килүчеләр фатирдагы бөтен нәрсәне пыр туздырып тентү үткәрә. Драматургның хатыны Заһидә ханым бер кара чемоданны, башкаларга сиздермичә генә, үкчәсе белән карават астына этеп кертә һәм ятак өстендәге пәрдәне шудырып, каплатыбрак куя. Шулай итеп ул Кәрим Тинчурин архивының бер өлешен яшереп-саклап кала. НКВДчылар капчыкларга төяп алып киткән башка кулъязмалар һәм барлык кәгазьләр мәңгелеккә югала.

Кәрим Тинчурин архивының могҗиза белән сакланып калган өлешендә кайчандыр театрда куелган, әмма моңарчы беркайда да басылмаган берничә кулъязма бар. Аларның берсе «Зәңгәр палас» исемле тәрҗемә әсәре. Тинчуринның үз кулы белән язылган бу әсәрнең төп нөсхәсе миндә саклана. Аны гарәп хәрефләреннән кириллицага күчергән идем, ул «Кәрим Тинчурин. Тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык» исемле китапта 2011 елда басылды. Икенчесе, «Хан кызы Турандык» исемлесе, итальян драматургы иҗат иткән «Принцесса Турандот» әсәренең ирекле тәрҗемәсе — Казан курчак театрында һәм Галиәсгар Камал театрында куелды, шулай ук алда исеме аталган китапта басылып чыкты. «Каракүз», «Нәни абый» исемле пьесаларын башка кулъязмалар белән бергә Милли китапханәгә тапшырдым. Тинчуринның «Кызык повар» исемле тагын бер әсәре Кәрим Тинчурин театры китапханәсендә саклана. Ул пьесаны театрның баш режиссёры Рәшит Заһидуллинга үз кулларым белән биргән идем. Кулъязмалар арасында «Стан» исемле пьеса да бар, ләкин ул бик буталчык, аның нөсхәләре, төзәтмәләре күп. Бу әсәр турында Заһидә ханым Тинчурина:

— «Стан» — социаль заказ белән языла башлаган әсәр, Кәрим аны теләр-теләмәс кенә яза башлаган иде, шуңа күрә очына да чыга алмады, — дигән иде.

Менә, ниһаять, Кәрим Тинчуринның киң җәмәгатьчелеккә нәмәгълүм «Каракүз», «Нәни абый» әсәрләре дә дөньяга чыгар вакыт җитте. Тәүге мәртәбә! Бу эштә аеруча көч сарыф иткән Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсе хезмәткәрләренә, бигрәк тә Раиф Мәрданов белән Ирек Һадиевка чиксез рәхмәтләремне юллыйм.

Бәрәкәтле мирас ядкярләре

Раиф Мәрданов

Күренекле татар драматургы, артист һәм режиссёр Кәрим Тинчуринның (1887-1938) иҗади мирасы бай һәм бәрәкәтле. Аның моңарчы басылмаган, күп укучыларга билгесез әсәрләре дә бар һәм соңгы вакытта аларны өйрәнү, бастырып чыгару дәвам итә[1].

Замандашыбыз, Татарстан Республикасының халык язучысы Рабит ага Батулла — Кәрим Тинчуринның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүгә, саклауга, танытуга зур өлеш керткән фидакяр шәхес. Ул Кәрим Тинчуринның гарәп язуындагы биш кульъязмасын 2014 елның 9 октябрендә Татарстан Милли китапханәсенә бүләк итеп бирде. Мәшһүр драматургның үз кулы белән язылган бу әсәрләр мәдәниятебез тарихы өчен аеруча кыйммәтле һәм кадерле ядкярләр.

Тинчуринның китапханәгә тапшырылган кульъязмалары түбәндәгеләр:

1) Чит илләрдә: хыялый комедия. А.Толстой һәм К.Чапек буенча язучысы К.Тинчурин. 1925 ел. 71 кәгазьдә;

2) Нәни абый: комедия. 4 пәрдәдә. [1925 ел]. 42 кәгазьдә;

3) Каракүз: борынгы тормыштан музыкалы мелодрама. 4 пәрдә, 5 күренештә. 1929 ел. 68 кәгазьдә;

4) Туран иле: мәзәк. [1930 ел]. 8 кәгазьдә;

5) «Ак каен» шигыре. [1920 нче еллар]. 1 кәгазьдә. Елы билгесез.

Милли драматургиябез классигы Кәрим Тинчурин иҗат иткән әлеге әсәрләрне, һичшиксез, белгечләр әтрафлы өйрәнер. Ихтимал, режиссёрлар аларны сәхнәләштерер дә, чөнки моннан 85-90 еллар элек иҗат ителгән булсалар да, бу әсәрләр хәзерге тамашачыны кызыксындырырлык һәм уйландырырлык куәткә ия. «Каракүз» һәм «Нәни абый» әсәрләре шундый максатларны күздә тотып гамәлдәге татар язуына күчерелде, басмага тәкъдим ителде.

***

Кәрим Тинчуринның «Каракүз» мелодрамасы «Зәңгәр палас» драмасының төп калыбына охшаш (шуны искәртергә кирәк, «Зәңгәр палас» драмасының тексты 2007 һәм 2011 елларда басылып чыкты[2]).

Рабит Батулла мәгълүматы буенча, К.Тинчуринның «Зәңгәр палас» әсәре «XX гасырның егерменче еллары башында шактый зур популярлык казанган урыс драматургы Любовь Столицаның «Голубой ковёр» әсәре буенча язылган»[3].

Драматург Л.Н.Столица (1884-1934) «Голубой ковёр» исемле шигъри-романтик драмасын 1916 елда Мәскәүдәге Камера театры өчен махсус язган һәм ул режиссёр А.Я.Таиров (1885-1950) тарафыннан 1917 елның гыйнварында сәхнәгә куелган.

[1] Кәрим Тинчурин һәм татар сәнгате: Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе материаллары = Карим Тинчурин и татарское искусство: материалы Всероссийской научно-практической конференции / [төз. һәм фәнни мөх. Р.Исламов]. — Казан, 2007. — 336 б.; Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / [төз.: И.Һадиев, Р.Батулла]. — Казан: Җыен, 2011. — 688 б.

[2] Кәрим Тинчурин һәм татар сәнгате... — Б.238-333; Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык... — Б.140-221.

[3] Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык... — Б.422.

Урыс драматургиясе тарихы белгечләре тарафыннан «Голубой ковёр» пьесасы, гәрчә андагы баш геройлар һәлак булса да, әлеге авторның иң якты драма әсәре, дип бәяләнгән. Л.Столица 1918 елдан соң гаиләсе белән мөһаҗирлеккә киткән һәм Болгариянең София шәһәрендә яшәп, шунда дөнья куйган.

Кәрим Тинчурин иҗат иткән «Зәңгәр палас» пьесасының премьерасы 1923 елның 15 апрелендә булган[4]. Премьера уңаеннан галим һәм әдип Гали Рәхимнең (1892-1943) зур мәкаләсе басылган. Ул «Зәңгәр палас»ны *«...бу кышта куелган әйберләр арасында аерылып тора торган, үзенә бертөрле (оригинальный) әйбер. Бу әсәр бер тарихи пьеса, дип уйланмасын. Ул тарихи шәхесләрне һәм тарихи вакыйгаларны тасвир кыла торган тарихи драма түгел, бәлки хыялый һәм халис рухи (психологический) бер әсәр»*[5] дип билгеләгән. Мәкалә авторы әсәрдәге типларның характеры Шекспирча ачылган һәм Тинчурин шигъри текстны уңышлы тәрҗемә иткән, дип тә бәяләгән.

«Зәңгәр палас» драмасының 1923 елда театрда уйналуы уңаеннан урыс телендә чыккан башка бер мәкаләдә К.Тинчурин әсәренең мөстәкыйль булганлыгы катгый итеп әйтелгән: *«Недавно в Татгостеатре состоялся бенефис главного режиссёра Татдрамы Карима Тенчурина. Ставилась его же драма «Голубой ковёр», написанная по сюжету драмы Л.Сталицы того же названия, но имеющая мало общего с ней. По содержанию текста основная идея «Голубого ковра» К.Тенчурина совершенно различна от основной идеи драмы Л.Сталицы... Драма К.Тенчурина также, как драма Л.Сталицы имеет символический характер; событие происходит на историческом фоне жизни дворца татарских ханов XIV века; но герои — не исторические личности»*[6] (орфография һәм пунктуация оригиналдагыча бирелә. — Редакция).

«Нумерсыз урындык» имзасы белән язган автор тарафыннан «Зәңгәр палас» драмасының 1925 елда куелуы матбугатта яктыртылган[7]. Ә ул чорда андый имза белән Фәтхи Бурнаш язганлыгы мәгълүм[8]. Мәкаләдә язылганга караганда, 1925 елның 1 мартында актриса Фатыйма Ильская бенефисында «Зәңгәр палас» уйналган, рольләрне Ф.Ильская, Уральский, Камал III, К.Шамил, Камская, Араповалар башкарган. Мәкалә авторы әсәрнең уңышсыз һәм кимчелекле яклары дип, шигъри текстның җөмләләре катлаулы һәм гарәп-фарсы сүзләре күплеге, монологларның һәм, гомумән, тамашаның озын булуын күрсәткән. Мәкаләдә «Тинчурин иптәш киләчәктә бу әсәрен озаграк утырып эшләсә, бәлки, без көткән нәрсә туар, дип уйлыйбыз» дигән теләк ирештерелгән. Кәрим Тинчурин, үз нәүбәтендә, шушы теләкләрне дә исәпкә алып, яңартылган «Каракүз» мелодрамасын иҗат итәргә алынгандыр, дип уйларга нигез бар. Шуны да искәртергә кирәк, 1931 елда Татарстан әдәбият һәм нәшрият баш идарәсе тарафыннан К.Тинчуринның «Зәңгәр палас» драмасын, башка күп кенә пьесалар белән беррәттән, сәхнәдә уйнау тыелган[9].

Тинчуринның «Зәңгәр палас» драмасы төп каһарманнарның үлеме белән тәмамланган. Ә «Каракүз»нең сюжеты башкача,

[4] Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык... — Б.14.

[5] Рәхим Г. «Зәнгәр палас» // Кызыл Татарстан. 1923. — 20 апрель. Халис — саф.

[6] Ибрагим. «Голубой ковёр» (в Татгостеатре) // Известия ТатЦИКа. — 1923. — 1 мая.

[7] «Нумерсыз урындык». «Зәнгәр палас» // Кызыл Татарстан. — 1925. — 4 март.

[8] Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык... — Б.617.

мавыктыргычрак корылган, комик күренешләр белән баетылган. Аның текстында шигъри һәм чәчмә сөйләм аралаштырып бирелгән. Ике әсәрдәге кабатланган урыннар (җырларда) булган кебек, аермалар да шактый. Һәрхәлдә, «Каракүз» мөстәкыйль әсәр буларак иҗат ителгән. Ул төп каһарманнарның ирекккә качуы белән тәмамлана.

Кәрим Тинчуринның хәләл җефете Заһидә Тинчурина үз хатирәләрендә «Каракүз»не драматургның халыкка билгесез ун-унике әсәреннән берсе буларак искә ала[10].

«Нәни абый» әсәренең кульъязма тексты тулы түгел, аның ахыргы өлеше язылып бетмәгән. Әлеге дәфтәр, ихтимал, Кәрим Тинчуринның иҗади хезмәте дәвамында эшкәртелгән яисә үзгәртелгән текстларының берседер, дип уйларга мөмкин. Ләкин тулы булмаса да, бу пьесаның мәгълүм өлешеннән шактый тулы манзара күзаллана.

Заһидә һәм Кәрим Тинчуриннар. 1919 ел

Галим Һәнүз Мәхмүтов К.Тинчуринның «Нәни абый» комедиясе аның «Ятлар» һәм «Шомлы адым» исемнәрендәге драмаларыннан үзгәртелгән, дип язган фикер[11] белән килешеп булмый. Чөнки әйтелгән әсәрләрнең уртак ягы — катнаш никах проблемасының үзәккә куелуында гына. Сюжетлары төрле.

«Нәни абый»да әлеге мәсьәлә коммунистлар партиясе әгъзасының атеистлыгы белән бергә үрелгән. Әсәрдә шулай ук 1920 нче елларда ук тамыр җәйгән яшь совет бюрократиясенең фаш ителүе дә мөһим. Йорт идарәсе җыелышының барышы, канцеляриядә эшнең оештырылу һәм үтәлеш рәвешләрен драматургның оста итеп тасвирлавы сокландыра. К.Тинчурин пьесасында үзәккә куелган, татарча бихисап хаталар белән язылган элмә такта проблемасы безнең заманга аваздаш. Комедия каһарманнарының кайбер типлары да хәзерге тормышка ят түгел.

Пьесаның ундүртенче күренешендә «Әүвәлгеләр, ГПУ агенты һәм кызылармеец» дигәннән соң автор тарафыннан берни дә язылмаган. Ягъни, текст шунда тукталып, тәмамланмыйча калган. Бу әсәрнең 1925 елда сәхнәдә уйналуына багышлап язылган мәкаләдә «Нәни абый» спектакленең баш герое кулга алыну белән тәмамланганы әйтелгән[12].

Татар дәүләт театры үзенең 1925 елгы сезонын 4 ноябрьдә, чәршәмбе көнне, Кәрим Тинчуринның «Нәни абый» әсәре белән ачып җибәргән. Бу турыда «Красная Татария» газетасында Фуат

[9] Сәхнәгә куярга ярый һәм ярамый торган сәхнә әсәрләре исемлеге. — Икенче басма. — Казан: Татиздат, 1931. — Б.19. Бу кулланмада идеологик, сәнгати эшләнеш һәм эчтәлекләре ягыннан тыелган пьесаларның исәбе — 246. Ә уйнарга ярый, дип билгеләнгәннәре — 208 пьеса. Мондый исемлекнең беренче басмасы 1924 елда дөнья күргән.

[10] Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык... — Б.445.

Саллавиның алхәбәре чыккан. Анда, аерым алганда, мондый юллар бар: «Сегодня Таттеатр открывает сезон. Открывает пьесой главного режиссёра театра Карима Тенчурина «Нани абы» («Маленький дядя»). Это — опыт бытовой комедии наших дней. И знаменует собой уход театра от дешёвых сказок и феерий, которые прочно держались в репертуаре до сего времени... На сезон приглашён оркестр под управлением Салиха Сайдашева»[13].

«Нәни абый» пьесасы 1931 елда сәхнәләрдә куелудан тыелган[14].

«Чит илләрдә» комедиясе үзәгенә бөтендөнья революциясенең тормышка ашу хыялы куелган. Тәҗрибәле драматург анда да татарларны катнаштыру җаен тапкан — әсәрнең башыннан-ахырынача Америкадагы ике татар мөһаҗирен тасвирлаган. Эмигрантлар характеры аша милли һәм шәхси үзенчәлекләр комик һәм сатирик вазгыятьләр эчендә ачылган. Әйтик, аларның берсе американнарга Тәтеш кантонын, икенчесе Эстәрлене сату турындагы тәкъдимнәре, робот-машиналарны иманга китертү, татарча такмаклап, вак сәүдәгә өйрәтүләр һәм башка шундый күренешләр гаҗәеп кызыклы.

«Туран иле» әсәре офыктан-офыкка җәелгән зур төрки-татар дәүләте — Туран илен төзеп, Казан шәһәрен аның башкаласы итү уйдырмасы турында. Анда XX гасыр башында яшәгән реаль шәхесләр сурәтләнгән булуга карамастан, әлеге сатирик әсәр үз чорының идеологик заказы сыйфатында язылган, дип әйтергә мөмкин.

***

Кулъязмаларның барысына да хас үзенчәлек — Кәрим Тинчурин әсәрләренең ашыгыч рәвештә язылганлыгы күзгә ташлана. Бу күренешнең объектив сәбәпләре Заһидә Тинчурина истәлекләрендә ачык итеп әйтелгән: *«Тинчурин язган 33 пьесаның, чагыштырмача алганда, бик азы гына басылып чыкты. Гадәттә, ул бик ашыгып яза иде, чөнки ул иҗат итә башлаган елларда әле театр яңа оешып кына килә һәм яңа әсәрләргә мохтаҗлык бик зур иде. Театрда бик күп эшләгәнгә күрә, Тинчурин бары тик буш вакытларында гына кулына каләм ала һәм күбесенчә төнлә белән, төнге 1дән 6га кадәр, башын күтәрми язып утыра иде. Ә 11дә инде ул театрда репетициядә. Яңа пьесаны тиз-тиз укыйлар, киңәшәләр һәм сәхнәгә әзерлиләр, ә пьесаны бастырып чыгару турында уйларга вакыт юк»*[15].

К.Тинчурин кулъязмаларында кайбер сүзләр хәзерге татар орфографиясенә туры килми. Мәсәлән, дөрест, мондай, ниндәй, андай, ийе, маңлай, өзем (йөзем), тамук (тәмуг), ямә (яме), җылау, җомгак, җуан, төслүк һ.б. Автор имлясын төгәлрәк саклау максатында бу басмада андый сүзләр төп текстлардагыча калдырылды.

[11] Мәхмүтов Һ. К.Тинчурин иҗаты һәм тәнкыйть // Традиции и новаторство в творчестве Карима Тинчурина: сборник статей. — Казань: Полигр. комб. им. К.Якуба, 1990. — С.54; Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык... — Б.414.

[12] «Дәү абый». Дәүләт татар театрында кышкы сезон ачылды // Кызыл Татарстан. — 1925. — 10 ноябрь.

[13] Саллави Ф. Татгостеатр // Красная Татария. — 1925. — 4 ноября.

[14] Сәхнәгә куярга ярый һәм ярамый торган сәхнә әсәрләре исемлеге. — Икенче басма. — Казан: Татиздат, 1931. — Б.16.

[15] Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык... — Б.445.

КАРАКҮЗ

Кәрим Тинчурин

Борынгы тормыштан музыкалы мелодрама
4 пәрдә, 5 күренештә



Катнашалар:

Каракүз — хәерче кыз. Җырчы, оста биюче.

Иделбай — кол егет.

Гөлгенә — келәм туку остасы.

Лаләбану, Асылбану, Хикәятбану — Гөлгенәнең кызлары.

Хөрмәбану.

Җанбәк — Алтын Урда ханлыгының Бәрләс олысы бәге.

Зөбәрҗәт, Айтүрә, Анастач — Җанбәкнең хатыннары, бикәләр.

Корылтай — Җанбәкнең киңәшчесе.

Бәйрәмкол — бытбылдыклар башлыгы.

Укбай — җәзачы.

Сөрембай — җәзачы.

Беренче сакчы.

Икенче сакчы.

Йолдызбану, Зәкятбану, Зәнҗәфил — кәнизәкләр.

Беренче чүре (кол кыз).

Икенче чүре.

Өченче чүре.

Шәйбан — бакча остасы.

Аксакал.

I дәрвиш.

II дәрвиш.

I сәүдәгәр.

II сәүдәгәр.

III сәүдәгәр.

IV сәүдәгәр.

V сәүдәгәр.

Җөрәкче.

Сачтараш.

I б а л а.
II б а л а.
III б а л а.
К ә р в а н б а ш л ы г ы.
К а р т.
Х ә е р ч е л ә р, к о л л а р, х ө к ү м ә т к е ш е л ә р е, с о р н а й ч ы л а р, к ә р н ә й ч е л ә р.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Иске Шәрык шәһәрендә эчкәре. Сәхнәнең түрен һәм уң ягын балханә киртәли. Сулда — бакча, койма һәм ишек. Йортны кисеп үтә арык. Шәфталу агачы төбендә казан асты урыны. Түрдәге балханәдә келәм тукыйлар. Уң ягында түшәкләр, ястыклар, мендәрләр өелгән. Гөлгенә әби келәм тукый, кызлар булышалар. Пәрдә күтәрелгәндә — көндез, ахырга таба кич була. Балханәләр өстеннән тау битенә төзелгән йортлар, мәсҗидләр, шәһәр күренә.

I күренеш

Гөлгенә, Лаләбану, Хикәятбану һәм Асылбану.

Җыр

Л а л ә б а н у. Җем-җем гынай…
Б а р ы с ы. Җем-җем.
Л а л ә б а н у. Ак йолдыздай…
Б а р ы с ы. Җем-җем.
Җем-җем итә, гөлләр сибә,
ай, карасаң;
Йөрәкләрне кисә китә, ай, уйласаң!..
Л а л ә б а н у. Нәфис, нәфис бизәкләрен күрең, бизәкләрен!
Б а р ы с ы. Күрең, күрең, күрең!
Л а л ә б а н у. Күрекле, күрекле үрнәкләрен күрең, үрнәкләрен!
Б а р ы с ы. Күрең, күрең, күрең!
Л а л ә б а н у. Җем-җем гынай…
Б а р ы с ы. Җем-җем.
Л а л ә б а н у. Гөлбостандай…
Б а р ы с ы. Җем-җем.
Җем-җем итә,
гөлләр сибә, ай, карасаң;
Йөрәкләрне кисә китә, ай, уйласаң!..
Л а л ә б а н у. Нәфис, нәфис бизәкләрен күрең, бизәкләрен!
Б а р ы с ы. Күрең, күрең, күрең!
Л а л ә б а н у. Күрекле, күрекле үрнәкләрен күрең, үрнәкләрен!
Б а р ы с ы. Күрең, күрең, күрең!
Л а л ә б а н у. Җем-җем гынай…
Б а р ы с ы. Җем-җем.
Л а л ә б а н у. Рушан айдай…
Б а р ы с ы. Җем-җем.
Җем-җем итә, гөлләр сибә,
ай, карасаң;
Йөрәкләрне кисә китә, ай, уйласаң!..
Л а л ә б а н у. Нәфис, нәфис бизәкләрен күрең, бизәкләрен!
Б а р ы с ы. Күрең, күрең, күрең!
Л а л ә б а н у. Күрекле, күрекле үрнәкләрен күрең, үрнәкләрен!
Б а р ы с ы. Күрең, күрең, күрең!..

II күренеш

Әүвәлгеләр һәм Хөрмәбану.

Х ө р м ә б а н у *(ашыгып кереп)*. Уф, уф!.. Эш уң булсын, Гөлгенә абыз!..

Г ө л г е н ә б а н у. Аягың җиңел, гомерең озын булсын!

Х ө р м ә б а н у. Уф-ф-ф!.. Тәмам әлсерәде кеше.

Г ө л г е н ә б а н у. Түрдән уз, Хөрмәбану!

Х ө р м ә б а н у. Утыра тора тормыйм, вакытым юк. Бүген иртәдән бирле өйгә кайтканым юк әле. Иртә белән багка барышлый, Чибәр абыз очрап, аның белән сүзгә мавыкланып китеп, багка да бара алмыйча калдым. Сүз сүзне тарта дигәндәй, сөйләшә-сөйләшә, аның белән бергә базарга барып чыкканмын. Әй-й-й!.. Базар дигәннән, кызлар, кызларым!

Х и к ә я т б а н у. Нәрсә, Хөрмәбану абыз?

Х ө р м ә б а н у. Бүгенге базар тамашасын ишеттегезме?

Х и к ә я т б а н у. Юк…

Х ө р м ә б а н у. Юу-у-у-к?!

Л а л ә б а н у. Базарларга чыгар өчен байлык һәм вакыт кирәк.

Х ө р м ә б а н у. Бик дөрес,

каләмкаш, бик дөрес. Байлык һәм вакыт кирәк. Уф, уф!.. Ә менә минем тын алырга да вакытым юк. Нигә генә Ходай көнне атна итеп яратмаган икән?.. Шул, сүзгә мавыкланып, Чибәр абыз белән базарга барып чыкканымны сизмичә дә калганмын. Ә базарга баргач анысын карыйсың килә, монысын күрәсе килә, дигәндәй. Анысы очрый, тегесенә «саумы», монысына «исәнме», дияргә дә өлгермисең — кич тә килеп җитә. Уф-ф-ф. Һич бу вакыт дигәнне төткәреп булмый. Нигә генә бу Ходай көнне ай итмәгән икән?! Шул бүгенге базар тамашасын күрмичә калсам, мәңге үкенечле калачак икәнмен.

Х и к ә я т б а н у. Нигә, әллә берәр кызыклы тамаша булдымы?

Х ө р м ә б а н у. Әй-й, кызык кынамы? Ахырзаман, кыямәт, дисәң дә ярый!

А с ы л б а н у. Карак тоттылармы әллә?

Х ө р м ә б а н у. Әй-й. Карак тотуы кызыкмыни?!

Х и к ә я т б а н у. Әллә кучкарлар сөзештерделәрме?

Х ө р м ә б а н у. Юк, дим, юк!

Л а л ә б а н у. Комарбазлар сугышканын күргәндер әле.

Х ө р м ә б а н у. Комарбазлар сугышканын күрер өчен базарларга барыр хәлем юк. Һәрбер чәйханәдә өелешеп яталар алар.

Х и к ә я т б а н у. Тамгачыны кыйнамаганнардыр бит?

Х ө р м ә б а н у. Чынлап кына әйтегез әле, ишеттегезме-юкмы?

Х и к ә я т б а н у. Юк, дибез бит инде.

Х ө р м ә б а н у. Чынлап әйтүегезме?

Х и к ә я т б а н у. Соң!..

Х ө р м ә б а н у. Әй, җебегән тавыклар!

Л а л ә б а н у. Әллә берәр хәл булдымы тагы?!

Х ө р м ә б а н у. Хәл генәме! Галәмәт, кыямәт, әкәмәт, мәхшәр көне булды бит бүген базарда!

Х и к ә я т б а н у. Нәрсә генә булды соң алай?

Х ө р м ә б а н у. Сөйләп торырга вакытым юк. Сөйли башласаң, сүз сүзне тарта, дигәндәй... Әйтмим әле. Иртәдән бирле өйгә дә кайтканым юк. Уф-ф. Нигә генә бу Ходай көнне ел итеп яратмаган инде?! Шул, икенче бервакыт иркенләп кереп сөйләп чыгармын әле, насыйп булса. Бөтен шәһәр шау килә бит, әле дә ишетмәгәнсез икән, мескеннәр. Сау булыгыз!.. Тудыкай да ишетмәгәндер әле... *(Кире кайтып.)* Төш әни дә ишетмәгән булган, сөйләгәч исе китте, хәйран калды. Исән булыгыз! *(Кире кайтып.)* Менә әле Баскак мәйданында Сөйгәнем абыз очрады. «Кая болай ашыгасың?» — ди, миңа әйтә. Мин әйтәм: «Ай, юл куй, — дим, — Сөйгәнем абыз, тын алырга да вакытым юк», — дим, мин әйтәм. «Болай мавыкланып кайдан кайтып киләсең?» — ди, миңа әйтә. «Ай, зинһар, юл куй, — дим, мин әйтәм. — Мөхсин базарчылары китергән чуралар арасындагы галәмәтне ишеттеңме? — мин әйтәм. — Алайса, — дим, мин әйтәм — сөйләп торырга вакытым юк. Юл куй, — дим, мин әйтәм.

Х и к ә я т б а н у. Йә, йә?!

Х ө р м ә б а н у. «Нәрсә, нәрсә?» — ул. «Алай», — дим. Тәмам сагыз булды. «Сөйләп торырга вакытым юк», — дим, мин әйтәм. *(Утыра.)*

Х и к ә я т б а н у. Йә, йә?!

Х ө р м ә б а н у. Мөхсин базарчылары китергән чуралар арасында теге алты тимерче җегет тә бар икән ләбаса.

Л а л ә б а н у. Нәрсә?!

Х ө р м ә б а н у. Әй, Ходаем, җөпләп, җентекләп торырга вакытым юк, дим, ләбаса... *(Бөркәнчеген ташлый.)*

Л а л ә б а н у. Ниндәй, кайсы алты җегет?

Х ө р м ә б а н у. Куян елны лашманлыктан баш тарткан өчен Олыс бәге боерыгы белән Мөхсин базарчылары алып киткән җегетләр...

Л а л ә б а н у. Йә, йә?!

Х ө р м ә б а н у. Шул җегетләрне чура итеп сатарга, дип кире монда алып килгәннәр.

Л а л ә б а н у. Чын сөйлисеңме, Хөрмәбану абыз?

Х ө р м ә б а н у. Дөньяда ике чын булса, берсе шул инде.

Л а л ә б а н у. Йа Ходай!..

Х ө р м ә б а н у. Бичараларның туган илләрендә ризыклары бетмәгән, күрәсең.

Л а л ә б а н у. Йә, йә, йә?!

Х ө р м ә б а н у. Мескеннәрнең чырайлары да калмаган. Туган-тумачалары җыелып, базарны мәхшәр көненә әйләндерделәр. Уф, уф!.. Җәелеп утырырга вакыт тапканмын тагы... Сау булыгыз! *(Кире кайтып.)* Әй, онытып китәм икән... Такыячы Талчыбык әбинең чуралыкка гөрифтар улының богаулы аякларын кочаклап, чал чәчләрен өзгәләп ярсуына карап, бөтен базар аһ орды.

Л а л ә б а н у. Хөрмәбану абыз...

Х ө р м ә б а н у. Тукта, бүлдермә! Вакытым тар. Олыс бәге әйтә икән, ди: бер тапкыр минем боерыгыма йөз орудан баш тарткан азгыннарның аяк эзләре минем туфрагымда булмас, дип әйтә икән, ди.

Л а л ә б а н у. Соң, соң, ул алты җегет арасында...

Х ө р м ә б а н у. Вакытым юк!.. *(Кире кайтып.)* Әй-й-й... Әле мин сезгә тамашаның иң кызыгын сөйләмәгәнмен икән.

Х и к ә я т б а н у. Йә, йә?!

Х ө р м ә б а н у. Анысын инде икенче чакта иркенләп сөйләрмен. Инансагыз әгәр, тын алырга да вакытым юк. Теге Илче-кунак мәхәлләсенең Зөбәрҗәт әби улы, тимер остасы Тимербулатны беләсегезме?

Л а л ә б а н у. Ни булган аңа? Әллә...

Х ө р м ә б а н у. Чү әле, чү, Лаләбану. Вакытым тарлыгын күрмисеңмени?!

Л а л ә б а н у. Хөрмәбану абыз! Җаным бул, бәгърем бул, әйт — ни булган?

Х ө р м ә б а н у. Вакытым булса, бер дә генә ялындырмас идем. Тамашаның кызыгы да алты җегет белән бергә сатылган шул тимер остасы Тимербулатта инде.

Л а л ә б а н у. Нәрсә, нәрсә дисең?!

Х ө р м ә б а н у. Базар аксакалы Олыс бәгенең сүзләрен базарчыларга әйткәч, әлеге шул Тимербулат шашып, йөзләрен көзән җыерып, тамашага җыелган халайыкка карап: «Туган илдә туганнар, сөйгән ярлар белән бергә торырлык булмагач, ичмасам, сөякләремне туган илнең этләре кимерсен!» — дип, менә мондай көймә кадакны йөрәгенә саплап актарды, актарды да, халайык алдында җан бирде, мескен.

Л а л ә б а н у *(бик каты кычкырып)*. Аһ, аһ!.. Вафасыз җанварлар, аһ, аһ!.. *(Акырып чыгып китә.)*

Х ө р м ә б а н у. Менә?! Ни булды аңа?!

Г ө л г е н ә. Яхшы бала ул, изге бала ул. Барсын, сөеклесенең үлгән гәүдәсе өстендә кайнар яшьләрен түксен.

Кызлар җылашалар.

Х ө р м ә б а н у. Моны белгән булсам, сөйләмәгән булыр идем.

Г ө л г е н ә. Зарар юк. Күргәнне сөйләү гаеп түгел. Шул җәфаларны ил башына төгүчеләрнең үз язмышларының шул көнгә калганын күрер идем мин.

Х ө р м ә б а н у. Юк кына гаеп өчен ата балаларын Олыс башының шулай мал урынына саттыруларын хан хәзрәтләре үзе беләме икән?!

Г ө л г е н ә. Кара эшләрнең барысы да аның боерыкларында, ярлыкларында күрсәтелгәнчә, аның ачкүз бәкләре, тарханнары тарафыннан эшләнәләр бит. Беләдер явыз, беләдер залим!..

Х ө р м ә б а н у. Тс-с-с, акрын, Гөлгенә абыз! Ишетсәләр...

Г ө л г е н ә. Ишетсеннәр. Ил өстендәге кара сөремнәреннән тын алып булмый башлады бит инде. Тын алып булмый. Ата балалары малдан да кадерсез булып калдылар хәзер. Ник дисәң, малның ите, тиресе кадерле. Ата балаларының тиреләре, итләре кадерсез шул. Шуның өчен безнең ханнар безне дә, тәннәребезне дә, намусларыбызны да кадерсезлиләр.

Уф-ф-ф, авыр, авыр, дәүләтсез ата балаларының хәле авыр.

Артта җыр ишетелә.

Җыр.

Каракүз.
Бакчадагы гөл төсле, ак теләк теләп,
Үткен, ирекле җил төсле, саф теләк теләп,
Чишмәдәге су төсле, пакь теләк теләп.
Җырлар белән килдем, ай… мин килдем,
Диңгез үкереп шаулаганда
бусагаңда, бусагаңда,
Күкрәп яңгырлар яуганда бусагаңда,
Кайгылылар җылаганда бусагаңда
Җырлар өчен килдем, ай… мин килдем.

Хөрмәбану. Бу теге хәерче кыз Каракүз!

Хикәятбану. Әнкәй, кертеп җырлатыйк үзен.

Хөрмәбану. Биюе күңелле аның. Вакытым булса, биегәнен мин дә рәхәтләнеп карар идем. Вакытым юк шул. Сау булыгыз!.. *(Җыена башлый.)*

Гөлгенә. Безнең кайгыларны җырлый ул кыз бала.

Хикәятбану *(ишеккә барып)*. Каракүз тәтәй, Каракүз тәтәй, безгә дә кер…

Хөрмәбану. Хәерче башы белән кайдан җырын таба да, кайдан биюен чыгара! Сау булыгыз!.. *(Каракүз белән очраша.)* Әйдә, әйдә, Каракүзбану, әйдүк, иркә!..

III күренеш

Әүвәлгеләр һәм Каракүз.

Каракүз *(сәләмә, ләкин бик килешле киенгән, кулында думбра)*. Гомерегез озын, җаныгыз таза булсын, абызлар!..

Хөрмәбану. Әй, кара әле, теләңә салынмыйча гына, тиз генә бер биеп ал да, юлыңда бул! Минем көтәргә вакытым юк.

Каракүз. Вакытың булмаса, капка ачык.

Хөрмәбану. Дивана дисәң, дивана… Ярый, сау булыгыз!

Каракүз. Исән йөреп, сау кайт, абыз!

Хөрмәбану *(кире кайтып)*. Кайт, кайт, дип, нигә мине куасың?

Каракүз. Куганым юк, абыз. Менә капка таныкъ.

Хөрмәбану. Кудың, кудың…

Каракүз. Кумадым, абыз.

Хөрмәбану. Кудың. Менә сиңа үч итеп китмим.

Каракүз. Китмә, кал! Гомерең озын, вакытың бәрәкәтле булсын!

Хөрмәбану *(сикереп торып)*. Вакытым бәрәкәтсез шул, сәләмәбикә!..

Хикәятбану. Хөрмәбану абыз!..

Каракүз. Исемең Хөрмә булса да, телең торма икән, абыз…

Хөрмәбану. Менә дивана, нәрсә ди бит миңа! Кайдан сүзгә өйрәндең соң син?!

Гөлгенә. Каракүз, балам! Син безгә безнең күңелләрдәгең бер җырлап күрсәт, булмаса.

Хикәятбану. «Ардаклы бала»ны, «Ардаклы бала»ны җырла син безгә!

Каракүз. Яман күздән, начар сүздән җыр җырлавы изгерәк, дигән. Бугаз — бездән, колак — сездән. Башладык.

Җыр.
Бакчаларда гөлләр булмас, булмас алар,
Таң чыклары һәр таң, һәр таң сугаралар.
Сулар агар, җилләр исәр, гомер үтәр,
Көннәр җитәр, күзләрдә дә яшьләр кибәр.
Ардаклы бала, ардаклы бала!..
Бәлли-бәү, бәү, бәү, җылама!..
Баскак камчысы эзләрен сызса,
Чура мөһере йөзеңә басылса,
Менә шулчакта, менә шулчакта
Ардаклы бала ардаксыз кала.
Ардаклы бала, ардаклы бала!..
Бәлли-бәү, бәү, бәү, җылама!..

Шәрыкчә ыспай бию башлана.

Богауланган коллар булмас, булмас алар,

Албастылар һаман тормас, тормас алар.
Төннәр үтәр, таңнар җитәр, хурлык бетәр,
Ил өстенә күптән көткән шатлык иңәр.
Ардаклы бала, ардаклы бала!..
Бәлли-бәү, бәү, бәү, җылама!..
Баскак камчысы эзләрен сызса,
Чура мөһере йөзеңә басылса,
Менә шул чакта, менә шул чакта
Ардаклы бала ардаксыз кала.
Ардаклы бала, ардаклы бала!..
Бәлли-бәү, бәү, бәү, җылама!..

Бу юлы бию озак дәвам итә.

Г ө л г е н ә. Гомерең озын булсын, бала! Язгы кояш төсле боеккан күңелләрне җылыта беләсең, бала.

Х ө р м ә б а н у. Әйт әле, Каракүз, кем өйрәтте сиңа бу җырларны?

К а р а к ү з. Урам.

Х ө р м ә б а н у. Ничек урам?

К а р а к ү з. Шулай, урам.

Г ө л г е н ә. Каракүз, балам! Хәзер казан асарбыз, ашарга бездә калырсың.

К а р а к ү з. Анысы яхшы булыр. Ник дисәгез, бүген әле минем бернәрсә ашаганым юк.

Х ө р м ә б а н у. Кара әле, Каракүз! Тора торган урының бармы соң синең?

К а р а к ү з. Нигә кирәк ул?

Х ө р м ә б а н у. Дивана дисәң, дивана. Кунарга, йокларга урын кирәк, ләбаса.

К а р а к ү з. Салкын күләгә — түшәгем минем, сайрар былбыллар — дусларым минем. Бүген монда кунсам, иртәгә, иртәгә сиңа барырмын.

Х ө р м ә б а н у. Ә иртәгәдән соң?

К а р а к ү з. Урамда!..

Х ө р м ә б а н у. Авызыңда шайтан бардыр синең, кызый.

К а р а к ү з. Ә синең әбиеңнең әнисе үрдәк булгандыр, абыз. *(Келәмне күреп шакката.)* Аһ, нинди матур келәм! Нәкышләре, бизәкләре, үрнәкләре йолдызлардай җем-җем итә... Моны син тукыйсыңмы?

Г ө л г е н ә. Без тукыйбыз, бала.

К а р а к ү з. Күптәннән бирле тукыйсызмы?

Г ө л г е н ә. Битемдәге җыерчыкларны санап чыксаң, бу келәмнең гомерен аңларсың.

К а р а к ү з. Кая, кая, у-у-у-у-у!.. Монда әллә тагы мең җыерчык бардыр.

Г ө л г е н ә. Булыр, бала, булыр.

К а р а к ү з. Җыерчыклар яратмыйм мин.

Г ө л г е н ә. Шул җыерчыклардан бу келәмнең үрнәкләрен күчердем мин.

К а р а к ү з. Алай булгач, бу келәм бик карт икән. Синең кордаш икән.

Г ө л г е н ә. Миннән дә картрак ул.

К а р а к ү з. Бу келәм карт булса да, үзе язгы гөл түтәле төсле саф, шат, яшь, матур булып тора. Ә син бөтенләйгә бөрешкәнсең.

Г ө л г е н ә. Минем яшьлегем, шатлыгым, матурлыгым аңа күчкән.

К а р а к ү з. Кайчан бетәр ул?

Г ө л г е н ә. Соңгы каймасын сузабыз.

К а р а к ү з. Беткәч нишләтмәкче буласыз?

Г ө л г е н ә. Аның хисабына шактай бурычландык инде. Менә боларның киләчәкләре аңа каратылган.

Х ө р м ә б а н у. Күпме тора инде ул?

Г ө л г е н ә. Моның бәясе юк.

Х ө р м ә б а н у. Алай да?

Г ө л г е н ә. Һәвәскәр очраса, йөз алтын да кызганмас.

Х ө р м ә б а н у. Йөз алтын!.. Байыйсыз икән, Гөлгенә абыз.

К а р а к ү з. Бу келәм өчен мин мең алтын да кызганмас идем. Тик менә бер генә алтыным да юк. Әй, бабакаем, сатып ала алмыйм шул мин сине. Әгәр дә мәгәр минем бик күп, менә бер итәк алтыннарым булса иде, ди.

Х ө р м ә б а н у. Синеңме? Ха-ха-ха!..

К а р а к ү з. Чү әле, чү!.. *(Келәмне сыйпап.)* Син минем бабакаем да, әбекәем дә, җаныкаем да булыр идең. Мин сине һәйбәтләп мәйдан уртасына җәеп җибәрер идем дә, өстеңдә җырлый-җырлый биер идем. Ә төн булгач, яртысын астыма салып, яр-

тысы белән бөркәнеп йоклар идем. Рәхәт!..

Х ө р м ә б а н у. Дивана дисәң, дивана! Ходай сиңа белеп байлык бирмәгән. Мондай келәмне мәйданга җәяләрмени?

К а р а к ү з. Синеңчә, кайда җәяләр соң?

Х ө р м ә б а н у. Өй эченә, балханәгә.

Г ө л г е н ә. Балалар, казан асыгыз!

К а р а к ү з. Минемчә, мәйданда да бик килешеп торыр иде бу келәм. *(Хыялланып.)* Менә шулай, шулай, шулай итеп җәеп җибәрәсең дә, уртасына менеп, менә шулай, һо-о-оп… утырасың. Ә тирә-юнеңдә күгәрченнәр, этләр карап торалар. Кыз-з-зык!

Х ө р м ә б а н у. Менә дивана! Ха-ха-ха!.. Затлы малның кадерен беләсеңмени соң син?!

К а р а к ү з. Нигә?!

Х ө р м ә б а н у. Соң бит мәйданга җәйсәң, тузанга манчылып эштән чыгачак.

К а р а к ү з. Мин һәр көн кагармын.

Х ө р м ә б а н у. Куй, куй, юкны сөйләмә! Сиңа төсмени ул?

К а р а к ү з. Ә сиңа төсме?

Х ө р м ә б а н у. Минем, ичмасам, җәяргә урыным бар, өем бар, балханәм бар.

К а р а к ү з. Ә минем мәйданым бар, урамым бар, чирәмем бар.

Х ө р м ә б а н у. Акыллы кешеләр урамга чыпта җәяләр.

К а р а к ү з. Алайса, бөтен дөнья акылы сиңа булсын!

Х ө р м ә б а н у. Дивана дисәң, дивана! Мәйданга келәм җәймәкче.

К а р а к ү з. Син акыллы бул да, чыпта җәй!

Х ө р м ә б а н у. Алаймы?

К а р а к ү з. Шулай, абыз.

Х ө р м ә б а н у. Нигә ул алай икән?

К а р а к ү з. Син акыллыга күрә.

Х ө р м ә б а н у. Акыллы шул. Синең шикелле дивана түгел.

К а р а к ү з. Мин дә шулай дим. Юкса, акыл да, келәм дә бер кешегә күбрәк булыр шул.

Х ө р м ә б а н у. Акыллы чыптаны да келәм итәр, ә дивана келәмне дә чыпта итәр.

К а р а к ү з. Туры әйттең, абыз. Акыллы башыңа чыптаңны капла да йөр. Мин диванага келәм дә ярый. Үз эшем: телим икән — мәйданга җәям, телим икән — урамга җәям. Синең эшең булмас.

Х ө р м ә б а н у. Ничек минем эшем булмасын?! Асылзатны син дивана хәерчедән сансызландырыр хәлем юк.

К а р а к ү з. Үз келәмем, теләсәм кая җәярмен.

Х ө р м ә б а н у. Ничек ул алай синеке?!

К а р а к ү з. Әллә синекеме?

Х ө р м ә б а н у. Минеке шул.

К а р а к ү з. Карагыз, кара, кара, кара, кара! Ха-ха-ха…

Г ө л г е н ә. Күреклеләр, туктагыз! Келәм әле бетмәгән.

К а р а к ү з. Ха-ха-ха… Үлә ич! Ха-ха-ха…

Х ө р м ә б а н у. Утырдашың таз булса, сөйләгән сүзең кутыр булыр, дигәндәй, син дивана белән сүз көрәштергән мин җүләр.

К а р а к ү з. Җүләр шул, абыз. Бик җүләр икәнсең, ха-ха-ха!..

Х ө р м ә б а н у. Йа, Ходай! Караңгы да төшкән ләбаса. Бу караңгыда өйгә ничек кайтыйм инде?

К а р а к ү з. Бераз гына вакыт табып кунып китәрсең, ха-ха-ха.

Лаләбану чәчләрен тузгытып керә.

IV күренеш

Әүвәлгеләр һәм Лаләбану.

Х ө р м ә б а н у. Кунасым килсә, синнән сорамам. *(Лаләбануга каршы барып.)* Күрдеңме, үлгәнме?

Л а л ә б а н у. Аһ, бу җәһәннәм газапларын күрер өчен нигә генә соң дөньяга туа ата баласы?! Күз тутырып йөзенә дә карый алмадым. *(Җылый.)*

Г ө л г е н ә. *(Лаләбануны кочаклап).* Жыла, кызым, жыла! Күз яшьләрең залимнарның туфрагына зәһәр булып тамсын!

Кызлар Ләләбануны чолгап алалар.

Җыр.

Л а л ә б а н у. Сүнде теләк, яна ла, ай, дәрт, яна ла яна!..

Б а р ы с ы. Әй-й-й, бала! Жыла, жыла, кыз бала.
Йолдызлар да сүнә, ай югала…

Л а л ә б а н у. Өзелде йөрәк, яна ла күкрәк, ай, яна ла, яна!..

Б а р ы с ы. Әй-й-й, бала! Жыла, жыла, кыз бала!
Йолдызлар да сүнә, ай югала…

Л а л ә б а н у. Тапталган гөл, яна ла күңел, яна ла, яна!..

Б а р ы с ы. Әй-й-й, бала! Жыла, жыла, кыз бала!
Йолдызлар да сүнә, ай югала…

Л а л ә б а н у. Авыр, авыр, яна ла бәгырь, ай, яна ла, яна!..

Б а р ы с ы. Әй-й-й, бала! Жыла, жыла, кыз бала!
Йолдызлар да сүнә, ай югала…

V күренеш

Әүвәлгеләр һәм Иделбай.

Иделбай чабып кереп, кинәт артка борылып, яңадан көч белән алга ташлана.

Г ө л г е н ә. Кем ул?!

Х ө р м ә б а н у. Ир кеше!

Х и к ә я т б а н у. Карак!

А с ы л б а н у. Качкын?!

Г ө л г е н ә. Эчкәрегә изенсез керергә ничек батырчылык иттең, оятсыз?

Х ө р м ә б а н у. Изенсез ничек керәсе булдың монда?

И д е л б а й *(аңына килеп).* Тс-с-с!.. Абызлар, харап итмәгез!.. Мине эзәрлиләр…

Г ө л г е н ә. Кем син?

Каракүз дикъкать белән Иделбайга карап тора.

Х ө р м ә б а н у. Карак?

И д е л б а й. Түгел.

Г ө л г е н ә. Комарбаз?

И д е л б а й. Түгел.

Х ө р м ә б а н у. Әллә кеше үтерүчеме?

И д е л б а й. Юк, юк, түгел!..

Г ө л г е н ә. Кем соң син?

И д е л б а й. Мин чуралыкка гөрифтар ата баласы, базардан качтым. Коткарыгыз, кызганыгыз мине?!

Х ө р м ә б а н у. Ялганлыйдыр ул.

И д е л б а й. Маңлаема карагыз, богауларым да чишелмәгән. Коткарыгыз мине, кызганыгыз! Тотылсам бит…

К а р а к ү з. Курыкма, җегет! Урының тыныч. Изге бәндәләргә дучар булдың. *(Ишекне бикли.)* Сине монда таба алмаслар.

Г ө л г е н ә. Кайсы илдән соң син?

И д е л б а й. Туган илем ерак, бик ерак, абыз.

Г ө л г е н ә. Ата-анаң бармы?

И д е л б а й. Беркемем дә юк.

К а р а к ү з. Утыр, җегет. Чуралыкка гөрифтар булуың күптәнме?

И д е л б а й. Дүрт ел.

К а р а к ү з. Ни өчен сине саттылар?

И д е л б а й. Хурлыктан баш тарткан өчен.

Х ө р м ә б а н у. Кара әле, җегет. Әллә син теге тимерче җегетләр кәрванынннанмы?

И д е л б а й. Ие.

Б а р ы с ы. Мескен!..

Л а л ә б а н у. Тимербулатымның юлдашымыни? *(Ташланып җылый.)* Аһ, залимнар, кансыз ерткычлар!.. *(Читкә китеп җылый.)*

Г ө л г е н ә. Ничек соң безнең йортка керәсе булдың, әллә Тимербулат әйтеп калдырдымы?

И д е л б а й. Менә бу сеңелнең мәйданда, Тимербулатның гәүдәсен кочаклап, аһ-зар түгүен тамаша кылдым. Тоткан юлы бу капка икәнен күрдем. Дошманнар булмас, дуслардыр дип, изенсез керергә батырчылык иттем.

Г ө л г е н ә. Балалар, табын корыгыз!

К а р а к ү з. Кая, җегет, бу чылбырлардан сине коткарырга кирәк.

И д е л б а й. Бикләнгән алар.

К а р а к ү з. Асылбану, игәү табылмасмы?

А с ы л б а н у. Табылса кирәк.

Х ө р м ә б а н у. Гөлгенә абыз! Мин хәзер өйгә кайтырга чынлап та курка башладым инде.

Г ө л г е н ә. Куна кал, түшәк табылыр.

А с ы л б а н у. Менә... *(Каракүзгә игәү бирә.)*

К а р а к ү з. Йә, әле җегет! Аякларыңны суз, игәүләп ташлыйк әле. Ай, бичара. Карагыз, кара, кара — богау божрасы аяк итләрен сөягенә хәтле ашаган.

Б а р ы с ы *(карап)*. Мескен!..

Каракүз игәүли.

Г ө л г е н ә. Ата-анаң күптән үлделәрме?

И д е л б а й. Әнидән ун яшьтә калдым, әтине хәтерләмим.

К а р а к ү з. Кардәш-тумачаларың бер дә юкмыни шулай?

И д е л б а й. Мөхсин-калада бар, ди торган иде әнкәй.

Х и к ә я т б а н у. Әнкәй, аш булды, табын тайярланды.

Г ө л г е н ә. Әйдә, җегет, күктән көткән, җирдән иңгән кунак бул! Каракүз, син үз итеп утыр! Хөрмәбану, син дә табынга уз!

К а р а к ү з. Әйдә, җегет, сыйлаганда усланып кал дигәндәй, син ачтыр әле. Аштан соң игәүләрбез, яме... Минем үземнең дә бүген көнозын бернәрсә капканым юк.

Асылбану таз-комган белән су бирә, барысы да җуыналар.

К а р а к ү з. Әбәү!.. Синең бу куллар туганнан бирле җуылмаганнардыр.

И д е л б а й. Чура кулын җуса — йозакларны, битен җуса — богауларны барлау кирәк, диләр йөкчеләр.

Г ө л г е н ә. Йә, кунаклар, боерыгыз!

К а р а к ү з. Җегетнең күзләренә тузан кергән әле монда.

Х ө р м ә б а н у. Үзең тузан җибәргәнсеңдер әле син.

К а р а к ү з. Анысы да була яшь чакта.

Х ө р м ә б а н у. Картайттың син мине, Каракүз.

К а р а к ү з. Үземчә олылап әйтүем иде...

Г ө л г е н ә. Боерыгыз, түрдән боерыгыз!

К а р а к ү з. Бу табында ардаклы кунак без булдык. Һоп! *(Утырып.)* Менә шулай.

Г ө л г е н ә. Бары шунда, кунаклар. Бик рәхәтләнеп башлагыз!

К а р а к ү з. Әйттем бит. *(Пылау сымак нәрсәне кашыксыз ашыйлар.)* Ә иртәгә мин сине, теләсәң — Мөхсин-калага, теләсәң — Җаекка озатачакмын.

И д е л б а й. Минем бит мөһернамәм юк. Аннан соң бу... *(Маңлаендагы мөһерне күрсәтә.)*

К а р а к ү з. Чалма урагач күренмәс.

Х ө р м ә б а н у. Чалма каян алырсыз икән сез?

К а р а к ү з. Анысы бар икән...

Г ө л г е н ә. Җитешегез, кунаклар, җитешегез!

К а р а к ү з *(кычкырып)*. Булды, чалма да булды! *(Сәләмә шарфын алып.)* Менә хәзердән үк чалып куярга мөмкин.

Шарфны Иделбай башына ураганда капка кагалар.

Б а р ы с ы. Тс-с-с!

Г ө л г е н ә. Бу ни хәл бу? Бу вакытта кем булыр икән? *(Һаман кагалар.)* Өн чыгармагыз! Үзем барыйм... Кем бар?

Т ы ш т а н т а в ы ш. Ач!

Г ө л г е н ә. Син кем?

Т ы ш т а н т а в ы ш. Кергәч белерсең.

Г ө л г е н ә. Танымаган ир-ат икәнсең, юлыңда бул!

Т а в ы ш. Без сакчылар.

Г ө л г е н ә. Ниндәй сакчылар?

Т ы ш т а н т а в ы ш. Базар сакчылары.

Г ө л г е н ә. Базар сакчылары, җегет, синең эздән килгәннәр. Кач! *(Кире капкага барып.)* Нәрсә кирәк соң сезгә?

К а р а к ү з. Әйдә, тизрәк! Ходаем, койма биек икән. Кая качырыйк моны?

Х и к ә я т б а н у. Түшәкләр астына!

К а р а к ү з. Әйдә! *(Иделбайны түшәкләр астына яшерәләр.)*

Г ө л г е н ә. Йортта ир-ат юк. Йомышыгыз булса, иртәгә килерсез.

Т а в ы ш. Ватып керәчәкбез. Ач!

Г ө л г е н ә. Нишлик икән, балалар? Ватып керәбез, диләр.

Б а р ы с ы. Кертмә, кертмә!

Г ө л г е н ә. Кертә алмыйм, бәкләр. *(Ишекне вата башлыйлар.)*

Г ө л г е н ә. Харап булдык, харап булдык!

Х ө р м ә б а н у. Нигә калдым, нигә якты күздә китмәдем?!

Х и к ә я т б а н у. Җимерәләр, җимерәләр!

А с ы л б а н у. У-у-у, у-у-у-у. *(Җылый.)*

К а р а к ү з *(Хөрмәбануга)*. Ят шунда, кузгаласы булма! *(Капкага барып.)* Ватасы булмагыз! Басып керергә хакыгыз юк. *(Тибә-тибә.)* Керәсе булмагыз, дим! Ватмагыз, дим! *(Ишек ачыла, сакчылар керә.)* Сукыр чебеннәр төсле кая керәсез? *(Сугыша башлый.)*

Б е р е н ч е с а к ч ы. Йорт иясе кем?

Г ө л г е н ә. Мин, бәкләр.

Б е р е н ч е с а к ч ы. Олыс бәге боерыгы белән әйтәм, турысын сөйлә!.. Бу капкадан качкын чураның кереп киткәнен күргәннәр.

Х и к ә я т б а н у. Бездә беркем дә юк.

Б е р е н ч е с а к ч ы. Синнән сорыйм, кортка!

Г ө л г е н ә. Без качкыннар асрамыйбыз.

К а р а к ү з. Эчкәреге хатын-кызлар арасына басып керү боерыкта да, ярлыкта да юк.

Б е р е н ч е с а к ч ы. Ир-аттан беркем дә юкмы?

К а р а к ү з. Сездән башка хәтта ата чебен дә юк.

Б е р е н ч е с а к ч ы *(Икенче сакчыга)*. Тенте! Ә сез урыннарыгыздан кузгалмагыз!

К а р а к ү з *(Икенче сакчыны этеп җибәреп)*. Бу вакытта эчкәрене тентергә хакыгыз юк!

Б е р е н ч е с а к ч ы. Олыс бәгенә шикаять итәрсез! Юл куй!

К а р а к ү з. Куймыйм.

Б е р е н ч е с а к ч ы. Юл куй, дим мин сиңа!

К а р а к ү з. Куймыйм.

Б е р е н ч е с а к ч ы *(Икенче сакчыга)*. Юлны арчы!

Икенче сакчы Каракүзне читкә бәрә.

К а р а к ү з. Кагылма миңа!

Л а л ә б а н у *(кычкырып беренче сакчыга каршы килеп)*. Кем кирәк сезгә, кем кирәк?.. Ышанмыйсыз икән, мине алыгыз, алыгыз!

Б е р е н ч е с а к ч ы. Юл куй!

Х ө р м ә б а н у *(мендәр арасыннан)*. Егылам, егылам, егылам... әбәү-ү-ү-ү!!! *(Илереп кычкырып, егылып төшә. Мендәрләр тарала — Иделбай күренә.)*

К а р а к ү з. *(Иделбайны капларга тырышып, Хөрмәбануга тибеп.)* Бәрәкәтсез!

Б е р е н ч е с а к ч ы. Бу кем?

К а р а к ү з. Кайда?

Б е р е н ч е с а к ч ы. Юл куй! *(Бәреп җибәрә.)* Бу кем?

К а р а к ү з. Бумы? Бу, бу, бу минем абыем.

Б е р е н ч е с а к ч ы. Нигә ул анда?

К а р а к ү з. Ни, ни, аны бик каты бизгәк тота.

Б е р е н ч е с а к ч ы *(Иделбайны җилкәсеннән тотып торгызып башыннан чалмасын тартып алып)*. Тор! Әһә! Әйдә!..

И д е л б а й *(паузадан соң)*. Гомерегез озын булсын, абызлар! Насыйп булмады…

Б е р е н ч е с а к ч ы. Кортка, син дә, әйдә!

К а р а к ү з. Ул йөри алмый, үзем барам!..

Чыгалар. Башкалар җылашып калалар. Пәрдә төшә.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бик бай сарай алды бакчасы. Фонтаннар, беседкалар, төрле көньяк агачлары һәм гөлләр. Бакчаның бер ягында сарай баскычы һәм фасады. Артта крепость дивары. Өстән түбәнгә таба киң таш баскыч. Арттан тау итәгендә иске Шәрык шәһәре күренеше. Көндез.

I күренеш

Чүреләр комганнар, тазлар күтәреп җырлап чыга.

Җыр

З ә н җ ә ф и л. Таң нурлары алсу, алсу.

Б а р ы с ы.
Алсу чыклар, сандугачлар,
карлыгачлар —
Безгә шул, теләгә шул, саба таңы бүләге.

З ә н җ ә ф и л. Яшь йөрәкләр ярсу, ярсу.

Б а р ы с ы.
Ярсып сыза, гомер уза, каннар кыза —
Йөрәктә шул, күкрәктә шул,
тиң табылмый яшь дәрткә.

З ә н җ ә ф и л. Аллы-гөлле нәфис гөлләр…

Б а р ы с ы.
Күңеллеләр, сөйкемлеләр, бәхетлеләр —
Түтәлдә шул, үскәндә шул,
күбәләкләр үпкәндә.

З ә н җ ә ф и л. Саба җиле синнән һәрдәм…

Б а р ы с ы.
Сәлам көтәм, хәбәр көтәм, хәтәр көтәм —
Фиракта шул, озакта шул,
ярым калды еракта.

Мелодекламация. Музыка.

Й о л д ы з б а н у.
Аһ, матур яз! Кочагыңда,
Сайрар кошлар җыры астында,
Күрекле гөлләр астында…

Б а р ы с ы. Аһ, дөнья ниндәй күңелле!

Й о л д ы з б а н у.
Таң уяткан тын күлләрдә
Кояш нурларын сипкәндә,
Җилләр назлап тирбәткәндә…

Б а р ы с ы. Аһ, дөнья ниндәй күңелле!

Й о л д ы з б а н у.
Киң күкрәк, дәртле йөрәк
Карап калса үткәндә,
Сөйгәнең сөеп үпкәндә…

Б а р ы с ы. Аһ, дөнья ниндәй күңелле!

Җыр.

З ә н җ ә ф и л.
Күңелле дөнья, дуслар, зарыгып үткәндә;
Читтә, еракта, дуслар, гомер сөргәндә,
Былбыл моңнары, чишмә сулары,
Нәфис сөнбелләр сөендермиләр.

Б а р ы с ы.
Нәфис сөнбелләр сөендермиләр.
Дәртле күңелләр тоткында чакта,
коллыкта чакта…

З ә н җ ә ф и л.
Ал күбәләкләр, дуслар, талпынып очканда,
Шат күбәләкләр, дуслар, гөлгә кунганда,
Күңелләр таша, аһ, чиктән аша,
Нигә мин дә шул күбәләк түгел?!

Б а р ы с ы.
Нигә мин дә шул күбәләк түгел?!
Ашкына күңел тоткында чакта,
коллыкта чакта…

Мелодекламация. Музыка. Ыспай хәрәкәтләр белән талпына-талпына, сөйләнеп, биергә әзерләнәләр.

Б е р е н ч е ч ү р е.
Күбәләктәй канат кагып очсаң иде,
Ерак-ерак саф күкләргә, зур тауларга!
Алтын төсле шәүләгәнгә әверелеп,
Талга кунып, мәңге җырлап торсаң иде.

Үз иркеңдә, сызылып
таңнар аткан чакта…

И к е н ч е   ч ү р е.
Болан төсле, таш-тауларда, далаларда,
Ирекле булып, теләгәнчә йөрсәң иде!
Үз көнеңне үз башыңа күрсәң иде.

Ө ч е н ч е   ч ү р е.
Балык булып саф суларда йөзсәң иде,
Диңгезләрне, мохыйтларны кичсәң иде!

Балет башлана. Музыка.

II күренеш

Әүвәлгеләр һәм Зәкятбану.

З ә к я т б а н у. Җитәр сезгә, әрсез җаннар, килбәтсезләр, килмешәкләр! Һә, тапканнар эш — бакча буйлап кәҗәләрдәй сикерешәләр. *(Зәнҗәфилгә.)* Комганыңны аударма! *(Беренче чүрегә.)* Сабын китер, күбек китер! *(Йолдызга.)* Ә син сөлгегә бар!

Й о л д ы з б а н у *(гөлләр түтәле янынннан үткәндә).*
Матур гөлләр, нәфис гөлләр, күрекле гөлләр!..

З ә к я т б а н у *(аны дорфа рәвештә этеп җибәреп).*
Синең ише чүре өчен үсмәгәннәр,
Бикәләрнең зәүкы өчен үскән алар.

Й о л д ы з б а н у.
Нәфис гөлләр, җиләкләр, җефәкләр,
Төрле-төрле асылташлар, бизәкләр,
Барысы да бикәләргә бүләкләр.
Ә безгә?! Безне, кагылсаң да, сүгәләр.

З ә н җ ә ф и л. Кычкыралар, бакыралар.

Б е р е н ч е ч ү р е. Оралар, сугалар.

Й о л д ы з б а н у. Этәләр, төртәләр.

З ә н җ ә ф и л. Чеметәләр, тибәләр.

З ә к я т б а н у. Җитәр, җитәр!

З ә н җ ә ф и л. Хәер.
Бикәләрнең сәгатьләре инде тулган,
Олыс бәге өчесен дә сөймәс булган.

З ә к я т б а н у. Ялган!
Гәрчә күптән ул хәрәмгә кермәсә дә,
Бикәләрне айдан бирле күрмәсә дә,
Әмма бүген боерык
булды күренергә,
Шуның өчен ашыгалар су керергә.

Й о л д ы з б а н у. Тс-с-с! Чыгалар…

З ә к я т б а н у. Каршы барыгыз!..

Кызлар чыгалар, Зәкятбану каршы бара.

III күренеш

Әүвәлгеләр, Зөбәрҗәт, Айтүрә һәм Анастач.

З ә к я т б а н у. Хәерле таң, бикәләр, боерыгыз, иркәләр!

Бикәләр кәнизәкләр арасында чайкалып кереп, Зөбәрҗәт уңга, Анастач сулга, Айтүрә уртага урнашалар. Көзгегә карашалар. Пауза.

З ө б ә р җ ә т. Зәнҗәфил!
Кара сана, ниндәй минем зиннәтләрем,
Һинд суларын күреп үскән энҗеләрем!
Такыямның күрекле ташы — зөбәрҗәт,
Матур йөзгә килешә икән чибәр зат.

А й т ү р ә. Йолдызбану!
Әйт, бизәнүем килешкәнме?
Кершәннәрем, иннекләрем шәп төшкәнме?
Хәер, йөзем шундай саф. Нәкъ яшь бала.
Караганда хәтта көзге дә ояла.

А н а с т а ч *(чүрегә).*
Чәчләремнең бөдрәләре тузмаганмы,
Керфекләрем кашларымны узмаганмы?
Ә күзләрем төс сайлаган зәңгәр күктән,
Бәгем мине көтә булыр, сагынып күптән.

З ө б ә р җ ә т.
Күлмәгемне күргәнең юк бит әле,
Изүләрен, итәкләрен син күр әле.
Хода кушса, бүген бәгем бик сөяр,
Әмма инде дошманнар тәмам көяр.

Зөбәрҗәт башкаларга кыек карап ала.

А й т ү р ә.
Хына яктым кашыма, чәчләремә,
Ант итсәм дә, охшармын мин бәгемә.
Пөхтә, тулы хатын-кызларны ирләр
Сөйгәннәр, сөяләр һәм сөярләр.

З ө б ә р җ ә т. Мактан, мактан!..
Суга кергәч, буяуларың эзе калмас.
Сәлперәгән җуан тәнең күренгәндә,
Бәгем түгел, чүрәкче дә сиңа бакмас.

А й т ү р ә.
Ялан өсткә бәккә әгәр син күренсәң,
Менә булыр иде хикмәт, әгәр белсәң.
Хи-хи-хи…
Кием киеп, мин матур дип син йөр әле.
Ә киемсез син нәкъ арык,
чын кара чутыр шүрәле!

А н а с т а ч.
Җуан, симез хатын-кыз
ирләр өчен имгәк ул,
Үтә арык булганчы,
булмаганы — мең алтын.
Иркә ирләр андайларны яратмыйлар,
сөймиләр,
Хатын-кызның солтаны —
минем төсле булганы!

З ө б ә р җ ә т. Синең төсле, ди, нәкъ…

А й т ү р ә. Алай. Хи-хи-хи… Салам төсле сары чәчле, ди.

З ө б ә р җ ә т. Песи төсле зәңгәр күзле, ди.

А й т ү р ә. Сипкеле, сипкеле әфәләм йөзле, ди.

З ө б ә р җ ә т. Кукайган ташкурчак төсле, ди.

А н а с т а ч.
Минем күзләр фирәзәдәй, саф күк төсле,
Шуның өчен бәгемнең дә сөеклесе.

З ө б ә р җ ә т. Синме, син Мәскәү эте!

А й т ү р ә. Син тәмуг уты!

А н а с т а ч *(Зөбәрҗәткә)*. Син кара чутыр! *(Айтүрәгә.)* Ә син пешмәгән камыр!

З ө б ә р җ ә т. Каян килгән матурлар… Берегез — черегән чикләвек, икенчегез — ташбака!

А й т ү р ә. Ә син орчык! Аждаһа!.. *(Анастачка.)* Ә син Мәскәү калдыгы, кахбә!

З ө б ә р җ ә т *(Анастачка)*. Черегән чикләвек! *(Айтүрәгә.)* Ташбака! *(Кабатлый).*

А й т ү р ә *(Зөбәрҗәткә)*. Орчык! Аждаһа! *(Анастачка.)* Мәскәү калдыгы, каһба! *(Кабатлый.)*

А н а с т а ч *(Зөбәрҗәткә)*. Кара чутыр! *(Айтүрәгә.)* Пешмәгән камыр! *(Кабатлый)*

Соңгы җөмләләрен барысы бергә сөйләп, бер-берсен төрткәләшәләр.

З ә к я т б а н у *(аралап).*
Әй, гүзәл гөл шаһлары, җир хурлары!
Көнләшәләр сездән саф күк йолдызлары.
Йөзегездә уйный кояш, ай нурлары,
Сез генә тик күрекле баг былбыллары!
Берегез ай, икенчегез якты кояш!
Өченчегез таң нурыдай балкып тора.
Сыннарыгыз талчыбыктай, үзегез яшь,
Күзләрегез җәүһәрләрдәй янып тора.
Син канәфер, син шәфталу, ә син бадьян.
Син карлыгач, син тутый кош, син сандугач.
Нindәй үпкә кала инде, уйласаң,
Матурлыкта өчегез дә тиң булгач!

З ө б ә р җ ә т.
Мин ачуланмыйм, ну-у-у…
бигрәк эссе һава,
Яңгыры да юк бүген, кирәкмәгәндә ява…

А й т ү р ә.
Мин үпкәләмим, үпкә йөзне саргайта,
Әнә, сыерчыклар да ояларына кайта…

А н а с т а ч. Каш җыеру зәңгәр күзгә килешми,
Киң күңелемә ачу-үпкә ирешми.

З ө б ә р җ ә т. Ефәк пәрдәң бигрәк ыспай, бик килешле бүген сиңа!

А й т ү р ә. Бу нинди таш, бигрәк күрекле, әйтсәнә миңа?

А н а с т а ч. Буй-сыннарың бигрәк нәфис, бигрәк зифа!

А й т ү р ә. Саф суларда коенганда бигрәк сылу күренәсең!

З ө б ә р җ ә т. Ак кардан ак тәннәреңә нәрсә генә сөртәсең?

А н а с т а ч.
Һинд диңгезе лаләләрен суга салып,
Җуынсаң син дәррәү китәрсең агарып.

З ө б ә р җ ә т.
Әгәр йотсаң зәл тамырын нанга салып,
Бер атнада ук калырсың син ыспайланып.

З ә к я т б а н у.
Иркә бикәләр, күрекле бикәләр,
Сабын, болыт, зәгъфран бар әзер!

Б а р ы с ы. Хәзер, хәзер…

А й т ү р ә. Олыс бәккә чибәрләнеп күреник әле.

З ө б ә р җ ә т. Әйдә, ахирәт, алдан син бар!

А й т ү р ә. Юк, ахирәт, син бар!

З ө б ә р җ ә т. Син олы хатын, төп хатын.

А й т ү р ә. Булса тагын, син акыллы.

З ө б ә р җ ә т. Син җумарт. Син уз!

А й т ү р ә. Син зирәк. Син уз!

А н а с т а ч. Сатулашмагыз, әйдәгез! *(Чыга башлый)*.

З ө б ә р җ ә т. Тукта, тукта!

А й т ү р ә. Анастач, бәгърем! Синеңчә, кем алдан барырга тиеш?

А н а с т а ч. Кайсыгыз картрак, шул барсын!

З ө б ә р җ ә т. Әйттем бит, хи-хи-хи…

А й т ү р ә. Алайса син алдан бар!

А н а с т а ч. Карчыклар барында мин батырчылык итәмме соң?!

З ө б ә р җ ә т. Әйттем бит, хи-хи-хи…

А й т ү р ә. Синеңчә, әллә мин карчыкмы?

З ө б ә р җ ә т. Сүз дә юк.

А й т ү р ә. Ничек сүз дә юк?

З ө б ә р җ ә т. Шулай.

А й т ү р ә. Ничек ул алай?!

З ө б ә р җ ә т. Шулайның алае булмый, әйдә, уз алга!

А й т ү р ә. Кагыласы булма!

З ө б ә р җ ә т. Төртмә! Нигә төртәсең?

А й т ү р ә. Үзең ич сукыр чебен төсле күзгә керәсең.

З ә к я т б а н у *(араларына кереп)*. Күрекле бикәләрем сау булсыннар! Минем арттан яшьләр генә иярә ала.

А й т ү р ә. Үзем, үзем! Җибәрегез, җибәрегез мине алга!

З ө б ә р җ ә т. Тора тор, ашыкма!

А н а с т а ч. Туктагыз, тукта!

А й т ү р ә. Муеныңны сузма!

А н а с т а ч. Этмә!

З ө б ә р җ ә т. Төртмә!

А й т ү р ә. Җибәрмә, җибәрмә!

Кабатлыйлар. Төрткәләшеп чыгалар.

***Редакциядән:** әсәрнең дәвамын тулысынча www.beznenmiras.ru сайтында укырга мөмкин.* ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

БӘЕТЛӘР (Тукай турында). Мондый бәетләрнең «Шагыйрь Тукай бәете», «Тукай бәете» исемнәре белән ике варианты басылган (татарлар һәм башкортлар яшәгән төбәкләрдә Т. турындагы бәетләрнең башка вариантлары да табылган). Беренчесе — «Тукай үлү мөнәсәбәтилә. Илаһи бәет» тәүге тапкыр «Кояш» газетасында (1913, 11 апр.) «Г.» имзасы белән басыла. Бәетнең кайда язып алынуы һәм язып алучының фамилиясе газетада күрсәтелмәгән (әлеге вариант тулысынча яисә кыскартылып «Татар халык иҗаты» һәм «Бәетләр» җыентыкларында (1951, 1954, 1960, 1983) урын ала). Бәетне матбугатка тәкъдим итүче кайсыдыр бер авылның яшьләре яраткан шагыйрьләре үлүен ишеткәч үк бәет чыгаруын әйтә. Аның аңлатмасында мондый юллар бар: *«Безнең авылга мөхтәрәм шагыйремез Габдулла Тукаев җәнапларының вафат хәбәре шимбә көн сәгать 10да килеп җитте. Килү белән хәбәр бөтен авылга таралып та өлгергән. Шул көн килгән ике нөсхә «Кояш», өч нөсхә «Йолдыз» йорттан йортка йөртелеп укылган. Яшьләр, картлар, карчыклар — авыл халкы аның яшьли заигъ булуына чын күңелдән кайгырганнар. Кич, ясигъдан соң, күл буена төшеп утырдым. Миннән ерак та түгел, бер мунча янында, авыл яшьләре җыелып, касдан моң гына, зәгыйфь кенә чыгарылган гармонь тавышына бер-икесе авылда гына була торган саф тавыш белән җырлыйлар, башкалары тыңлыйлар иде. Җырлары ачык ишетелмәсә дә, арада «шагыйрь Тукай» дигән сүзләр ишетелә иде. Мин: «Бу ни! Болар ни җырлыйлар?» — дип, чынлап тыңлап карасам, үзләренең шагыйрьләре хакында бер бәет тәртип кылып, шуны көйләп утырганлыкларын сиздем. Иртәгесен бәетләрен табып алдым»*. Икенчесе турында «Тукай Башкортстанда» (1966) китабының аңлатмасында 1948 елда Башкортстанның Чакмагыш районы «Йөрәктау» колхозчысы Шаһибәк Биктимеров кульязмаларыннан күчереп алынганлыгы, башлап «Башкорт халык иҗаты» җыентыгының I томында (1954) басылганлыгы әйтелә, ләкин «Татар халык иҗаты. Бәетләр»нең (1983) искәрмә һәм чыганаклар өлешендә «Тукай бәете» алда аталган җыентыктан алынганлыгы күрсәтелсә дә, «кемнән язылганы күрсәтелмәгән» дигән хәбәр бар.

Халыкның Т.га кайнар мәхәббәтен чагылдырган бу бәетләрнең башлам өлешендә XIX йөзнең урталарыннан алып революциягә кадәр чыгарылган бәетләргә хас булганча, «бисмиллаһи вә биллаһи» белән башланып, традицион рәвештә вакыйганың елы, ае һәм көне күрсәтелә һәм сүзнең кем турында баруы белдерелә: *«Тукыз йөз дә унөч елда, апрель икесендә, Тукай мескен вафат булган Клячкин больницасында»* яисә *«Тарих мең дә тугыз йөз дә унөч елы бу вакыт, апрельнең икесендә җырчыбыз Тукай вафат»*. Бу традиция, нигездә, безнең тарихи бәетләребез өчен хас күренеш. XVI йөзләрдә туган бәетләрдә үк кереп киткән бу традиция соңгы чорларда да дәвам иткән.

Тукай бәетләре фаҗигале. Алардагы фаҗига аерым шәхес фаҗигасе генә түгел, ә вакытсыз үлем нәтиҗәсендә барлыкка килгән халык фаҗигасе буларак яңгыраш ала, чөнки халык үзенең яраткан бөек шагыйрен бик яшьли, бик иртә югалта, килешмәскә тырышып Әҗәлгә дәгъва да белдереп ала: *«Ак келәтнең келәсен элә белми эләсең, / «Әҗәл» агай, син нишлисең, килә белми киләсең»*. Авыл яшьләре дә, картлар да Т. үлеме турындагы хәбәрне ишетү белән тирән кайгыга чумалар: *«...Җырла, моңай, саргай, үл, / Матур Тукай калмагач», «...Тукаен җуйган яшьләргә / Ходай бирсен сабырлык»* һ.б. Тукайның 27 яшендә үк вафаты — көтелмәгәндә чыккан бәхетсез хәлләр нәтиҗәсендә килеп туган драматик фаҗига трагизм категориясе белән якын гына тормыйча, бер-берсенә күчә — тыңдәшсез зур югалту булып аңлашыла, бу фаҗиганең аянычлы нәтиҗәсе, аның кайтара алмаслык олуг югалту китерүе: *«Шагыйрьләргә шагыйрь иде / Ул Тукай заманында...»* яисә *«Син идең бит барча акын, / бар шагыйрьнең акыны...»*, *«Син идең бит һәммәбезнең моңлы җанлы шагыйре, Син идең бит халкыбызның солтаны һәм шаһ ире»*, *«Ни дигән сүз: милли шагыйрь / Габдулла Тукай вафат? // Бумы? Бу бер якты йолдыз яки нурлы ай вафат»*, *«...Безне ятим калдырып китте / Безнең шәп шагыйрь»* һ.б. Әлеге юллардан күренгәнчә, фаҗигале хәл тудырган югалту халыкның чыгарган нәтиҗәсе буларак түбәндәгечә гәүдәләнә: матурлык юкка чыккан, яшь гомер харап булган һәм иң мөһиме — халык ятим калган.

«Тукай бәете» вариантында башка бәетләр белән чагыштырганда фаҗига тудыручылар да, турыдан-туры булмаса да, гаепләнә: *«Мохтаҗлыкта яшәде ул, / Байга бурычка батып, // Сәүдәгәрләр баедылар / Аның китабын сатып»*. Әлеге юллардан аңлашылганча, җәмгыятьтәге строй, аның башында торучы түрәләр халкыбызның сөекле улын шундый көнгә китереп җиткерә.

Тукай бәетләренең бетем өлеше дә бар. Беренче вариантта ул мәңгелеккә саубуллашу буларак яңгырый: *«Кабереңдә тыныч йокла, / Җаным, шагыйрем минем»*, ә икенчесендә Т.ның үз сүзләре китерелеп: *«Җырлый-җырлый үләрмен мин, — диде Тукай, — үлгәндә дә»* шагыйрьнең үлемсезлеге *«яшәү һәм үлем фәлсәфәсе»* аша аңлашыла: *«Тере калды җыры белән, / Җисемен җиргә күмгәндә дә»*.

Илмир Ямалтдинов ■

Әсәр.: Шагыйрь Тукай бәете; Тукай бәете. Текстлар // Татар халык иҗаты. Бәетләр. К, 1983. Б.37-38, 297.

Әдәб.: Бәетләр. К., 1960. Б.236, 374; Ярми Х. Татар халкының поэтик иҗаты. К., 1967. Б.253—283; Урманчеев Ф.И. Халык авазы. К, 1974. 178 б.; Татар халык иҗаты. Бәетләр. К, 1983. Б.37-38, 296-297; Бакиров М.Х. Татар фольклоры. К., 2008. Б.262-299.

САЛИХ СӘЙДӘШЕВ
(1900-1954)



Салих Сәйдәшев артист Нури Сакаев истәлегенә «Матәм маршы» язган төннән соң. 29 февраль, 1927 ел

1954 елның җәенә Салих Сәйдәшевнең сәламәтлеге шактый начарлана. Әмма табибларга барып күренүне кирәк тапмый, беркемгә дә бу хакта белгертми. Бертуган Әминә апасының улы Үзбәк Әхмәров кына, табиб буларак, абыйсындагы үзгәрешләрне сизә һәм шактый озак бәхәсләшкәннән соң, ниһаять, хастаханәгә керергә күндерә.

Сәйдәшне Тукай һәм Пләтән (хәзерге Сәйдәшев) урамнары чатында урнашкан партия элитасы дәвалана торган сырхауханәгә (ул вакытта «Домрачев клиникасы» дип йөртелә) яткыралар. Диагноз: сул үпкәдә су тулган шеш (киста). Озакламый табиблар консилиумы аны Медицина фәннәре академиясенең Мәскәүдә урнашкан А.В.Вишневский исемендәге Хирургия институтына юлларга карар кыла.

Салих Сәйдәшев белән бергә, озата баручы һәм сиделка сыйфатында, хатыны Асия Казакова да юлга кузгала. Озакламый Казанга телеграмма килә: «Операция уңышлы узды. Барысы да яхшы».

Әмма соңыннан һич уйламаган хәл килеп чыга. Бу көнне хатыны, нишләптер, ирен ялгыз калдырып, хастаханәдән кайтып китә. Урыныннан кузгалыр өчен кемгәдер ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә кыенсына булса кирәк, композитор үзе тора, ләкин бәхетсезлеккә, абынып егыла, хәле шунда ук начаралана — эчке җөйләре сүтелеп, кан сава (внутреннее кровотечение), күрәсең.

Салих Сәйдәшев 1954 елның 16 декабрендә бакыйлыкка күчә.

Гәүдәсен махсус очкычта Казанга алып кайталар. Бәхилләшү Академия театрының фойесында уза. Заһид Хәбибуллин скрипкасы елый, оркестр мәгълүм «Сакай маршы»н уйный. Ан-

нары Татар зиратына алып китәләр. Ул вакытта ТАССР Министрлар Советы каршындагы Сәнгать эшләре буенча идарә җитәкчесенең урынбасары Р.Хәмидуллин искә алганча, күренекле сәнгатькярне соңгы юлга озату вакыйгасын мәңгеләштерергә теләп, телевидениедән оператор-төшерүчеләр килә, әмма аларга китәргә кушыла: «Эта не та фигура», — диләр.

Күмү-җирләү эше тәмамланганда кемдер: «Аның маршын уйнарга иде», — дип пышылдый. Бу сүзләр оркестрга барып җитә. Музыкантлар югалып кала: зиратта шундый күтәренке, дәртле марш уйнау әдәп кысаларына сыярмы соң? Алай эшләргә ярармы? Ахыр чиктә, уйныйлар. Шулай итеп, Салих Сәйдәшевне кабергә «Кызыл Армия маршы» озата.

__Рүзәл Мөхәммәтша__ әзерләде.

1. Дильбар Саинова-Ахмерова. Салих Сайдашев. Страницы жизни и творчества композитора. — 2-ое издание. — Казань: Татарское книжное издательство, 2009. — С.182-188.

Композиторның исән чакта төшкән соңгы фотосурәте. Кызыл Байрак. 1954 ел

Салих Сәйдәшев табутта

Театр белеменең йөзек кашы

Нияз Игъламов

Әти турында язу һәркемгә авыр. Театр тәнкыйтьчесе исәпләнгән угылга театр белгече булган әтисе турында язу – икеләтә авыррак, чөнки җаваплылык хисе арифметик прогрессиядә арта. Каләмен сәнгать дөньясын яктыртуга җиккән кеше өчен «ялгыш фикерле» дигән гаептән дә зуррак гаеп һәм абруйдан да зуррак кыйммәт юк.

Рәүф Игъламов – татар театрының күренекле тарихчысы һәм теоретигы, хәзерге театр процессының иң яхшы аналитигы, дисәм, мәкалә авторының дәрәҗәсен төшермәмме, аннан да бигрәк, мәкалә каһарманының намуслы исемен тапламаммы? Юкса, әтиеңне масштаблырак, мәһабәтрәк итеп күрсәтергә теләү – гайре табигый хисмени? Юк. Әмма телгә алынган сыйфатлар Рәүф Игъламовның фәнни-педагогик эшчәнлегенә, тәнкыйди чыгышларына, чыннан да, туры килә икән, ул очракта нишләргә соң? Хезмәтләрен һәм аларның татар театры өчен әһәмиятен анализлаганда шәхси якын килүне хупламыйм, алай гына да түгел – инкяр итәм. Шуңа да укучы белән килешеп карыйк: театр белгече Рәүф Игъламов турында сөйләгәндә, объектив һәм гадел булырга тырышырмын, әтием турында сөйләгәндә – кичерегез, юк.

***

Рәүф Мәхмүт улы Игъламов 1941 елда тәүге татар профессиональ архитекторларыннан булган Мәхмүт Камал улы Игъламов гаиләсендә дөньяга килә. Балачагыннан ук театр сәнгате белән мавыга, драма түгәрәгенә йөри, училищеда укып, «драма театры актеры» белгечлеген ала. Аннары Ленинград дәүләт театр, музыка һәм кинематография институтын (ЛГИТМиК), атаклы галим В.А.Сахновский-Панкеев җитәкчелегендә аспирантура тәмамлый, бераздан (кызганыч, ул вакытка фәнни җитәкчесе дөнья куя) Кәрим Тинчурин иҗаты буенча диссертация яклый, шул рәвешле, бу исемне совет сәнгать белеме «әйләнешенә» кертеп җибәрә. Институт ишеген ябып чыкканнан (1971 ел) алып бәхетсезлеккә тарыганчы, ул мәдәният институтында (соңрак мәдәният һәм сәнгать академиясе, университеты дип атала) укытты, ассистенттан башлап профессор дәрәҗәсенә иреште, кафедра җитәкләде, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе булды. Бу елларда Рәүф Игъламов тәнкыйть мәкаләләре бастырды, спектакльләрне тикшерде, бәһаләде, фәнни-педагогик эшчәнлеген җәелдерде, республикабызның һәм Россиянең театраль тормышында актив катнаша килде, нәтиҗәдә, театр җәмәгатьчелегенең ихтирамын һәм мәхәббәтен казанды.

2000 елның маенда әти ике яклы инсульт кичерде. Шуннан тернәкләнеп китә алмады. Моннан соң да савыкмаячагы бүген көн кебек ачык. Бу хәлне

мин башта гаиләбезгә төшкән күңелсез вакыйга буларак кабул иттем, әмма соңрак күзем ачылды һәм татар театр тәнкыйтен, педагогикасын, фәнен нинди зур афәт басканын аңлый башладым. Әти биләгән урынны бушлык яулады… Җитмәсә, сырхау алганда, ул докторлык диссертациясен (XX гасырның беренче яртысындагы татар театры турында) төгәлләп килә иде, болай да җәрәхәтләнгән йөрәкне ошбу хакыйкать тагын да җәрәхәтли төште. Татар сәнгате кичергән ифрат зур югалтуны беркадәр киметер өчен әлеге юлларның авторы әтинең кулъязмаларын җыярга, өйрәнергә, системага салырга кереште, үзенә анык максат куйды: Рәүф Игъламовның моңарчы беркайда дөнья күрмәгән яисә үзгәртелеп басылган докладларын, мәкаләләрен, рецензияләрен, кайбер актерларны сурәтләгән язмаларын туплап, җыентык чыгарырга! Эш үз эченә суырып алды. Әмма озакламый бер-бер артлы мәшәкатьләр дә тумады түгел: баксаң, язмаларның байтагы редакцияләнмәгән хәлдә ята, төзәтмәләр күтә, чыганаклар белән баетылуны яисә чагыштыруны сорый икән; әти аларның барысын да

Рәүф Игъламов. 1968 ел

Җәмәгате Әдилә ханым һәм улы Нияз белән. 1977 ел



хәтерендә тоткандыр, билгеле; миңа исә баш күтәрми китапханәләрдә һәм архивларда утырырга туры килде. Кайбер хезмәтләр искәрмә сорый иде, кайберләре — өслүби (стилистик) редактура, кайберләре — гади-гадәти дата куюны... Нөсхәләрнең, эчтәлекләренең бик нык үзгәлеге, яхшылар арасыннан иң яхшысын сайлый алмау да изалады... Ихтимал, текстологик проблемаларның күбесе (барысы ук дип әйтмим) минем театр тарихы һәм теориясе мәсьәләсендә бихәбәрлегемнән дә килгәндер. Шуңа да, җаваплы эшкә башаяк чумгач, гыйлем һәм осталык ягыннан аксавым чамаланды, мондый җитешсезлекне һөнәри белем алып кына бетереп була иде.

Фәкыйрегезне театр да, аның тарихы да һәрвакыт кызыксындырды. Күп кенә актерлар һәм режиссерлар пәрдә артында үсә, диләр бит. Мин дә шундый идем. Теге яисә бу тамашадан соң өйдә әти белән без озаклап бәхәсләшергә яисә, киресенчә, таң калып ризалашырга, уртак фикергә килергә мөмкин идек. Билгеле, бәхәсләр бернинди ташламасыз-нисез барды — мин, күп дигәндә, үз фикеремдә кала бирдем. Хәер, каршы якның мантыйкый дәлилләре һәм эрудициясе барыбер, нигездә, үземнең ялгышымны, фикерләвемнең сыеклыгын танырга һәм «коточкыч» көнләшергә мәҗбүр итә иде. Кыскасы, шулай бервакыт ошбу өлкәне җитди өйрәнәсем килде, тәвәккәлләп, Санкт-Петербург дәүләт театр сәнгате академиясенә барып кердем.

Үз биографиямә шулкадәр күп урын бирүемнең бердәнбер сәбәбе — кулыгыздагы мәкаләне язарга һәм әтинең мирасын тупларга-эшкәртергә нәсел ягыннан гына түгел, һөнәри яктан да хокуклы булуымны күрсәтү өчен иде...

Татар театры турында фәнни хезмәтләр аз, бик аз, байтак җитди мәсьәләләр әле дә үзенең тикшерүчесен көтеп ята. Бүген тәгаен мәгълүм: безнең театр тарихы һәм теориясе кайбер, тәүге карашка, какшамас, җимерелмәс тоелган постулатларны энә күзе аша үткәрүне, яңабаштан тикшерүне сорый. Беренче чиратта фикерләү (осмысление) методологиясенә кагыла бу: театр тарихының барлыкка килү һәм үсеш этапларын чорларга бүлү, теге яисә бу сәхнә әһелләренең мәдәниятькә керткән өлеше, аерым бер куелышларның кыйммәте, гомуммәдәни вазгыятьнең төрле тарихи дәвердә театр процессына йогынтысы һ.б., һ.б. Татар театр белеме өчен традицион булган тарихи-генетик метод та сүсәрде кебек. Тарихи-биографик фрагментарлык — сүз уңаеннан, безнең белгечләрнең яраткан методы — белән хәлләр тагын да мөшкелрәк, ул, гомумән, киләчәккә өмет уятмый. Театральлек типларын җәмгыяви-мәдәни контекстта өйрәнеп, театр тарихы проблемаларына киңрәк караш ташларга тырышу зарур. Билгеле, типологик һәм социологик методларны да универсаль санарга ярамый. Тискәре очракта эстетика һәм идея принципларын зигзаг сыман алыштырган гаять катлаулы татар театры тарихын кирәксез гомумиләштерүләргә, башка халыкларның театраль мәдәниятенә охшатуга, хәтта яңа төр, заманча вульгар социологизмга барып җитү мөмкинлеге барлыкка киләчәк. Гомумән, гуманитар фәндә методологик универсалияләр була алмый да. Әмма бүгенге театр дәрәҗәсенең бүгенге театр белеме дәрәҗәсе белән тәңгәлләшмәгәнен күреп, шуны танырга кирәк: фән тарихи-генетик герменевтика ягыннан тарихи-функциональ метод, типологик һәм структур анализ, театр процессының җәмгыяви-мәдәни закончалыкларын өйрәнү тарафына шактый шуышырга тиеш әле... Монда театраль семиотика, аның прагматика дип аталган һәм сәхнә белән зал арасындагы коммуникатив мөнәсәбәтләрне өйрәнгән өлкәсе герменевтикага ярдәмгә килергә мөмкин. Бу фикерләр, кай урыннарда гомумирәк төстә, кай урыннарда төгәл формулировкалар, үзгә төшенчәләр рәвешендә Рәүф Игъламов текстларында сибелеп ята. Алар — XXI гасыр татар театр

белеме нигезенә кереп ятасы ташлар, дип фаразларга да җөрьәт итәм.

***

Теорияләр белән мавыгу, урыс һәм чит ил галимнәренең типологик яктан охшаш, әмма, шулай да, үзгәрәк өйрәнү объектлары нигезендә барлыкка килгән методологиясен берьяклы гына аңлау да куркыныч тудыра. Хәтта Назим Ханзафаров кебек күренекле галим дә милли үзенчәлеккә һәм җәмгыяви-тарихи фонга игътибар итмичә, татар комедиясенең килеп чыгышын халыкның көлү (смеховой) культурасына кайтарып калдыра. Татар комедиясенең тамырында яткан гайрәтле демократизм, Михаил Бахтинның абруе кебек үк, һичкемдә шик уятмыйдыр, анысы. Шулай да, ул (XX гасырның иң зур мәдәният белгече) игътибарын Урта гасырлардагы, Яңарыш чорындагы рәсми һәм халыкчан культуралар диалогының аерымүзгә җәмгыяви-мәдәни ситуациясенә юнәлтә (бу диалог традицияләрен Аурупада Франсуа Рабле (1494-1553) гына «сындыра»). Бездә исә, драматургиянең коточкыч тиз алга китүе аркасында, бу культуралар, бер-берсеннән изоляцияләнгән хәлдә, «өлгереп» һәм диалог урнаштырып җитешми.

Драматургиянең әдәбият һәм театр кебек ике аерым күренеш чигендә яшәгән сәнгать феномены булуын танырга теләмәгән филологлар, әдәбиятчылар җитди кимчелек җибәрә: алар пьесаның поэтикасын проблематикага, хәтта тематикага буйсындыра, беренче әдәби пластны — фабуланы — чишүгә һәм интерпретацияләүгә төп басым ясый. Эш шунда ки, иң шәп, классик татар драматурглары — кендеге белән театр сәнгатенә береккән, аларның пьесасын сәхнә үзенчәлекләреннән гайре карау — ялгыш, ә XXI гасырда — бөтенләй ярамый торган гамәл.

Шушы урында без Рәүф Игъламовның тарихи-театраль уйлануларындагы төп фигурага — Кәрим Тинчуринга якынлашабыз. Тинчурин

«Әти Кәрим Тинчурин исемен совет сәнгать белеме «әйләнешенә» кертеп җибәрде...»

әтинең диссертациясе һәм монографиясе каһарманына әверелде, тарихи-теоретик һәм хәзерге заман театрына кагылышлы хезмәтләрендә ул, әти, аны, Тинчуринны, татар драматургиясенең этик, эстетик яктан камиллеген (яисә камилсезлеген) чагыштырырга мөмкин булган үлчәү итеп күтәрде. Бу бер дә очраклы түгел. Чөнки, типологик яктан карасак, Кәрим Тинчуринны Шекспир, Мольер, Островскийлар белән бер рәткә куярлык, татар театры үсешендә аның драматургиясе әле телгә алынган бөекләр иҗаты сыман ук хәлиткеч роль уйнаган.

***

Рәүф Игъламовның күп кенә хезмәтләре әллә кайчан матбугатта дөнья күрергә тиеш булса да, «Испытание временем» җыентыгы чыкканчы (Казан, 2007) алар гаилә архивында гына сакланды. Мәкаләләрнең басылмавы, гадәттә, бер бик җитди сәбәпкә килеп төртелгән: автор сынфый көрәш темасына эчпошыргыч аз игътибар итә, уңай каһарман эзләми! Рәүф Игъла-

мов, марксистик-ленинчыл эстетика методологиясен яхшы белгән хәлдә, кулыннан килгәнчә, милли мәдәниятне иҗтимагый-икътисади формация һәм «социалистик реализм», «пролетариат әдәбияты» кебек вакытлы күренешләр кысасына кертмәскә тырыша. «Безнең замандашыбыз Камал» мәкаләсе исә матбугатта чыккан сирәк язмаларның да ни дәрәҗәгә китерелүенә, нинди «редакцияләүгә» дучар ителүенә, ничек үзгәртелүенә күңелсез мисал булырлык: теләгән кеше җыентыкка кергән (һәм татарчасы «Безнең мирас» журналының бу санында урын алган) нөсхә белән «эшкәртелеп», «Коммунист Татарии» журналында (№4, 1989) басылган нөсхәне чагыштырып карарга мөмкин. Бу, юкса, 1989 ел бит инде — үзгәртеп коруның аяк терәп сүзен әйткән чагы!

Туксанынчы елларда материалны бастырыр өчен идеологик чикләр юкка чыга, аның каруы, үзгә проблемалар борын төртә: цензураның бетүе матбугатта дилетантлык тантана итүгә китерә, озакламый бәгъзе басмалар зәвыксыз укучы өчен азык була, ә гуманитар фәннәрнең, гомумән, дәрәҗәсе төшә. Бу вакытта Рәүф Игъламовны мәдәният академиясендә кафедра мөдире итеп куялар, аңа театр факультеты ачу бурычы йөкләнә. Педагогика һәм, нигә яшерергә, тамак кайгысы бу чорның беренче яртысында әтинең әдәби-тәнкыйди эшчәнлеген икенче планга күчерә. Гасыр ахырына таба вазгыять алышынгач, дәреслекләре, рецензияләре, мәкаләләре күпләп-күпләп күренә башлый. Шуның белән бергә, докторлык диссертациясе өчен беренчел материалларны үзләштерү эшенә керешә ул, «Әкият» курчак театры тарихы буенча зур хезмәт язарга алына. Педагогик эшчәнлегенең күләме, республиканың барлык театраль вакыйгаларында катнашу, үзен аямыйча иҗат итү Рәүф Игъламовның сәламәтлеген какшата…

Мөхәррирләрнең идеологик казынулары, совет чоры мәрхүм булганнан соң туган башбаштаклык… Әтинең библиографиясе кечкенә булуда (табигый таланты һәм кабилияте каланчасыннан караганда) болардан тыш тагын бер сәбәп бар әле — характер: таркаулыгы, вак-төяк эшләр белән артык мавыгуы, яраша белмәве, бер урында утырып тора алмавы, беркайчан да җитмәгән һәм җитмәячәк вакытны дөрес бүлә белмәве, һәр мәкаләсен, рецензиясен азаккача камилләштереп бетерергә тырышуы. Язганнарының күләмен (ләкин сыйфатын түгел!) киметкән сәбәпләр — шул. Конкрет, әмма төп фәнни кызыксынуларыннан ерак торган темага берәр мәкалә язганда, проблеманы чишү белән мавыгып китеп, ул еш кына язманы тиешле вакытка тапшырып та өлгерми иде. Яисә фәнни конференциядә һәйбәт чыгыш ясаганнан соң, төп тезисларын теркәп куярга, сөйләгәнен мәкалә дәрәҗәсенә җиткерергә уйламады.

***

Бу язмамны мин әтинең мирасыннан бөртекләп җыелган «Испытание временем» китабына кереш итеп ун ел элек әзерләгән идем, хәзер аны «Безнең мирас» журналы өчен җыйнакландырдым, үзгәрттем. Бүген булса, фикерләремне кәгазьгә башка төрлерәк күчерер идем, бәлки, әмма язганнарымның эчтәлеге барыбер үзгәрмәс иде. Мин әле дә әтине иң күренекле татар театры белгеченнән саныйм, аның янына — фәкать ихтирам йөзеннән! — тагын берничә исемне генә теркәп күрсәтә алам.

Китапны без әни белән үз акчабызга чыгардык, тиражы гаять кечкенә булды аның, беркемгә дә ярдәм сорап мөрәҗәгать итмәдек. Җыентыкны үзебез күргәнчә, үзебез теләгәнчә нәшир итәсе килде.

Дөньяга күрсәтү өчен дә бернинди гамәл кылмадым, җыентык хакында ишетеп тә белмиләр — бусына хәзер беркадәр үкенәм дә, билгеле: «Испытание временем» күз ачып йомган арада таралып бетте, ә үземдәге соңгы экземплярны мин шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтшинга бүләк иттем.

БЕЗНЕҢ ЗАМАНДАШЫБЫЗ КАМАЛ*

Рәүф Игъламов

Галиәсгар Камал (1879-1933) турындагы биографик һәм тәнкыйди материал белән танышкан чакта «тикшерүчеләрнең игътибарын үзенә шулкадәр нык җәлеп итә алган, сәхнә практикларының шулкадәр күп истәлекләренә кергән, хатирәләрендә яңгыраш тапкан тагын берәр драматург бармы икән?» дип уйлап куясың. Исән чагында ук Камал искиткеч шәп замандашларының мактау сүзләрен ишетеп калган — ул затлар арасында Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан кебек титаннар да бар — алар тәкәбберләнмичә дә, хуплауга юмартлыклары ташып чыкканга да түгел (аннан гына үз даннары кимемәс иде), ихлас күңелдән каләмкяргә якты йөз күрсәткән; осталыгын югары бәһаләп, драматургны, әдәби иҗатның башка өлкәсендә (ныклы традицияләре турында сөйләү кая, күп гасырлык шигърият белән прозадан аермалы, татар әдәбиятының әле генә, күз алдында гына барлыкка килгән яңа тармагында) көч түксә дә, үзләренә тиң күргән.

Тугры Тукайның шундый сүзләре бар: *«Татар тормышының, Казан мещаннарының билгесез якларын сәхнәдә якты кояш кеби күрсәткән Галиәсгар әфәнде — ул татарның Островские!»*

Татар драматургиясенә нигез салучыларның берсе — Галиәсгар Камал тәүге пьесасын 1898 елда, унтугыз яшендә иҗат итә. Казанда тире эшкәртүче хезмәткәр гаиләсендә туган Галиәсгар бик катлаулы тормыш университетлары аша уза. Башта «Госма-

Рәүф Игъламов. 1999 ел

ния», аннары алдынгырак карашлы «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә, өч ел шәһәр училищесында укый, әмма болар да яшь егетнең гыйлемгә сусавын баса алмый. Камал урыс телен өйрәнә, һәрдаим үзлектән белем туплый. Туксанынчы елларда театр сәнгате белән мавыга башлый. Ул чакта Казан Драма һәм опера труппасының гөрләгән чагы. Россиянең иҗтимагый тормышын яңа шаукымнар басу икенче, башка төрле театраль формалар эзләүгә дә китерә, шуның бер нәтиҗәсе булып гасырлар чигендә Мәскәү Сәнгать театры ачыла. К.С.Станиславский һәм В.И.Немирович-Данченконың «уртак баласы» провинцияләрдә кайнаган театр тормышына да, киң катлам җәмәгатьчелекнең мәдәни таләпләренә

* Эчтәлеген үзгәртерлек дәрәҗәдә куркыныч «редакцияләнгән», бик нык кыскартылган хәлдә «Коммунист Татарии» журналында (№4, 1989) басылган иде. — Нияз Игъламов искәрмәсе.

Галиәсгар Камал. 1902 ел



«Беренче театр» комедиясенең кулъязма бите (факсимиле)

дә йогынты ясамый калмый. Россиядә алдынгылардан саналган Казан урыс театрының сәхнәви трактовкалары татар яшьләре арасында да һәвәскәр театрлар хәрәкәте уята. Камал спектакльләрнең даими тамашачысына әверелә, күп укый; кайбер пьесаларны татарчага тәрҗемә итә, «Бәхетсез егет» исемле драматик әсәрен яза.

Галиәсгар Камал иҗаты татар драматургиясендә беренче карлыгачлардан саналган Габдрахман Ильяси һәм Фатих Халиди пьесаларыннан гаять нык үзгә. «Бәхетсез егет» — камил әсәр түгел, дигән фикерләр йөрсә дә, моның белән һичничек килешергә ярамый. Әлбәттә, ун ел узгач кергән төзәтмәләр, үзгәрешләр пьесаны яхшырткан, ләкин аның беренче нөсхәсе дә Ильяси-Халиди пьесаларыннан күпкә сыйфатлырак. «Бәхетсез егет» тукымасына мәгърифәтчелек, дидактика рухы кереп китү, бездә кабул ителгәнчә, әсәрнең сәнгати йомшаклыгы турында сөйләргә сәбәп була алмый. Җөмләдән, искәрик: үтелгән өслүпләрнең (стиль) шундый кайтавазы тарихта еш очрый, бу — сәнгатьнең зәгыйфьләнүе хакында чаң кагарга нигез түгел әле. Мәгърифәтчелек тенденцияләренә килгәндә, алар соцреализм чәчәк атканда да үсенте бирергә җирлек тапты.

«Бәхетсез егет»не махсус рәвештә кимсетеп күрсәтү, кызганыч ки, драматургның эволюциясен ачыклауда гомуми бер программага әверелде: әүвәл көчсез әсәр, соңрак өйрәнчеклек чоры, аннары инде бертуктаусыз үсү, үсү һәм, ниһаять, шаһәсәрләре — «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре». «Алга һәм өскә» принцибын нигез иткән схема, ни гаҗәп, сугыш алдыннан драматургның активлыгы кимүен һәм, совет дәверенә кергәч, гомумән, мондый формадан читләшүен аңлатып бирми.

Бу ни дигән сүз? Димәк, Камал драматургиясенең эстетик приоритетлары ачыкланмаган, иҗатының төп, нигезле, мәңгелек яклары вакытлы, очраклы өлешләрдән аерылып күрсәтелмәгән. Гомумән, драматургның

сәнгати тигез үсмәве, тема белән шигъри «гәүдәләнеш»нең, сәләте белән дөньяны кабул итү рәвешенең туры килмәве — кызыклы тема; шуңа да карамастан, бу мәкаләдә без мәсьәләнең ул ягына кагылып тормабыз. Әдәбият тыныч кына, бер килеш кенә үсә-үзгәрә алмый. Ул тартылып, ыргылып та барырга мөмкин — дөнья драматургиясендә моңа байтак мисаллар очрый.

«Бәхетсез егет»тән татар драматургиясе яңа чорга аяк баса, дип ышанып әйтергә ярый. Бу, беренче чиратта, драматургик лексикада чагыла. Урамнарда, шәһәр бакчаларында, чәркәханәләрдә, сәүдә йортларында тантана иткән ирекле стихия пьеса битләренә килеп керә, персонажларның семантик, функциональ «төгәл» сөйләме кинәт идиомалар белән ныгытыла, җирле һәм һөнәри сөйләмгә, сленгка, аргога йөз тота башлый. Шушы «күптавышлылык» һәм «төгәлсезлек»ләр аркасында тел хисси төсмерләргә байый, драматизмның, конфликтның төшенә, каһарманнар характеристикасының сурәтенә әверелә. Керткән яңалыкларының инкыйлабый булуын Камал үзе дә яхшы аңлаган: «Бәгъзе кешеләр бу китапны бигрәк урам телендә чыгарган икән, дип көләрләр, бәлкем. Әмма, ни зыян? Көлсеннәр. Дәхи дә, шундый бар кеше дә аңларлык, урам телендә булган китаплар насыйп булсын», — дип яза ул.

Тормыш материалын пьеса сюжетына ирекле, табигый рәвештә кертә белүе дә Камал драматургиясенең уңай якларыннан. Әдип персонажларын алдан тапталган сукмаклардан йөртми, аның каһарманнары мөстәкыйль фикерле, алар үзләренең акылына яисә хорафатларына нигезләнеп гамәл кыла. Сюжетка очраклы вакыйганың килеп керүе, аның эчтәлекне төбетамырыннан үзгәртүе дә әсәргә файдага гына.

Камал драматургиясе турында сөйләгәндә тагын бер мәсьәләгә игътибар юнәтергә кирәк, ул да булса — фаш ителгән җәмгыяви адресларның нисбәтилеге. Кайбер фикер ияләре: «Камалның иң зур мәртәбәсе — монафикъларны, татар сәүдәгәрләренең комсызлыгын һәм бозыклыгын, мөселман руханиларының фанатиклыгын һәм туемсызлыгын, буржуазиянең дорфалыгын һәм наданлыгын ачып салу», — дип тәкърарларга ярата. Көчле сүзләр. Әмма бу караш безне, бүгенге куелышлары белән дә игътибарыбызны җәлеп иткән «чын» сәнгатькяр Камалдан шактый ерагайта шул, чөнки аның пьесаларында яшәгән җәмгыяви типажлар мәңгелеккә үткәндә калды, юкка чыкты. Тарих күзлегеннән караганда, алар бик мөһим фактлар, билгеле; әмма драматургия классикасының эчтәлегендә гомумкешелек башлангычлары урын алганда гына театр теге яисә бу әсәр белән кызыксынырга мөмкин. Яхшылык-начарлык турындагы фикерләребезне анык күзаллаган һәм бүген дә театр репертуарыннан төшмәгән «тере» классикка мөнәсәбәтебезне дә, карашыбызны да үзгәртергә вакыт. Хәер, хәтта тарихи-әдәби анализ ярларында торып фикер йөрткән хәлдә дә, Камалның көче фаш итү белән генә чикләнәме соң? «Каениш» пьесасын карыйк. Габсаттар белән Гөлбану (хатыны) кебек көлкеле образларда җәберләүче-эксплуататор күрер өчен кешегә бик бай фантазия кирәк. Болар — очын очка ялгап яшәүче «урта сыйныф» вәкилләре, мещаннар. Мәсәлән, «Бүләк өчен» әсәре. Монда, чыннан да, хәлле кешеләр катнаша: Әхмәтҗан — Казан сәүдәгәре, Габдуллаҗан — студент булса кирәк (фәкыйрь халык андый белем алу югарылыгына җитмәс иде). Нигә соң, алайса, акчалы кәләшкә өйләндереп, улын бәхетсез итәргә теләмәве, әдәплелеге белән бай бездә мәрхәмәтлелек хисе уята? Ата-угылга капма-каршы рәвештә, Хәмидә — саран, комсызлык — бу хатынның төп сыйфаты. Ул заманның «дөрест» татар әдәбияты хатын-кызны көчле җенес тарафыннан кимсетелүче, мыскылланучы җан иясе итеп сурәтләгән, ә Камал, күрәбез ки, монда

да, башка комедияләрендә дә (шул ук «Банкрот»ны алыйк) «тере курчак»ны, «феодаль җитештерү мөнәсәбәтләре» вәкилләренең «уенчыгы»н «илаһилаштырырга» уйламый да. Нигә «Банкрот»тагы Сираҗетдин (аның малы Әхмәтҗаннныкыннан шактый күп), төп гамәленең түбәнлегенә карамастан, усаллыгының «сөйкемлелеге», максатына ирешәм, дигәндә нык булуы, чайкалмавы, «сугышчанлыгы» белән үзенә карата соң?

Мөселман руханиларының фанатиклыгын фаш итүгә килгәндә, монда, гомумән, буталчык килеп чыга. Безгә Камалның дин әһеле катнашкан бер генә пьесасы мәгълүм — «Уйнаш», анда да ул сюжет өчен ярдәмчел функцияләр башкарган эпизодик персонаж гына — күзгә төртеп тә тормый, кайдадыр артта, тоныграк фонда һәм автор аны, ни дисәң дә, нигездә, уңай бәһали. Камал пьесаларына кергән очраклы бу персонаж аркасында гына «фаш итү» эшендә сәүдәгәрләр, буржуазия һәм руханилар арасында тигезлек билгесе кую — ким дигәндә, саксызлык булыр иде.

Шул ук вакытта, инкыйлабка кадәрге журналистлык эшчәнлеге, сатирасы Камалны, чыннан да, һич бәхәссез, «фашлаучы» (шул исәптән, дин әһелләрен дә) буларак танырга боера. 1905-1907 еллар инкыйлабын чакыручы җилләр исә башлауга аның өчен драматургия икенче планга күчеп, беренче сафка журналистлык-оештыру эшләре, публицистика чыга. Өстәвенә, ул чорда драма язып кына тамак туймый, матбугат гаиләне туендыручы бердәнбер яшәү чыганагына әверелә. Нәшир буларак, Камал еш кына социал-демократлар, Хөсәен Ямашев белән очрашкалаган. Аларның Камалга ясаган тәэсирен истән җуярга ярамый! Үзе редакцияләгән «Азат» (соңрак — «Азат хатын») газетасында, «Яшен», «Ялт-йолт» сатира журналларында гадел, ләкин кайвакыт берьяклы рәвештә мөселман фанатиклыгына, реакциягә, искелек калдыкларына каршы юнәлтелгән мәкаләләр күп басыла. Бу эшчәнлеге өчен Камалга полиция һәм, җавап бирүче сыйфатында, мәхкәмә бусагасын бик еш таптарга вә киләчәктә дә алдынгы фикерле җәмәгатьчелеккә хезмәт итәр өчен вакыт-вакыт либераль басмалар белән килешергә, уртак тел табарга туры килә.

Заман үзгәрә тора, чагыштырмача ирекле вазгыять һәр юлы рәхимсез цензура тарафыннан киселә: 1905-1907 еллар инкыйлабы төкәнгәч тә шул хәл күзәтелә, империалистик сугыш башлангач та... Кыскасы, Камал сатирада, чыннан да, «фаш итүче» буларак күз алдына килеп баса.

Ләкин без драматургия турында сөйләшәбез ләбаса. Ә монда вазгыять катлаулырак. Әлбәттә, җиңел юл белән китәргә — биш-алты пьесасын аерып алып, Камалны әлеге дә баягы «фашлау» калыбына дыңгычларга мөмкин. Аның каруы, бу очракта да әдипнең үзенә тагылган схемага гына сыешмавын аңлату зарур. Бер яктан, «фаш итүче драматург» образына басым ясарга теләсәк, икенче яктан (барлык пьесаларының корпусын хәтерләгән хәлдә), бу теләккә һичничек ирешә алмасак, Камалдагы һәммә «каршылыклар»ның бик тә аңлашыла торган «кимчелекләр»гә укмашуын күрәбез. Ул уңай каһарманнар тудыра белмәгән, имеш. Әмма Камалның, нигездә, комедия жанрында эшләвен истән чыгармыйк әле, бу жанрда уңай каһарманны сурәтләү зарурлыгы шуның кадәр генә. Әлеге «җитешсезлек» язучының дөньяга тар карашы аркасында хасил кылынган, димәкчеләр. Имеш, ул «бар булмышы белән инкыйлабый-демократик программа дәрәҗәсендә калган». Ярый. Әллә ни рәнҗетә торган сүзләр түгел. Билгеле, Камал, «хәзерге заманның сыйнфый көрәшен хәрәкәткә китергән көчләр» турында тирән уйламагандыр да, аңлап та бетермәгәндер, бәлки; әмма XX гасыр башында кайсы гына язучы пролетариатның хәлиткеч роле хакында тәгаен белеп фикер

«Банкрот»ның Фәрит Бикчәнтәев куелышындагы Сираҗетдин – Радик Бариев

Галиәсгар Камал шигырьләренең бергә тупланып, «Декламацияләр» исеме белән Казанда чыккан аерым басмасы. 1921 ел



برلەشگز بتون دۇنيا اشچيلرى!

غ. کەمال.

دیکلاماتسیەلەر

بیەدی، مەجوی نەظملار، مەم دیکلاماتسیەلار.

شەرق خالقلارى کابمونیستلارینڭ

مەرکەز بیورا نەشرى.

قازان

لوتاپسکی اورامى ۳۱ №

تەمامون ۱۰۸ №

Р. В. Ц. Казань Тираж 10000 экз.

г. Казань 6-я Государственная Типография 1921 года.

Г. Камал шигырьләренең бергә тупланып, «Декламацияләр» исеме белән 1921 елда Казанда чыккан аерым басмасы (тышлыгы).

йөртте икән? Горький, ихтимал? Ихтимал. Вәләкин бу алай җиңел генә җавап бирерлек сорау түгел. Дөньяга караш иҗаттан тыш була алмый. Сәнгать процессы «әүвәл сыйнфый уй йөртү, аннары алдынгы фикерләрнең әдәби образга проекцияләнүе» кебек чылбырны танымый, аны һөнәрчеләр, кәсепчеләр өлге итәргә мөмкин. Ләкин андый затларга Камалның ни катышы бар? Сәяси карашларның консервативлыгын рөхсәт итеп, аларның җәмгыяви юнәлештә иҗат итүчеләргә мәһабәт әсәрләр тудырырга комачауламавын таныган марксизм классикларының мәгълүм нигезләмәсен нишләтергә соң алайса? Бальзакны, Гогольне, Толстойны нишләтергә?

Камал — бөек сәнгатькяр. Әмма ул эзлекле рәвештә сәүдәгәрләрне, буржуазияне эттән алып эткә салган драматург түгел. Ул икейөзлелекне, комсызлыкны, наданлыкны, тупаслыкны фаш иткән! Болар икесе ике нәрсә.

Ахыр чиктә, ни дисәң дә, «татар тормышының, Казан мещаннарының билгесез якларын сәхнәдә якты кояш кеби» күрсәткәнен раслап, Камалны Островский белән бер югарылыкка күтәргән Тукай хаклы шул. Бу, чыннан да, бик зур бәһа!

Камал каһарманнарының төп сыйфаты нинди? Фикер йөртеп караган тиз төшенер: самимилек. Бу — ахмаклык та, гыйлемсезлек тә түгел. Самимилек — ялган оятның булмавы, хәйләгә барырга юл табылганда да үзенчә кала белгән кешенең табигый халәте. Самими затның табигыйлеге һәрвакыт өстен чыгачак, ул, нәтиҗәдә, үзенең дә, башкаларның да ипсез уйланган ниятен җимерәчәк. Самимиләр яхшыга өметләнә, алар хәтта начарлык кылганда да гамәлләрен меңкәррә хаклы саный. Алар, әлбәттә, дәртле

кешеләр, дәрт — гади, табигый, самими кешенең төп сыйфатларыннан. Беренчесе үк булмаса әле.

«Бүләк өчен» комедиясендәге Хәмидә ире белән улын үз ягына аударыр өчен никадәр энергия сарыф итә. Бер уйласаң, нәрсәсе бар инде — бүләк турында яучыдан яхшылабрак сора гына, алай-болай бер-бер хата китмәгәнме? Кодагыйның әдәпсезлегенә төкер, ниһаять — аннан гайре дә кулга бихисап байлык керергә тора лабаса! Юк шул. Мизгел эчендә шартлый! Хәзер кәләш тә «өрәк шикелле», ата-аналары да «аңгыралар», «мәнсезләр». Җитмәсә, Хәмидәнең аферасы ачыла. Туй булмый кала.

Яисә «Каениш» комедиясеннән бер мисалга тукталыйк. Приказчикка юлланган мәхәббәт хаты кулдан кулга йөри. Хуҗабикә, үзенә генә аңлаешлы мантыйкка буйсынып, бәлале мәктүптән имин тормышларына куркыныч яный, дип кабул итә. Ирен яклау-саклау мәшәкатьләре шулкадәр сукырларча дәртле ки, ул хәтта очраклы рәвештә килеп кергән кызның нинди максат белән йөрүен дә сорамый. Гөлбануның ашкынулы тырышлыгы дөньяның астын өскә китерә, ә эш, югыйсә, бик җиңел чишеләсе булган — кунак өйләрне бутаган.

Камал тудырган самими каһарманнарның сөмсезлеге таң калырлык. Алар кабахәтлек эшләргә гөманлаганда да («Уйнаш»тагы кебек) үз мәнфәгатьләрен яшерергә, качырырга уйламый, киресенчә, барлык ниятләрен бик җиңел ачып сала. Драматик сюжетларда да самими каһарманнар үзләренә хыянәт итми — табигатьләре, холыклары куркудан көчлерәк, үлемнән көчлерәк булып чыга. «Бәхетсез егет»тәге Гайни, Закир — шундыйлардан.

Монда бер аңлатма биреп үтү зарур: Камал пьесаларында каһарманнарның гамәлләре (мәсәлән, бәхетсез егет Закирның хыянәтче мәгъшукасын үтерергә теләве, «Банкрот»тагы Сираҗетдинның кредиторларны төп башына утыртырга теләве) һич тә беркатлы түгел. Аларның шушы теләккә ирешү юллары самими. Ник соң алайса Сираҗетдинның нияте чынга аша? Күп комедияләрдә, киресенчә, каһарманнар үз максатына ирешә алмый бит? Чөнки Камал бик нечкә һәм искитмәле рәвештә сюжетны контрастлар «яшен уздыргыч»ы белән тотыра. Гөлҗамал, Камали, Җамали, тинтәклекләре аркасында (самимилектән бер баскыч түбән сыйфат), сәүдәгәрнең кармагына каба, Мәскәүдән «авыруны» фаш итәргә килгән комиссия оятка кала, чөнки алар самими Сираҗетдиннән берничә баскыч «югарырак» тора. Гаять акыллы затлар, үз каланчаларыннан карап, ятьмәне дә биеккә ташлый, белмиләр: бу — түбәннән оча торган «кош» ласа! Комиссия киң күңеллелек күрсәтеп махсус «ялгыша», дигән фикер дә туарга мөмкин — сәүдәгәрләр мәнфәгате казага тарыган аерым бер затларның мәнфәгатен каплап китә, янәсе. Алар үзен Сираҗетдин тарафыннан рәнҗетелгән кредитор халәтенә куеп карый алмый; моральләре, дөресрәге — аморальлекләре шунда: ни генә булмасын — акылдан язу, фәкыйрьләнү — болар берсе дә безгә кагылмый, яхшылык-начарлык берлегенә катнашыбыз юк, дип уйлый алар. Бу яктан караганда доктор хәтта символик мәгънәгә ия. Комедиядә вәхши эгоизм рухы тантана итә.

Камалның барлык каһарманнары — яхшысы да, начары да — бер тукымадан ясалган характерлардан гыйбарәт. Сүзләре белән гамәлләре арасында гармония дә, дөньяга бердәм карашлары да юк, диярлек. Алар тотрыклы чорда, мәңгелеккә урнашкан, катып калган кыйммәтләр заманында яши. Беркадәр аныклык кертик: биредә сүз конкрет XX гасыр башы, торгынлык кичерүче сәүдәгәр-мещаннар мохите турында бармый (гәрчә пьесаны укыганда иң беренче шуларны уйлап куясың).

Шул ук заман, шул ук тормышкөнкүреш шартлары үзгә язучыда катлаулы характерга, каршылыкларда янган зиһенгә әверелә алган һәм, нигә

фал ачарга — әверелгән дә бит: Максим Горькийның «Мещаннар»ын искә төшерик, Сергей Найденов, Евгений Чириков әсәрләрен. Галиәсгар Камал пьесаларындагы персонажларга карата «эчке конфликтлы характер» төшенчәсен кулланып булмый, бу мәсьәләдә ул әле генә телгә алган язучылардан гына түгел, хәтта замандаш татар драматургларыннан (мәсәлән, Фатих Әмирханнан) да аерылып тора. Яшь каләмдәшләре — Мирхәйдәр Фәйзи, Кәрим Тинчурин белән чагыштырганда бу үзгәлек тагын да ныграк сизелә. Гасыр башында яшәгән конфликтлы каһарманнары өчен органик мохит эзләгәндә алар, кабилиятләренең табигатенә туры килгәнчә, йә милли интеллигенция, йә керәстияннәр тормышына мөрәҗәгать иткән. Башка драматургларыбызның каһарманнары агымдагы, үзгәрүчән драматик вакытта гомер кичерә. Мәсәлән, «Галиябану» пьесасындагы уртакулкерәстиян Бәдрине искә төшерик. Аның кем икәнен (киң мәгънәдә) тәгаен аңлап җиткерер өчен драмадагы барлык эчке элементәләрне, кечкенә-вак төсмерләрне исәпкә алырга, җентекле анализларга кирәк.

Камалның каһарманнары исә «үтә күренмәле». Алар нинди бар — шундый. Алар — аңлаешлы. Аларга «тагылган» сыйфатлар — дорфалык, мактанчыклык, саранлык һ.б. — мәңгелек. Бу сыйфатларга ия затларны яктылык тизлеге белән чабып баручы елларда да, ерак киләчәктә дә бик җиңел табып булачак. Халыкның тормышкөнкүреше, яшәү рәвеше үзгәрә, әмма рухи хасияте үзгәрми. Кәзәки кисәң дә, джинс кәчтүм кисәң дә комсызлыкның, тупаслыкның, икейөзлелекнең асылы барыбер шул калачак. Әнвәр бай гыйлем иясенә әверелсә дә, наданлыктан чыкмаса да, барыбер шундый ук бозыклыкта көн күрәчәк. Фәкыйрьме, баймы — Сираҗетдин дә барыбер шундый ук Сираҗетдин булачак.

Фәкать Камалда гына («остазы» Александр Островскийдагы кебек) яхшылык вә яманлык арасында күзгә күренерлек чик бар. Бу ике төшенчә, кешелеклелекнең мәңгелек категорияләре буларак, импрессионизмны, тоныклыкны яратмый — үзара яраклашмыйлар да, берсе икенчесенә күчмиләр дә, сыйныф һәм төркем мәнфәгатьләренә ышыкланмыйлар да. Камал пьесаларында алар мәңгелек көндәш-юлдаш халәтендә. Бөек драматургларга хас театральлекнең сере шундадыр да әле. Театр табигате белән демократик күренеш. Ул кирәгеннән артык катлауландыруны өнәми, ышанычсыз әхлакый юнәлешләрне кабул итми. Телен камилләштереп, эзләнүләр сукмагында кайчак адашып, четерекле тормыш чынбарлыгын анализлау юлыннан барганда, үз-үзен саклап калыр өчен, театр яңадан, яңадан башлангычына мөрәҗәгать итә. Бу башлангыч, әлбәттә, яхшылык белән яманлыкның асыл табигатенә анык караштан гыйбарәт.

Галиәсгар Камал.
Рәссам Ефим Симбирин эше. 1982 ел

1989

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ОРЕНБУРГ – Иске татар китапларында – *Орынбур, Рынбурух.* Исмәгыйль Рәми Оренбургны *Үрән* дип тә атый, чыганакларда шәһәрне *Ур Кала* дип атау да очрый. Кайбер бүгенге китапларда *Ырынбур* һәм хәтта *Ырымбур* язылышлары күзәтелә. Болары «татарчалык»ны гади сөйләм белән бутаудан, ягъни талымсызлыктан башка нәрсә түгел, әлбәттә. Тирәнгәрәк китсәң, атаманың татарчасында төрки «ур» яки «ор» сүзе катнашырга тиеш иде. «Салават бәете»ндә: *«Җаек дигән җәп йир-су, сай йирендә сөңге буйлайдыр, Урунбуркайның ягасында алтынлы тулар уйнайдыр».* Икенче бер бәеттә бу шәһәр «Ранбур» дип телгә алына: *«Яна икән саласы, Ранбурдыр каласы, Мәһди байның тәкъдирендә язган икән янасы».* Каюм Насыйри сүзләренә караганда, «бу шәһәр кадим заманда «Яман кала» дип тәсмия кыйлыныр иде».

Оренбург шәһәренә башта 1735 елда, Орь елгасы буенда крепость буларак нигез салынган (хәзер анда Орск шәһәре) һәм ул алман үрнәге буенча исем («Орь елгасы буендагы шәһәр») алган. Шиһабетдин Мәрҗани кәгазьләрендә: *«1135 сәнә – Кальга Оренбург төзелде – тычкан елы ирде».*

«Орь» сүзе исә төрки чыгышлы, *ур/ор – казылма/чокыр яки өем/өелмә* мәгънәсендә. 1739 елда шәһәрне Сакмар тамагына, 1743 елда исә баштагы урыныннан 280 чакрым көнбатышка таба күчергәннәр. Оренбург шәһәре *«51 дәрәҗә 45 дакыйка гарыз шималида, 72 дәрәҗә 46 дакыйка тул шаркыйда вакыйгдыр»* (Каюм Насыйри). Ә шәһәрнең исеме аңа ияреп килгән. Оренбургны төзү эшен җитәкләүче баш контора һәм штаб Казанда урнашкан була, соңыннан Минзәләгә күчерелә. 1744 елда Оренбургтан ерак түгел татар авылы *Каргалы*, ягъни *Сәгыйть бистәсе* төзелә. Бирегә башлыча Мамадыш һәм Лаеш ягы татарлары килеп утыра (Михаил Глухов). Шул ук елны Оренбург губерна шәһәре статусы алган.

1938 елдан алып 1958 елга кадәр Оренбург шәһәре Чкалов дип аталып йөрде.

Нигез салынып утыз еллап үтүгә инде Оренбургта урысларның саны 5 меңнән артып китү турында мәгълүмат бар. Алардан кала, шәһәрдә күп санлы татарлар, казакълар, фарсылар, әрмәннәр, үзбәкләр, «малоросслар», грузиннар, валахлар, гарәпләр яшәгән.

1740 елда И.И.Неплюев сенатка хәбәр иткәнчә, Бохарадан һәм Хивадан Оренбургка берничә кәрван килгән

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

Оренбургта Тимер юл вокзалы. XX гасыр башы

милләт сәүдәгәрләреннән, атап әйткәндә, урыслардан алты тапкыр күбрәк булган (Альберт Фәтхи, «Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби бәйләнешләр»).

Шәһәрнең үзендә бернинди сәнагате булмаган диярлек. Шуңа күрә бирегә һөнәр белгән җинаятьчеләрне сөрә башлаганнар, зинданда яхшы җиһазланган остаханәләр ачылган, столярлар, слесарьлар, каретачылар, пыялачылар, итекчеләр эшләгән. Төрмә карамагында чүлмәк һәм кирпеч җитештерү фабрикалары булган.

һәм бу кәрваннарның төп йөген Персия көмеше тәшкил иткән (418 пот 23 кадак). Рәсми мәгълүматларга караганда, 1748 елдан алып 1755 елга кадәр генә дә Оренбургка Шәрыктән 50 пот алтын, 4000 пот көмеш, бик күп асылташлар китерелгән. Аларны товарга алыштырыр өчен Мәскәүгә һәм эчке шәһәрләргә вәкилләр җибәреп, андагы сәүдәгәрләрне Оренбург базары белән кызыксындырырга туры килгән. Шушы вакытларда Казаннан күпләп татар сәүдәгәрләре дә күренә башлаган.

Персия алтын-көмешенең күпчелек өлеше Әстерхан сәүдәгәрләре кулына кергән. Шуңа күрә затлы металларның илдән кире «чыгуын» булдырмас өчен, сенат Әстерхан губернаторына ашыгыч төстә боерык җибәреп, моны күз уңында тотарга кушкан.

Оренбург сәүдәсе казнага 40-50 мең сумлык таможня җыемы китергән. Шәһәрдәге сәүдәгәрләр курасы, ягъни Кәрван-сарай («Гостиный двор») Россиядә иң зурлардан булып, анда 300 кибет исәпләнгән һәм алардан казнага ел саен 5000 сумлык керем алынган. Бу двордан тыш шәһәрдән ике чакрымда гына «Азиат» һәм «Бохара» ярминкәләре эшләгән. Берничә йөз казак кораллы каравылда торган, «меновой дворлар»ны туплы отрядлар саклаган. XVII гасыр азагында Оренбург шәһәрендә сәүдә эшен, башлыча, Сәгыйть бистәсе татарлары алып барган һәм аларның саны башка

Мөселманнар (башлыча татарлар) күп яшәгәнлектән, калада берничә мәхәллә исәпләнгән. XX гасыр башларындагы Оренбург халкы турында Фатих Кәрими түбәндәгеләрне яза: *«Оренбургта тәкърибән [якынча], егерме мең кадәр мөселман татар мәүҗүд булып, бонлар башка шәһәрләрдәге кеби кәнделәренә аерым мәхәллә булып утырмамышлар, бәлки урыслар илә катнашып утырмышлардыр. Мөселманнарның алты данә мәчетләре, вә һәр мәчет янында мәктәп-мәдрәсәләре бар исә дә, бу мәктәп вә мәдрәсәләрдә тәгълим вә тәрбия җәһәтләре гаять нәкыс вә касыйрдыр»*. Тагын: *«Оренбург мөселманнары эчендә интеллигентлар (зыялы мөселманнар) бик аз булып, бонлар да хөкүмәт мәэмүриятендә булган бер кач морзадан вә дәһа бер кач әдәмнән гыйбарәттер»*.

Оренбург шәһәренең иске мәчетләре (Шиһабетдин Мәрҗани буенча):

Беренче мәчет. Шәһәр эчендәге мәчетне кенәз Волховский гасырында Бохараның кәрван башы Иш төзеткән, аңа казна да күпмедер ярдәм иткән. Ишнең үзенә тарханлык дәрәҗәсе бирелгән. Бохарадан Оренбургка беренче тапкыр кәрван башы булып шушы кеше килгән, диләр. Язучы Лирон Хәмидуллин исә бу мәчетнең тарихын болай тасвирлый: *«Оренбург каласы төзелгәч, казакъ халкы түрәләрен*

Россиягә тагын да якынайта төшү ниятеннән чыгып, анда бер алдынгы уку йорты ачу нияте барлыкка килә. Ә аның өчен башта мәчет салырга кирәк. Шәһәрдә затлы таш мәчет төзетү өчен патша казнасыннан акча бүленеп бирелә. Император Александр Iнең 1802 елгы махсус указы белән мәчетне төзү, аның карамагында мәдрәсә ачу бурычы мөфти Мөхәммәтҗанга йөкләнә. Мөфти бу эшкә авылдашын, булачак икенче мөфти Габдессәламне тарта. Ул аны 1799 елда ук инде шәһәрнең беренче мәхәлләсе имам-хатыйбы һәм Оренбург ахуны итеп билгеләгән була. Шәһәр үзәгендә, Урал елгасыннан ерак булмаган бер калкулыкта тиздән кызыл кирпечтән матур итеп төзелгән мәчет бинасы пәйда була. 1905 елда аның карамагында махсус мәдрәсә ачыла. Хәзергечә итеп әйтсәк, ул ябык типтагы уку йорты була. Аңа күрше дәүләтләрнең хан-солтан балалары гына укырга алына... Шул ук гасыр ахырында анда күренекле әдибебез Галимҗан Ибраһимов белем үзләштерәчәк. Хатыны Гөлсем Мөхәммәдева сөйләгәнчә, «Коръән Алладанмы, түгелме?» дигән язмасына этәргеч биргән нindидер бер кульязма да аның кулына шулвакытта килеп керә».

Алмаш (Меновой) ярминкәсе (Җаек суының аргы ягында – Азия халыклары белән сәүдә итү урыны) ***мәчете.*** Мелла Сөләйман сүзләренә караганда, бу мәчет Оренбург төзелгәндә, мәликә Катерина (чынлыкта Оренбург шәһәре 1743 елда Елизавета Петровна патшалык иткән вакытта төзелә башлый – А.Т.) вакытында казна ярдәме белән корыла, аңа ике имам, ике мәзин, бер хезмәтче билгеләнеп, барысына елына 105 сум акча бирелә.

Кәрван-сарай мәчете. Оренбургтагы өченче мәчет Кәрван-сарай мәчете дип йөртелә. 1229 (1843) елда башкортлардан акча җыеп төзелә, 1262 (1845) елда ачыла. Бинасы – гүзәл, төгәл. Янында Бохара, Сәмәркандмәдрәсәләре үрнәгендә ике катлы бүлмәләрдән торган

Кәрван-сарай мәчете. 1913 ел

«Кәрван-сарай» исемле бер бинасы бар. Мәчет эченең әйләнәсендә алтын белән «Җомга» сүрәсе язылган. Әүвәл мич һәм морҗасы булмый, соңрак төзелә.

Оренбург шәһәрендә кыргыз (казакъ) дарелмөгалимине (ирләрдән мөгаллимнәр әзерли торган уку йорты, семинария) эшләгән (Фатих Кәрими, 1904).

Патша хакимияте чорында Оренбург губернасында 595 мәчет, 152 мәдрәсә, 222 мәктәп исәпләнгән. Бүген исә өлкәдә 78 мәчет һәм 2 мәдрәсә эшләп килә икән (Фәүзия Бәйрәмова материаллары буенча). Оренбург өлкәсендә рәсми рәвештә ике мөфтият теркәлгән. *«Беренчесе – Оренбургның үзендә, аңа Габделбарый хәзрәт Хәйруллин җитәкчелек итә. Икенчесе – Богырыслан мөфтияте, аның рәисе – Исмәгыйль хәзрәт Шәнгәрәев. Өлкәдәге мәчет-мәдрәсәләр дә урталай бүленгән, Оренбург тирәләрендәгеләре – Габделбарый хәзрәт мөфтиятенә карый, Богырыслан, Әсәкәй тирәсендәгеләр – Исмәгыйль хәзрәт мөфтиятенә буйсына»,* – дип яза Фәүзия Бәйрәмова. Кәрван-сарай мәчетендә дини вәгазьләр башкорт телендә алып барыла икән, мәчетнең «маңгаена» да «Каруан-һарай» дип язып куелган. Ләкин Кәрван-сарайның «Гостиный двор» («Сәүдәгәрләр курасы») дип йөртелгән башка биналарын башкортка да, татарга да кайтарып бирмәгәннәр. ■

МОГҖИЗАИ АНА ТЕЛЕМ!

Әбрар Кәримуллин
(1925-2000)

Милли телнең нигезе — ана теле. Моны бик яхшы аңлаган шовинистлар баланы милли телдән аеру өчен ананы алдарга кирәк икәнен бик тиз төшенделәр. Татарның үз «зыялылары», хәтта укытучылары бу эшне бик тиз конвейерга куйдылар һәм зур уңышларга да ирештеләр.

Безнең кайбер галимнәр, революциягә кадәр татар халкы надан, иң артка калган халык булган, ирләре хатын-кызны кол итеп тоткан, дип, трактатлар яздылар, матбугат битләрендә татарның үткәнен өзлексез пычракка буяп күрсәтеп килделәр. Сәхнәләрдә халкыбызның гореф-гадәтләрен мәсхәрәләп күрсәттеләр, урыска кияүгә чыгу мәдәни юл, дип, шигырьләр яздылар, җырлар җырладылар, миен агуладылар…

Үзенең бабасы, атасы, милләтенең егетләре әнә шундый кыргый, надан кавем булгач, теле дә ярлы дип каһәрләнеп килгәч, совет мәктәбендә ялган тәрбия алган «нечкә» күңелле татар кызына бәхетле булу өчен бер генә юл кала: урыска кияүгә чыгу, туган теленнән баш тарту, балаларга урыс теленә табынып тәрбия бирү…

Халык массасын тоталь рәвештә алдау җиңелрәк булсын өчен, аның зыялыларын, галимнәрен, милләтче, «халык дошманы» дип атап, сөргеннәргә сөрергә, зинданнарга ябарга кирәк иде. Һәм шунда меңләгән дин әһелләре дә юкка чыгарылды.

Татар милләтен юкка чыгаруның башка алымнары да күп. Патша заманында динен, милләтен саткан кешегә хөкүмәт зур бүләкләр биргән, баласын солдатка алмаган, салымнардан азат иткән. Әгәр ул кеше үтергән булса, христианлыкка чыгу белән, аның барлык гөнаһларын кичергәннәр.

Коммунистлар хакимияткә килгәч исә мулла малае булу, дингә ышану, аның йолаларын тоту, халыкның тарихын яклау зур «гөнаһлар»дан санала башлады. Моны сизеп алган татар зыялылары, үзләренең «гөнаһлар»ын җую өчен, икенче төрле чукыну юлына — марҗага өйләнү юлына кереп киттеләр. Вакытында миңа татар фольклоры буенча зур хезмәтләр калдырган галимебез Хәмит Ярми үзенең мәзин улы булуына, «Идегәй» текстларын барлау, басарга әзерләвенә карамастан, ничек кулга алынмый, эштән куылмый калуының сәбәбен аңлаткан иде. «Хатыным марҗа иде, ә марҗага өйләнгән кешеләргә милләтче, «халык дошманы» исеме такмыйлар иде», — диде ул.

Әйе, марҗага өйләнү, милләтеңнән качу, балаларыңа урыс исеме бирү Совет хакимияте чорында карьерага ишекне киң итеп ача иде. Әле дә шулай. Без кырыклап татар генералы, адмираллар барлыгын беләбез, ә аларның абсолют күпчелегенең хатыннары марҗа. Болар барысы да милләт белән сату итеп түрә булу үрнәкләре… Инде марҗага өйләнмәгән икән, «чукыну»ның башка юллары да бар. Түрә булу өчен үз телеңне «оныту», урысча гына нотык сөйләү, балаларыңны урыс мәктәбенә бирү шарт.

1928 елда татар имласын латин графикасына күчерделәр. Моңа каршы чыккан татар зыялыларының бер өлешен стенага терәп аттылар, икенчеләрен

үгетләп, куркытып, моңа риза булырга мәҗбүр иттеләр. Аннары, ун ел үтү белән, инде киңәшләшеп тә тормыйча, Мәскәүдән килгән боерык нигезендә, урыс графикасына күчерделәр. Бу юлы инде моңа каршы сүз әйтүче булмады, татар теле белгечләре дә, әдипләре дә үткән «сабак»ны бик яхшы төшенгәннәр иде...

Меңләгән еллык язма тарихы булган Кытай дәүләте дә киләчәктә латин графикасына күчүгә әзерлек алып бара.

Кириллицага күчерелгән графика татар теленең фонетик системасына туры килми торган имла иде. Аның төп максаты — татар телен бозу, аңа нәфрәт тәрбияләү, татар «графикасы» исеме астында сүзләрне урыс фонетикасында бозып әйттерү, нигездә, татар телен аксак графика аркылы урыслаштыру иде. Менә шуннан урыс мәктәбендә укыган татар баласы татар телен белсә дә, татар язуын укый алмый торган булып чыкты, ә күп кенә татар кешеләре бу урыслаштырган графикадан баш тартты, туган телдә уку авырайгач, урысча гына укый-яза башладылар.

Камил графика булдыру — телебезнең үсеше өчен мөмкинлекләр тудыру, аның абруен үстерү, аңа мәхәббәт уяту, аның кулланышы, яшәеше өчен тиешле мөмкинлекләр ачу, дигән сүз. Графикабызның билгеләрен фонемалар системасына туры китереп торгызу, язуыбызны йөгерек, җиңел укуга, хатасыз җиңел язуга юл ачачак бит! Ә бу — һәр телнең үсеше, кулланышы өчен иң хәлиткеч нәрсә.

Аннан шуны да истә тотарга кирәк: латин графикасы дөньяда иң киң таралган, шул ук вакытта иң камилләрдән санала. Меңләгән еллык язма тарихы булган Кытай дәүләте дә киләчәктә латин графикасына күчүгә әзерлек алып бара. Хәзерге заман компьютер техникасы һәм башка төр прибор, машиналар теле инглиз, латин графикасына корылган бит. Әгәр цивилизация юлыннан читтә, кыргыйлыкта калырга теләмәсә, нинди генә консерватор булмасын, урыс графикасы да озакламый шул латин графикасына күчәчәк. Егерменче елларда урыс галимнәре бу мәсьәләне инде күтәреп тә чыкканнар иде, тик шовинизм, бөек милләтчелек идеясе генә аларны тотып калды.

Тарихтан билгеле булганча, теге яки бу җирләрне басып алу, анда яшәгән халыкның байлыгын талау, хокукларын, телен кысу белән генә чикләнми, басып алынган халыкның урман һәм сулары, шәһәр һәм авыллары топонимиясен үзгәртү, урыслаштыру юлы белән дә алып барыла. Әнә шуңа күрә патша хөкүмәте заманында урыслаштырылган топонимияләр өстенә Совет хакимияте елларында татарның бөтен авыл, шәһәр, елга, урман, урам, күл исемнәре урыслаштырылып бетте. Кайберләре бөтенләй юкка чыгарылды, икенчеләре урыс теле законнары буенча үзгәртелде (Җүкә тау — Жукотина, Имәнкискә — Именьково һ.б.).

Этимологиясе онытылмаган топонимнар ике телдә йөри башлады. Биектау — Высокогорский, Чүпрәле — Дрожжановский һ.б.

Милли тел, милли язмыш милли мәктәпкә барып тоташа. Бу өлкәдә башкарган эшләр тубыктан, ә аның «уңышлары» турында язганнар Һималай тауларыннан ашмалы... Бүгенге көндә ничә милли мәктәп барын, анда ничә баланың туган телдә белем алуын күрсәткән мәгълүматларны минем очратканым юк.

Миңа калса, Татарстаннан тыш, татарларның туксан тугыз проценты туган телендә укымый. Татар кызларының кырык ике проценты урыска кияүгә чыкканда, татар егетләренең кырык проценты марҗага

өйләнгәндә, татар балаларының йөздән өчесе генә туган телдә укыганда, милләтнең бетүгә юл тотуы бик ачык күренә ләбаса. Моны яшереп торуның файдасы юк, халыкны алдап, бездә мәктәп, милли телдә укыту үсә, дип, берне йөз итеп күрсәтү — бу фаҗигагә гимн уку гына булып тора түгелме?

Изелгән халыклар өчен үлемне аңлата торган бер куркыныч нәрсә бар, ул геноцид дип атала. Геноцид дигән «спид»ның төп өч формасы бар. Аның берсе — физик геноцид яки халыкны физик юл белән юкка чыгару, үтерү методлары. Әгәр заманында татар белән урыс халкы сан ягыннан тигез булса, хәзер урысның саны татардан утыз мәртәбә артык, ә татар нибары җиде миллион, әле аның да ике миллионы, бәлки инде биш миллионы үз телен белми торгандыр. Тукай заманында татар халкы саны ун миллионга якын булса, «халыклар дуслыгы чәчәк аткан» Совет хакимияте елларында ул тагын өч миллионга кимеде. Чиләбе ягындагы татар авылларын тычкан кебек эксперимент ясап радиация астында тотулар — болар барысы да шул физик геноцид үрнәкләре...

Геноцидның икенче формасы — биологик геноцид, башка төрле әйткәндә, халыкны турыдан-туры үтереп бетерү түгел, ә аны икътисади авыр шартларга куеп, ач-ялангач тоту, биологик яктан юк итү. Татарстанның 20 процентын су белән бастыру, Татарстанда җирдән, бүтән өлкә һәм күрше республикалар белән чагыштырганда, өч-дүрт мәртәбә күбрәк салым алу, халыкны хәерчелеккә калдыру — биологик геноцидның ярылып ята торган чаралары. Ачлыктан, ялангачлыктан үлмәс өчен, татар кешесе иң авыр хезмәт булган Донбасс, Кузбасс, илнең бүтән шахталарына китәргә мәҗбүр була, шулай ук иң авыр эшләрдән — урман кисүгә яллана. Юл төзү, таш вату, җир казу аның «яраткан» эшенә әверелде. Ул яшьтән физик яктан туза,

Милли тел, милли язмыш милли мәктәпкә барып тоташа. Бу өлкәдә башкарган эшләр тубыктан, ә аның «уңышлары» турында язганнар Һималай тауларыннан ашмалы...

гомерен кыскарта, ә шул ук вакытта милләтеннән аерыла, балалары милли телдән, милли моңнан аерылып үсә, урыслаша. Эчәргә, урларга, таларга өйрәнә.

Геноцидның өченче формасы — инде күреп үтелгән мәдәни геноцид: халыкның милли аңын буу, телен кысу, мәктәбен бетерү, матбугатын кисү, көчләп «бөек» халык мәдәниятендә тәрбияләү, югары уку йортларының ишекләрен ябу...

Милли тел язмышы — ул милләт язмышы, аның яшәеш, үсеш формасы, милләтнең сакчысы да, аның киләчәгенең гарантиясе дә. Кешелек әле милләтнең таянычы булган, йөрәк парәседәй нечкә, кадерле башка төр могҗизаны уйлап тапмаган, таба да алмас, бу бөек көчне бернәрсә дә алыштыра алмый. Чыгышы белән татар булса да, үз телен белмәгән, шул ук вакытта үз халкын яраткан, аны сөйгән кеше дә милләтнең сакчысы, аның үсешенә өлеш кертә алган зат була алмый. Ярату — әле ул мәхәббәт дигән нәрсә түгел. Ярату, сөю сүнә, ә мәхәббәт — мәңгелек.

И туган телем, мөкатдәс моңым, яшәешемнең бөек мәгънәсе булган могҗизам! Бары син яшәсәң генә татар милләте яшәр, тормышыбызның мәгънәсе булыр, дөнья, галәм гүзәлрәк күренер, инсаният, тормышның да ямегаме артыр, иншаллаһ!

1994 ел
Татарстан радиосының «Тел күрке — сүз» тапшыруына нигезләп, басмага ***Рөстәм Акъегет*** *әзерләде.* ■

БӨЕК ОСТАЗГА ИҢ ЯКЫН РӘССАМ

Расиха Фәизова

Урта гасырларның әдәби прозасы турында сүз чыкканда, 30 елдан артык гомерен шул чорга караган мәдәни җәүһәрләрне тикшерү-өйрәнүгә, шуларны кабат халыкка кайтаруга багышлаган Нәҗип Фәйзрахман улы Исмәгыйлевнең исемен хаклы рәвештә зур хөрмәт белән атыйбыз.

ҺӘР ЯҢА КУЛЪЯЗМА — АЧЫШ

Татарстан Фәннәр Академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кулъязмалар һәм текстология бүлегендә гыйльми хезмәткәр булып эшләү дәверендә (1979-2011) борынгы мирасны бүгенге әдәби телгә күчереп 4 китап, 30дан артык гыйльми мәкалә бастырып чыгарган галим ул. Бу эшкә студент елларында ук кереп китеп, фарсы, гарәп, төрек катыш «Мәҗмугыл хикәятләр»не хәзерге әдәби телгә тәрҗемә итә. Хикәятнең катлаулы чагыштырулары да, урыны белән җырлап торган рифмалы стиле дә куркытмый егетне. Бераз соңрак, 1994 елда, 15 мең тираж (!) белән басылып та чыга әлеге хезмәт. Ә инде институтта эшләгәндә ул басмага әзерләгән хезмәтләрнең иң күп тираж белән басылганы (25 мең) «Саваплы гамәлләр» була. Моңа кадәр күрелмәгән рекордлы тираж белән басылуына карамастан, тиз арада таралып та бетә ул. Алай гына да түгел, соңрак җиңел кәсеп белән тиз генә баерга ниятләгән берәве хәтта 50 мең тираж белән урлап та бастыра әле аны. Ул вакыттагы гаделсезлекне күреп галимнең

җаны рәнҗесә дә, хәзер инде моңа аның үз фәлсәфәсе: аңа — файдасы, миңа — савабы.

Һәр яңа кулъязманы ачышка тиңләгән Нәҗип әфәнденең әле бүген дә эш өстәленең бушап торганы юк. Чөнки беләә: нәрсәгә генә тотынма, аларның

Г.Тукай: «Җөмлә фикерем кичә-көндез сезгә гаид милләтем».
Дизайн кәгазе, тушь, гуашь. 80х58 см



Шәмаил: «Айлы Сөембикә»

Шәмаил: «Татармын!»

Шәмаил: «Кече яшьтән алган гыйлем ташка уйган бизәк кебек». Хәдис

***

«Нәҗибулла хәзрәтләре, җанкисәк! Бик мәхәббәтле күргәзмәң. Оештыру һәм матбугат җыюда остазыңны, Урманче хәзрәтләрен узасың. Балаларың, шәкертләрең үз юлыңнан китеп, татар гыйлем-сәнгатен бик зур югарылыкка күтәрәчәксез, иншаалла!»

Флора Урманче.

***

«Гарәп телен белмәсәм дә, әсәрләрегездән гасырлардан килә торган моңлы саз ишетелгән кебек тоела».

Рәссам ***Шамил Нигъмәт.***

***

«Бүген мин гаҗәеп серле күргәзмәдә булдым. Күмелергә, онытылырга хөкем ителгән сәнгатебезнең бу төре, Ходай рәхмәте белән, яңадан үзебезгә кайта башлады. Афәрин Нәҗип әфәндегә».

Туфан Миңнуллин.

һәркайсында хикмәт бар, телисеңме син аны, юкмы, ул ахыр чиктә, нинди дә булса чыганакларга барып тоташа. Менә шушы Фирдәүси, Низамилардан башлангыч алган җеп очын табу да үзенә бер рухи ләззәт бирә аңа. Шуның өстенә борынгы көнчыгыш әдәбияты әсәрләрен тәрҗемә итеп, укып, барлап барган мәдәниятле халкы өчен горурлык хисләре гел яңарып тора күңелендә.

— Нигездә мин кульязма хәлендәге хикәят, кыйсса, ләтыйфа, нәсыйхәт, гыйбрәт жанрындагы чәчмә әсәрләр белән эш иттем. Әйтик, «Фазаилешшөһүр» 1854 елда Мамадыш өязендә яшәүче галим тарафыннан язылган була. Кайчандыр мәдрәсәләрдә татар телен шушы сирәк чыганакларның берсе булган, китап аша өйрәнгәннәр. Ә менә «Кәлилә вә Димнә»не сигезенче гасырда гарәп язучысы Ибн әл Мөкаффаг тарафыннан язылган. XIX гасырның икенче яртысында әлеге әсәрне мәшһүр татар мәгърифәтчесе Габделгалләм Фәйзханов тәрҗемә иткән булса, 120 елдан соң бу эшкә мин кабат алынып, аны бүгенге телебезгә яраклаштырдым, — ди Нәҗип әфәнде.

Инде килеп, текстолог-галим тарафыннан әзерләнгән китапның бишенчесенә керәсе хикәятләр[1] белән «Безнең мирас» җурналы укучылары беренчеләрдән булып таныша икән, бу бик табигый. Беренчедән, әлеге хикәятләр чыннан да әдәби мирас җәүһәрләре буларак җурнал өчен кадерле һәм әйтергә кирәк, Нәҗип әфәнде элеккеге «Мирас» журналы редакциясе белән дә озак еллар, тыгыз элемтәдә яшәгәнлектән, аның гыйльми мәкаләләре укучыларга электән үк таныш. Икенчедән, хаттатның шәмаилләре, каллиграфик композицияләре, тугралары, җәмгысе 25ләп әсәре 1996 елга кадәр журнал тышлыкларын бизәп, аның йөзен билгеләде.

ЯЗУ ЧИСТАЛЫГЫ – КҮҢЕЛ ЧИСТАЛЫГЫННАН

Хаттат Нәҗип Нәккашның үзенчәлеге шунда ки, ул татарның совет дәверендә онытылырылган борынгы сәнгать мирасы булган гарәби каллиграфияне 90 нчы еллар башында кабат тергезеп, яңартып җибәрүче булды. Гарәби каллиграфия, тугра, ләүхәне сәнгать югарылыгына күтәреп, шул ук вакытта әлеге юнәлештә үз мәктәбен булдырган рәссам ул. Иллә мәгәр, нәрсә генә эшләсә дә, аның галимлеге хаттатлыгына, хаттатлыгы галимлегенә берегеп бербөтен хасил итүен чамалавы кыен түгел. Үзенең шушы шәмаил, ләүхәләрендә дә рәссам борынгы әдәбият белгече буларак, Коръән аятьләре, пәйгамбәрләрнең хәдисләр белән генә чикләнмичә, татар шагыйрьләренең хикмәтле, гыйбрәтле, фәлсәфи шигырь юлларын киң файдалана. Нәзакәтле милли бизәкләргә «төрелгән» шәмаилләре, тугралары үзләренең форма үзенчәлекләре (кораб, китап һ.б.) белән генә җәлеп итеп калмый, аның асылында тугра иясенә атап әйтелгән үгет-нәсыйхәт, изге теләк, йә булмаса гыйбрәт өчен җиткереләсе хикмәтле сүз ята! Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Йосыф Баласагуни, Кол Галидән башлап алдыбызга, шаһәсәрләрне бер-бер артлы ташка баскандай тезә бара рәссам. Борынгы кульязмаларда халкыбызның гасырлар буе сакланып килгән гакыл байлыгын киң катлауга җиткерү, күрсәтү юнәлешендәге тагын бер бик үзенчәлекле, отышлы юлны табуы була бу аның.

ТУКАЙНЫ ПӘЙГАМБӘРЛӘР БЕЛӘН ЯНӘШӘ

Тукай иҗаты рәссамның шәмаилләрендә аеруча калку бирелә. Әйтик, 1990 елның сентябрендә Сөембикә манарасына ай куюга багышланган эшендә

[1] «Бим шәһәре төзүчесе һәм гүәшир падишаһының вәзире» №12 (2015), «Кирпеч ясаучы Шапур һәм Хуҗа Мозаффар хикәяте» №3 (2015) исемле маҗаралы хикәятләрне журналдан табып укый аласыз.

(«Айлы Сөембикә») Тукайның «Пар ат» шигыреннән юллар укыйбыз:

«Мондадыр безнең бабайлар,
төрләре-почмаклары,
Мондадыр дәртле күңелнең
хурлары-оҗмахлары.
И Казан! Дәртле Казан,
моңлы Казан, нурлы Казан!

«Гыйлемгә омтылыгыз!» дип аталган эшендә дә Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисе («Бишектән башлап ләхеткә кергәнче белем алырга, гыйлем эстәргә онытмагыз!») белән Тукай шигырьләреннән өзекләр бер-берен тулыландырып янәшә бара:

Өч наданга алмашынмас
бер язу белгән кеше.
Мәгърифәт эстәр,
иренмәс һич Кеше булган кеше.

Шул рәвешле рәссам Тукайны пәйгамбәрләр белән янәшә куеп кына калмый, ә алар дәрәҗәсенә күтәрә дә!

Бары тик Тукайның «Туган тел» еннән генә торган шәмаил да бар. «Татармын» шигыренә исә рәссам кайта-кайта мөрәҗәгать итә һәм бер-беренә охшамаган бик кызыклы эшләр килеп чыга. «Кадер кич» шигыренә дә аерым туктала рәссам. Тукай әсәрләренә мөрәҗәгать итеп, җәмгысе 30га якын каллиграфик эш башкара хаттат. Бу үзе үк бер зур тематик күргәзмә дигән сүз. Юкка гына рәссамның беренче эшләре 1993 елда Тукай музеенда узган күргәзмәгә куелмый инде. Хаттатның үзенчә Тукайдан фатиха алуы да булгандыр ул. Кол Шәриф мәчетенең Ислам музеенда узган «Коръән Кәрим һәм Тукайдан илһам алып» (2008) дип аталган тематик күргәзмәне, иманым камил, әле дә хәтерләүчеләр бардыр.

ГАШЫЙКЛАР СӘГАТЕ ШУШЫНДА СУГА

Бауман урамына милли төсмер биреп торуы, Тукай шигырьләренә иллюстрация рәвешендә ясалган сәгатьне (рәссам Игорь Башмаков эше) кем генә белми икән. Сан урынына гарәби хәрефләр белән язылган мондый сәгать, кем белә, Казанда гына түгел, ә бәлки әле дөньяда берданбердер?! Инде ничә еллар Казанда гашыйклар очрашу сәгатен вә минутын шуның буенча исәпли. Өч якка карап торган таблоларда Тукайның өч шигыреннән юллар да китерелә. Әлеге скульптур композициянең каллиграфиягә кагылышлы өлеше шулай ук Нәҗип Нәккаш эскизлары буенча башкарылган.

Шагыйрьләр иҗатына мөрәҗәгать итү — нигездә, кырыйларына мәчет манаралары куелып, аятьләргә, хәдисләргә генә нигезләнеп башкарылган элеккеге стильдәге эшләрдән аерылып торучы үзенчәлеге, табышы бу рәссамның.

Революциягә кадәр шәмаилләрдә татарча язулар очраштырса да, ул киң яңгыраш тапмый. Асылда гарәпчә, фарсычага өстенлек бирелә. Шәмаилне шактый ук татарчалаштыруда да (гәрчә гарәп шрифты белән булса да) шактый юл ярган, үзенчә эшләгән кеше Нәҗип Нәккаш. Бу җәһәттән Дәрдемәнд иҗатын нигез итеп алып, гел татарча башкарылган эшләрне дә мисалга китерергә мөмкин. График яктан чиста, төгәл, стильне артык «куертмыйча» гына эшли ул аларны. «Нәсех», «сүлес», «куфи», «тәгълыйк», «дивани», «шикәстә» кебек классик язу стильләренең бөтен мөмкинлекләрен белгән хәлдә, Нәҗип Нәккаш шәхсән үзе әз генә урынга күп итеп текст сыйдыру мөмкинлеге бирүче, өч тигезлектә языла торган сүлесне ошата төшә. Гадәти текстларны язганда исә Коръән аша бөтен кешегә дә яхшы таныш булган нәсехкә туктала. Язу чисталыгы — күңел чисталыгыннан, дибез икән, бу төшенчә Нәҗип әфәндегә бик рас килә.

КҮҢЕЛ БИЗӘКЛӘРЕ

Шәмаилләр белән беррәттән тугра жанрының популярлашуын да Нәҗип Нәккаш иҗаты аша таныйбыз. Аның кулы белән башкарылган шәхси тугралар, гаилә герблары меңнәрчә татар өйләренең түрендә үзенең лаеклы урынын тапты.

Шәмаил: «Игелек кылыгыз!» Пыяла, катнаш техника, 64х64 см

— Тугра — гади кешене шәхес итеп күрсәтүче, хөрмәтләүче, югары күтәрүче гарәби тамга; гаиләне берләштереп торучы көчле бер символ. Аның гарәби хәрефләр белән башкарылуы — мең еллар буе кулланылган мөкаддәс вә кадерле мирасыбыз барын искә төшереп тора, — ди бу хакта рәссам үзе.

Анкарада Ататөрек исемендәге төрек мәдәният мәркәзендә узган Халыкара кул сәнгатьләре күргәзмәсе ярминкәсенә килүчеләрне дә (2006 ел) аның тугралары таң калдыра.

Бизәүгә килгәндә, рәссамның чәчәк орнаментлары рәвешендәге катлаулы кысаларга урнаштырылган затлы эшләрен әллә каян танырга була.

***

«Чагыштырыр өчен (мактаныр өчен дип уйлый күрмәгез, зинһар) әйтәм: мин гомер буе музейлар, күргәзмәләр карап йөрдем. Шаккатып, бирелеп. Европа, Азия һәм башка кыйтгаларның сәнгатьләрен карадым. Аңларга тырыштым. Сезнең шәмаилләрне күргәнче үк сиземли, тоя идем. Хәзер менә күрдем, сокландым һәм аларның матурлыгы мин исән чакта миндә яшәячәк. Татар рәссамнарының барысы да бөек Бакый шәкертләре, аның дәвамчылары. Сез шулар арасында бөек остазга иң якыны».

Миргазиян Юныс. (2001)

Монда да табышларсыз гына булмый. Археологик казу эшләре вакытында табылган чүлмәк ватыкларындагы борынгы бизәкләргә янә җан өрә рәссам. Бер үк вакытта әлеге милли бизәкләргә нигезләнеп, үзе дә ачык, якты төсләрне мул кулланып, оригинал, чын мәгънәсендә «мин татарныкы» дип кычкырып торган эшләр иҗат итә. Бик яратып, хасиятләп башкарылган, челтәр урынына үргән шушы татар бизәгенә төрә рәссам үзенең шәмаил, тугра, ләүхәләрен. Һәм, әйтергә кирәк, чамасын бик белеп кенә «төрә». Шул рәвешле рәссамның гарәби каллиграфия үрнәкләре дә татарча яңгыраш, татарча төсмер белән байый.

КҮРГӘЗМӘ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Нәҗип әфәнде катнашкан, берсе икенчесеннән җаваплырак, мәртәбәлерәк була барган күргәзмәләр саны да инде 66дан артып бара (8е — халыкара күргәзмә, 5се — Россия күләмендә). Шуларның 23е шәхси күргәзмә булуын да искәрсәң, моның артында никадәр хезмәт ятуын чамаларга була. Франциянең Дижон (2006), Төркиянең Анкара (2006) шәһәрләренә дә гарәби каллиграфия тарафдары, хаттат буларак аяк баса ул. Россиядә уза торган халыкара каллиграфия күргәзмәләренең бишесендә дә (Санкт-Петербург (2009), Великий Новгород (2010), Мәскәү (2009, 2012, 2015)) эшләре түрдә була рәссамның. Алай гына да түгел, күргәзмәне оештыручылар гарәп каллиграфиясенә нисбәтле рәвештә теге яки бу мәсьәләдә аның фикере белән санлаша. Рәссамга турыдан-туры киңәш сорап мөрәҗәгать итә. Үзен бик үк диндар кеше санамаса да (моны тыйнаклык күрсәтү дип кабул итсәң, дөресрәктер, юкса студент елларында ук өйләнешкән группадашларына никах укыган, әле хәзер дә оныкларына исем кушучы да ул үзе!), Нәҗип Нәккаш Коръән белән бик белеп, сак эш итә. Мәскәүнең Үзәк җамигъ мәчетенең конференцияләр залында узган күргәзмәдә (2004) дә ул очраклы гына катнашмый. 2001 елда Рамазан аенда Иранның Тәһран шәһәрендә узган халыкара «Коръән» күргәзмәсендә 25 эше белән катнашу бәхете дә нәкъ менә аңа насыйп була. Ә иң кызыгы күргәзмәдән кайтып аяк асты бераз тынгач була. Н.Нәккашның фатир ишеген Голландиядән килгән сәнгать белгече, коллекционер шакый. Баксаң, ул аның Иранда вакытта төрек телевидениесенә биргән интервьюсын һәм шул ук вакытта төшерелгән эшләрен күргән булган икән. Шулай итеп, сәнгать белгече эзләгәнен таба: рәссамның ике эшенә ия була.

КАМИЛЛЕКНЕҢ ЧИГЕ ЮК

Шул ук вакытта аның бер генә күргәзмәсе дә осталык дәресеннән башка узмый, дип әйтә алабыз. Арада студентлар, сәнгать мәктәбе укучылары өчен махсус үткәрелгәннәре дә шактый. Кайчандыр мәшһүр Урманченың үзеннән 4-5 дәрес алу бәхетенә ирешкән Нәҗип Нәккаш осталык серләрен шәкертләре белән бик теләп уртаклаша. Туган авылы Үсәлидә университетка кергәнче үк 7 ел рәсем укыткан, 8 ел Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында, мөфти соравы буенча 6 ел Ислам университетында каллиграфия буенча дәресләр биргән кеше буларак, аның инде монда да үз методикасы бар. Кайчандыр останың үзенә килеп шәхсән сабак алган, киңәш-табышка йөргән Владимир Попов[2], Ришат Сәлахетдинов, Әлфия Хәлиуллина кебек байтак кына рәссамнар бу өлкәдә инде үзләре танылу алды.

Аннан еш кына хаттатның шәһәр күләмендә узган урам бәйрәмнәрендә, кулланма гамәли сәнгать осталары тарафыннан узучы зур-зур чараларда, халык алдында ал-ялны белмичә, экспромт рәвешендә кешеләрнең исемнәрен, тугураларын язып торуын да

[2] Владимир Поповның иҗатына багышланган язманы (Расиха Фәизова. «Феномен») журналыбызның 2014 елгы 7 нче санынннан укый аласыз.

еш күрәбез. Бу очракта вакыты белән исәпләшмәү генә түгел, кул астындагы материалларын да исәпләми ул. Аның тирәсендә һәрвакыт чират була. Мәскәүдә узган күргәзмәгә керергә сузылган чират зур иде, дип сөйләүләре дә юктан гына түгел.

Хаттатның дистә елларга сузылган иҗатының ни дәрәҗәдә зурлыгын күз алдына китерү өчен генә булса да, саннарга мөрәҗәгать итик әле. Кара исәп белән генә караганда да, Нәҗип Нәккаш исәбендә кәгазьдә, катыргыда башкарылган 100дән артык шәмаил, ләүхә, плакатлар; кәгазьдә эшләнгән 1000нән артык тугра (логотип, герб, шәхси тамгалар) бар. Ә декоративлыгы белән әллә каян игътибарны җәлеп итеп торучы пыялада башкарылган шәмаилләрне, тугараларны кая куясың?! Аларының да исәбе 500дән артып киткән ләбаса! Моңа әле мәчет бизәмнәрен, кабер ташларын, шәҗәрәләрне, китап бизәлешләрен дә өстәсәңме?.. Аларның һәркайсы үзе бер тармак булса да, барысына да өлгерә, барысын да колачлый рәссам. Мәчет бизәмнәренә килсәк, әлбәттә Казанның «Печән базары» мәчетендә, «Мәрҗани» мәчетенең яңа төзелгән уң канатындагы михрабта, Борисо-Глебовский бистәсе мәчетендә, «Ярдәм» мәчетендә һ.б. күрергә була аның эскизлары буенча башкарылган бизәлешләрне. Илдар Хановның Галәм әхрамындагы мәчет гөмбәзен дә нәкъ менә Нәҗип Нәккаш эскизлары буенча смальтадан җыелган мозаика бизи. Районнарга чыксаң, Түбән Кама шәһәрендә ике мәчет, Лениногорскидагы җамигъ мәчете, Әлмәт шәһәре, Югары Афанас һәм Шаңгәлче авылы мәчетләренең бизәлешләренә дә аның өлеше кергән. 2 нче татар гимназиясендә даими эшләүче Шәмаил музее концепциясе, бизәлеше шулай ук Нәҗип әфәндегә барып тоташа. Каллиграфия сәнгатенең кулланыш даирәсе моның белән генә чикләнмәсен иде, урамнарда кибет-салон исемнәрендә дә күрәсе иде аны дип, ничә еллардан бирле чаң сугучы да, бер урында гына таптанмыйча, каллиграфия үрнәкләренең кулланыш даирәсен киңәйтүнең авангардында баручы да Нәҗип Нәккаш үзе бит.

Хәзер инде хаттатның шактый гына эшләрен музейларда күреп тә юанабыз (Милли музейда — 6 эш, «Казан» милли мәдәният үзәгендә 5, Казан кирмәненең «Хәзинә» милли сәнгать галереясында — 4, Казанның сынлы сәнгать музеенда — 2, Казадагы Тукай музеенда — 5, К.Насыйри музеенда — 4, Санкт-Петербургның этнография музеенда — 1, Мәскәүнең Заманча каллиграфия музеенда — 4 һ.б.). Хәер, бүген кайда татар яши — Н.Нәккашның эшләре шунда, дип һич икеләнмичә әйтә алабыз. Чөнки дөнья буйлап сибелгән татарыбыз Казанга килүгә, үзе белән менә шушы матурлыкны, үзебезнең борынгыдан килгән сәнгатебезнең бер генә үрнәген булса да алып китәргә тырыша. Шул рәвешле Голландиянең Утрехт, Финляндиянең Хельсинки, АКШның Вашингтон, Сан-Франциско, Австралиянең Аделаида, Төркиянең Анкара, Истанбул, Измир шәһәрләренә китә аның эшләре. Бу бит әле ул үзе белгәннәре генә!

Моннан элек рәссам-хаттатның Тукай музеенда ачылган бер күргәзмәсендә танылган галим Хатип ага Миңнегулов: *«Без бу олы иҗатның мәгънәсен тиешенчә аңлап та, бәяләп тә бетермибез булса кирәк. Нәҗип Нәккашның эшләре кая гына куелмасын, күңелендә татар җаны булган кешенең татарлыгын уята, геннарын кузгата, татар булмаган кешеләрнең дә татарга хөрмәтен, ихтирамын арттыра»*, — дигән иде. Чыннан да, безнең инде рәссамның мондый эшләренә күзебез ияләнде булса кирәк. Чыннан да, шәркый мирасыбызга күпләргә караганда да якынрак торучы хаттатны, Хатип ага әйткәндәй, тиешенчә аңлап, тиешенчә бәһалисе иде бит! ■

«АЛТЫН БИТЛЕК»

(ТР Милли музее фондларыннан)

Музей фонды елдан-ел арта, 2015 елның яңа экспонатлары арасында Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театрының элеккеге баш режиссёры, СССРның халык артисты Марсель Сәлимҗановка 2001 елда бирелгән «Алтын битлек» — Россиянең милли театраль премиясе аерым игътибарга лаек.

Театр сәнгатендәге иң абруйлы премия тәүге мәртәбә 1993 елда Россия Федерациясенең Театр эшлеклеләре берлеге теләктәшлеге белән тапшырыла.

«Алтын битлек» югары тарихи-мәдәни һәм мемориаль әһәмияткә ия. Татарстанда әлегә кадәр ошбу премия иясе Марсель Сәлимҗанов кына иде. Күптән

түгел Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Ринат Таҗетдинов та «Алтын битлек»ле булды.

ТР Милли музее — Россиядә әлеге абруйлы премияне үз фондында саклаучы беренче музей.

Гүзәлия Җәләлева *әзерләде.*
Фоторәсемнәр Г.Камал театры
һәм ТР Милли музей архивларыннан
алынды.

قوياش

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның февраль ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Татарча театр

Үткән җомга көн Өммегөлсем ханым Болгарская бенефисына[1] «Шәфкать туташы»[2] уйналды. Кирәк бенефис сахибәсе вә кирәк бүтән иптәш артистлары яхшы ук берегеп, иттифак берлә уйнадылар. Соңгы пәрдә вә күренешләрдә докторның (Үзбәк Тинчурин) шәфкать туташы булырга димләве һәм Любовьның (Болгарская) иҗабәт-изһарләре[3] вакытларындагы, урамнан сугышка озатыла торган гаскәрләрнең «Ура» тавышлары һәм музыканың бик урынлы төшүләре, һәм моннан соңгы сугыш хәлләре гаять муаффәкыятьле [уңышлы] тасвир ителде.

Миһманнарның [кунакларның] күплеге уртача иде. Бенефис сахибәсенә алтын чылбыр, алтын сәгать, кыйммәтле кашлы алтын алка вә башка бүләкләр тәкъдим ителде.

Әҗем мәчете вә мәдрәсәсе хисабы

Әҗемовлар бина кылган мәсҗед вә мәдрәсәи «Гаффария»нең 1914 ел 1 ноябреннән башлап 1915 елның 1 ноябренә кадәр булган еллык хисабы идарәбезгә тапшырылды. Бу хисапка караганда, мөдириятнең бөтен варидәте [кереме] 5732 сум 70 тиен булган ки, моның эченнән 900 сумы ярдәм буларак шәһәр управасыннан алынган. Ел эчендә бөтен тоткан мәсъраф [чыгым] 5244 сум 52 тиен булган.

Һәр җирдәге мәктәп-мәдрәсәләребездә була торган хәлләр монда да ингыйкяс иткән [чагылган]. Хисапның мәсъраф ягына күз салынса, мондый мәсъраф урыннары күзгә бәрелә: мәдрәсә сторожына жалуния — 14 сум; 4 мөгаллимгә сентябрь ахырында укытканга — 20; дамеллага бер айлык вазыйфа — 20; дүрт мөгаллимгә вазыйфа — 83; сторож Мөхәммәдшага жалуния — 14.

Менә болар һәр ай саен шул нисбәттә тезелешеп киткәннәр. Мөгаллим вә дамелла сторождан 6 гына сум кыйммәтрәк йөргән һәм моның өстенә бу вазыйфалар елның һәр аенда бирелмәгән. Шуның белән бергә мөгаллимнәргә вазыйфа бирелү сторожныкыннан соң башланган һәм элек тукталган. Бу хәл, тәэссефкә [кызганычка] каршы, бу мәдрәсә вә мәктәпкә генә махсус хәл түгел. Безнең һәммә мәдрәсәләребезнең хәле шулай яки шуңар якын.

Кояш. — 1916. — №908. — 1 фев.

«Бәхетсез егет»

Җомга көн «Бәхетсез егет» драмасы «Сәйяр» труппа артистлары тарафыннан уйналды. Саф үз тормышыбыздан алынган бу әсәр уйналышы

---

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] 1916 елда Өммегөлсем Болгарскаяга (1891-1968) 25 яшь тулган.

[2] «Шәфкать туташы» — М.А.Кирьякованың 4 пәрдәлек драмасыннан («Сестра милосердия») И.Кулиев тәрҗемәсе.

[3] Иҗабәт-изһарләре — уңай җавап бирү, мәйданга чыгу

белән дә муаффәкыятьле чыкты. Казан бае Кәримнең Уфага углын эзләргә барып, анда дин башлыгы булганлыгы җәһәтеннән, гаять гали мәнфәгатьле булыр, диеп фараз итеп йөргәне, мөфтине күреп кайткач, аның чапан вә чалмасы өстенә ятмавын яратмый көлеп хикәят кылганы тамашачыларга җан кертте. Бу мәсьәлә әсәр язылган чакта зур әһәмияткә малик булмаган төсле күренсә дә, хәзерге көндә нәүбәттә торган мәсьәләләрдән итеп тәлкыйн кылынганлыгы [аңлатылганы] беленде. Уйнаучылардан Кәрим (Кариев), Гайни (Болгарская), Закир (Үзбәк Тинчурин), Мәгъри (Болгарская) гаять муаффәкыятьле уйнады. Бу юлы Җәмилә (Таждарова) яхшы ук чибәр уйнады. Моннан калганнары да иттифак белән уенның камил чыгуына зур хезмәт күрсәттеләр, миһманнар уеннан мәмнүн булып калдылар.

Кояш. — 1916. — №912. — 7фев.

Сөембикә рәсеме

«Аң» журналы идарәсе тарафыннан еллык мөштәриләренә [абүнәчеләренә] һәдия [бүләк] итеп бирер өчен бастырылган «Сөембикә һәм угылы» рәсеме полиция мәэмүрияте тарафыннан җыелып алынган иде. Инде хәзер бу рәсемне нәшер итәргә мөсәгадә [рөхсәт] кылынган.

Кояш. — 1916. — №917. — 16 фев.

Габдулла Камал[4]

«Сәйяр» труппаның маһир артистларыннан Габдулла Камал сугыш мәйданында җәрәхәтләнеп кайтып, озын мөддәт [вакыт] хәстәханәдә тәрбияләнгән иде. Инде хәзер гаскәри хезмәткә сәляхияте [сәләте] беткән диеп танылып, хезмәттән тәмам азат ителгән вә үзенә елга 160 сум пенсия тәгаен кылынган. Габдулла Камал моннан соң «Сәйяр» труппа белән бергә сәхнәгә хезмәтен дәвам иттерәчәктер. (Якын көннәрдә уйналачак «Ревизор»да да иштиракъ итәчәктер [катнашачак].)

Үләксә ите саткан өчен

Евангелистовский урамда ит белән сату итүче Сәйфетдинов кибетеннән яртысы сатылган келәймәсез ит табылган. Тәфтиш соңында бу итне үләксә ите дип һәм чери башлаган дип тапканнар. Шәмсетдинов судка тартыладыр.

Кояш. — 1916. — №924. — 28 фев.

Әхлак бозуга каршы

Аеклык җәмгыяте рәисе, шәһәр управасына гариза биреп, соңгы вакытларда шәһәрдә бик күп кинематограф ачылганлыгын, бу кинематографларда әхлак боза торган картиналар күрсәтелгәнлеген, җөмләдән, үз күзе алдында «Большой» театрда «Өйләнү» дигән яшь буыннарга түгел, хәтта зурларга да әхлакый начар тәэсир бирерлек картина күргәзелгәнлекне бәян кыла да, шәһәр халкын әхлак бозыклыгыннан саклау юлында шушы кинематографларда күрсәтелә торган картиналарны ачыклауны, яман картина күрсәтелергә юл куймауны үтенәдер. Управа бу үтенечне гадлия [юстиция] комиссиясенә, гомуми тамаша урыннарын тәфтиш кылуга шәһәрнең хакы бармы икәнен хәл итәргә биргән.

Кояш. — 1916. — №923. — 26 фев.

[4] Габдулла Камал, ягъни Камал I (1893-1933) — режиссер, артист. Г.Камалның бертуган энесе.

Президентның күңеле күтәренке. Ул җиңүче булды.

БАШКАЛА, СПОРТ ҺӘМ ҖИТӘКЧЕЛӘР

Әгъзам Фәйзрахманов

Соңгы вакытларда спорт һәм Татарстан сүзләре еш кына янәшә кулланыла башлады. Чыннан да, бездәге спорт инфраструктурасы илдә иң яхшылардан санала. Боз сарайлары, бассейннар эре шәһәрләрдә генә түгел, районнарда да ачыла. Татарстанда 40тан артык боз сарае һәм физкультура-сәламәтләндерү комплекслары эшли.

Күп кенә матбугат чараларында республика журналистлары Татарстанны Россиянең спорт башкаласы дип тә бәяли башлады. Шәхсән үзем мондый бәяләмә белән һич кенә дә килешә алмыйм. Башкала ул — административ үзәк. Илнең төп спорт оешмалары да Татарстанда урнашмаган. Илнең тулаем спорты белән дә Татарстан идарә итми. Владимир Дальнең 1882 елда чыккан аңлатмалы сүзлегендә башкала төшенчәсе менә ничек аңлатыла: *«Столица — престольный город, главный, первый в государстве, где пребывает высшее правительство, государь»* (4 том, 328 нче бит).

«Башкала» төшенчәсе белән мавыгу республика матбугатында моңарчы да булгалады. Хәтерлисездер, үткән гасырның 90 нчы еллары урталарында республика районнары икмәк үстерү буенча ярышырга тотынды. Кайберләре хәтта чик-чаманы онытып, гектардан 70-75 центнер уңыш җыеп алдык, дип рапорт бирде. Арчалылар район буенча гектардан 75 центнердан артык уңыш алдык, дип кычкырды. Татарстан шартларында мондый уңышка ирешеп булмавын һәркем аңлый югыйсә. Саламын, камылын да кушып, бераз балчык та өстәсәң генә инде. Арчага еш кайтып йөрүче, хакимият башлыгы Вәгыйз Минһаҗев белән дуслык урнаштырган

бер журналист та, күрәсең, бу саннарның мәгънәсен аңлап бетермичә, республика газеталарында «Арча — республиканың икмәк башкаласы» дигән рубрика белән мәкаләләрен яудырырга тотынды. Арчалылар да бурычлы булып калмады: «Уңыш бәйрәме»ндә аны сәхнәгә чакырып, тун һәм затлы бүрек бүләк итте.

Бервакыт мин бу журналист белән очрашкач, аңа әйтеп куйдым: «Балтачлар сөтне мул сава. Балтач — республиканың сөт башкаласы, дип яза аласың. Ә менә Чүпрәледә дуңгызчылык мәсьәләсе әйбәт куелган. Чүпрәлене «дуңгыз башкаласы» дип атый аласың». Күрәсең, ул юморны аңламады: «Уйларга кирәк», — диде.

Әлмәт шәһәре турында сүз барганда кайберәүләр аның турында «республиканың нефть башкаласы» дигән төшенчәне куллангалый. Мин бу гамәл мантыйкка сыя, дип саныйм. Чөнки бу тармак белән идарә

Урра! Җиңдек!

Милләттәшебез Гата Камский партияләре һәрвакыт киеренке үтә

итүче «Татнефть» берләшмәсе анда урнашкан.

Студентларның бөтендөнья җәйге уеннары — Универсиада Татарстанны Россиянең алга киткән спорт төбәге булуын раслады, аны дөньяга танытты. Ярышларда 162 илдән 11759 спортчы көч сынашты, 27 спорт төре буенча 351 комплект медаль уйнатылды. Болар — Универсиада тарихында рекордлы саннар. Дөньякүләм ярышларга Универсиада авылы, «Казан» халыкара аэропортында яңа терминал, Казан метрополитенының икенче чираты, 11 юл чишелеше, 41 җәяүле кичүе, бихисап спорт корылмалары төзелде.

Спортның су төрләре буенча Казанда үткәрелгән дөнья чемпионатында 190 илдән 2500 спортчы катнашты. Моңарчы су чемпионаты безнең илдә бер тапкыр да үткәрелмәгән булган. Халыкара йөзү федерациясе президенты Хулио Маглионе Казандагы чемпионатны тарихта иң яхшысы дип атады.

2018 елда Россиядә футбол буенча узачак дөнья чемпионатының кайбер уеннары да Казанда узачак. Моның өчен стадион да, кунакханәләр дә әзер инде.

Татарстанның «Рубин» (футбол), «Зенит-Казан» (волейбол, ир-егетләр), «Динамо-Казан» (волейбол, хатын-кызлар), «Ак барс» (хоккей), «УНИКС» (баскетбол) командалары Россия чемпионатында һәм халыкара ярышларда уңышлы чыгышлар ясый, республиканы таныту буенча шактый роль уйный. Әмма аларда республикада тәрбияләнгән спортчыларның бөтенләй диярлек булмавы эчне пошыра. Зур акчалар түләп шулкадәр уенчыны чит илләрдән, Россия төбәкләреннән чакыруның кирәге бармы икән?! Аларга түләнгән акчаны үз спортчыларыбызны әзерләүгә тотканда күпкә отышлырак булыр иде бит.

Республика җитәкчеләре Татарстан командаларының чыгышларын даими күзәтеп тора. Үзләре дә спорт белән шөгыльләнә. Президент Рөстәм Нургали улы Миңнеханов — автоспорт буенча атказанган спорт мастеры. Аның күп кенә ярышларда җиңеп чыкканы, призлы урыннарны яулаганы бар. 2000 елда берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә үткән «Дакар» раллиенда Р.Миңнеханов үзен пилот буларак та сынап карады.

Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев шахмат уйнарга, чаңгы шуарга, йөзәргә, ишкәкле көймәдә йөрергә, урманда ял итәргә ярата.

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшиннан: «Сез буш вакытыгызны ничек үткәрәсез?» — дип сорагач: «Минем бер иске машинам бар, шуны сүтәм дә, җыям, сүтәм дә, җыям», — дигән иде. Бер очрашу вакытында Рафаэль Хәкимов Фәрит Хәйрулла улының балык тотарга бик яратуын, әз генә буш вакыты булуга, кармакларын күтәреп, елгага йөгерүе турында сөйләгән иде.

Премьер-министр Илдар Халиков тау чаңгысына мөккибән. Ул һәр кышны зарыгып көтеп ала икән.

Шәһәр мэры Илсур Метшин Казанда үтә торган спорт чараларын карап барырга тырыша. Күптән түгел аны «Рубин» футбол клубы президенты итеп сайладылар. Сүз уңаеннан, Илсур Рәис улының күпчелек буш вакытын ипподромда уздыруын да әйтеп узу урынлы булыр. Ул ат спорты белән мавыга. Мэр улы катнашкан ярышларны да карамый калмый, билгеле.

Республикада спорт үсештә. Казанның 1000 еллыгына, Универсиадага, су спорты буенча дөнья чемпионатына әзерлек чорында моның өчен кирәкле база да булдырылды. Хәзер аны тулы файдалану әмәлен табасы бар. Спорт корылмалары шәһәрләрне һәм авылларны бизәп тору белән бергә тулы күләмдә халыкның сәламәтлеген ныгытуга, ялын оештыруга хезмәт итәргә тиеш. Республиканы бөтен дөньяга танытырлык спортчылар әзерләү өчен махсус уку йортлары да, сәләтле тренерлар да җитәрлек. Бары тик бар көчне бер максатка туплап, җигелеп тартырга кирәк. Ул чагында, иншаллаһ, нәтиҗәләр дә озак көттермәс. ■

Алтайдагы Ордос дигән җирдә табылган каеш каптыргычындагы көрәш сурәте. Б.э.к. III гасыр

БЕЗ – КӨРӘШЧЕ ХАЛЫК

Таулы Алтай яклары төрки халыкларның борынгы ватаны булып санала. Алтынчы гасырда, төгәлрәге, 552 елда, шул якларда оешып, 740 елга кадәр яшәгән, байтак халыкларга үз дәүләтчелекләрен оештырырга үрнәк булып торган күпмилләтле дәүләт – Төрки каганат нәкъ менә шунда булган. Моның шулай икәнлеген без бу гасырга кергәч, тагын бер тапкыр рәсми рәвештә белдердек.

...2006 елда, Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге рәсми делегация Алтайның Рәсәйгә кушылуына 250 ел тулуга багышланган тантаналарда катнашканда, Алтай республикасына керә торган җирдә Татарстан Республикасы исеменнән «Алтай-Евразиянең йөрәге» дип аталган истәлекле билге куелды. Әлеге корылманың нигезенә бездән соң килгән буыннар да укый алсын, бөтен дөнья белеп торсын, дип, инглиз, япон, корея, төрек, фарсы телләрендә һәм латин хәрефләре белән татарча болай дип язылды:

«Бу урында борынгы кабиләләр үзләренең дәүләт эшләрен хәл итү өчен җыела торган булганнар, биредә батырлар аргамакларын иярләп яуга киткән, биредә халык тормышындагы истәлекле вакыйгалар уңаеннан җыеннарга җыелып, ярышлар оештырылган. Төрки халыкларның цивилизациясе биредән башланган. Бездән соң килгән буын! Тамырларыңның кайдан икәнлеген онытма, бабаларыбызның мактаулы эшләре белән горурлан һәм үзеңнең исемеңне дә лаеклы йөрт!»

«Без көрәшче халык»
исемле китаптан ■

Көлке куа килә...

МИРЗАЛАР АВЫРУЫ

Фатих Әмирхан

З.Хәйруллин шаржы

Гайнетдин Гайнетдинович Сәкыймов, Мәскәүдән съезддан кайтып җитеп, йокы урынына яткач та, авыр бер уйланышка бирелде:

— Һә, так. Тәки теге шовинистлар җиңделәр бит. Имеш, татар-башкорт эшче-крестьяннарына үз җөмһүриятләре кирәк. Имеш тә, башкаларныкы шикелле үк аның да җөмһүрияткә хакы бар. Имеш тә, татар-башкорт эшчеләре бөтен эшләрен үз кулларына алырга хаклылар! Чорт возьми, иртәгә шул турыда губкомга доклад ясарга кирәк. Лев Абрамович ни әйтә инде, моны ишеткәч? Иван Иванович ни әйтә? Ә Мария Иосифовна? Ул бөтенләй иронически көлеп җибәрә инде. «Сез соң нинди көч белән җөмһүрият алып бармакчы буласыз?» — ди инде ул, билгеле. Позор! Бөтен губком алдында көлке. «Сез нинди шовинистлар соң?» — диләр инде. Әле бу көн бюрога әгъзалар кабул итү правасы бирелсен иде, дип просить иткәч тә, Матвей Иваныч, көлеп җибәреп: «Сез һаман иске националистлыгыгызны онытмыйсыз!» — дигән иде.

Гайнетдин Гайнетдиновичның уйлары бер-берсеннән авыр, бер-берсеннән кәефсез иде. Ул үзенең һәм бөтен татар коммунистларының губком алдында нинди уңгайсыз хәлдә калачакларын күзе белән күргән кебек күреп тора, Адам Петровичның: «Сез коммунистлар түгел, сез шовинистлар, больше ничего!» — диячәген колагы белән ишеткән шикелле ишетеп тора иде. Сәкыймов озак йоклый алмады, берничә мәртәбәләр үз-үзенә генә «позор, позор!» диенде, «тфү!» диде, төкеренде, төн уртасында гына йоклап китте. Ләкин тыныч йоклый алмады: әллә нинди шәүләләр аны мыскыл итеп көләләр, әллә нинди шүрәлеләр аңар яныйлар, әллә нинди өрәкләр аңар: «Ах, гололобый татарин!» — дип бармак селкиләр иде. Бераздан бу тынычсызлык бөтен бер рәвешкә, куркыныч бастырылуларга әйләнде. Гүяки бик күп кешеләр моның өстенә җикеренеп килгәннәр, имеш, алар моны бик тиргиләр, бик ачуланалар, имеш, алар арасыннан Лев Абрамыч белән Иван Ивановичның тиргәүләре бигрәк аерым-ачык ишетелә, имеш.

— Без сине соң Мәскәүгә татар-башкорт җөмһүрияте алып кайтырга

җибәрдекмени? Ах, контрреволюционер, ах, шовинист, ах, оятсыз! — диләр, имеш. Сәкыймов Иван Ивановичка җавап бирә, имеш:

— Товарищ барин, ә товарищ барин, ей-богу, мин гаепле түгел, мин әйтәм, мин барысын да әйтәм: татар эшче-крестьяннары үз җөмһүриятләрен теләмиләр, дидем. Татар ярлы халкы үз җирендә һәрбер учреждениеләрдә татарча да сөйләшүне бер дә теләмиләр, без русча белмәсәк тә, безнең белән русча гына сөйләшсәләр иде, дип требовать итәләр иде, дидем. Татар эшчесе властьның үз кулына күчүеннән бик курка, мин баринсыз тора алмыйм, дип әйтә, дидем. Татар эшче-крестьяны кулыннан чүп тә килми, ул бариннан башка харап булачак, дидем. Ей-богу, товарищ барин, мин верноподданный! Мин... 1918 ел маеннан халык комиссарлары тарафыннан җыелган Татар-башкорт җөмһүрияте комиссиясен татарлардан безнең иптәш берүзе демонстративно ташлап чыгып киткән иде...

Сәкыймовның бастырылуы озак сузылды. Йокысыннан уянгач та, ул саташудан айный алмады. Аңар доктор чакырдылар. Доктор карт коммунист икән. Сәкыймовның авыруын тиз таныды:

— Бу авыруны «лакейлар тифы» дип атыйлар, әүвәл заманда бу авыру белән татар мирзалары гына авырый иде; хәзер простой халык арасына да кергән икән. Шулкадәресе бар: әүвәл заманда мондый авыру белән авырган мирзалар «ваше превосходительство» дип саташалар иде, хәзерге заман халкы «товарищ барин» дип саташалар икән. Авыруны татар һәм башкорт ярлылары һавасында озак йөртергә кирәк, — диде.

Авыру һаман саташа иде: «Товарищ барин, барин товарищ, зделай милость...»

ДУСЛАРЧА ШАЯРУЛАР

....

Шәүкәт Галиев

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВКӘ

Шактый бәхәсләр сәбәпчесе булган «Өч аршин җир» повесте «Дружба народов» журналында басылып, еллык бүләк алды.

Юкка йөрде кайберәүләр:
«Алай язма, болай яз!..»
«Өч аршин җир» өч карышка
Үстерде сине, Аяз!

И.Хантимеров шаржы

ИЛДАР ЮЗЕЕВКА

Авторның «Яшь наратлар» исемле яңа китабы чыкты, анда укучылар җылы каршылаган «Язылмаган поэма» да бар.

Кем генә поэма язмый,
Төшенәлми җаена...
Ә сиңа уңыш китерде
«Язылмаган поэма»!

Х.Әхмәтҗанов шаржы

Муса Җәлилгә кагылышлы мәзәкләр

Салих Баттал

БУРНАШ ЙОКЫСЫ

Муса Җәлилнең Мәскәүдәге фатирының ишеге беркайчан да бикле тормаган. Каләмдәшләре, дуслары хуҗа үзе өйдә юкта бүлмәгә кереп, чәй эчеп, сөйләшеп утыра торган булган, кирәк булса, йоклап та калалар икән.

Бер тапкыр Мәхмүт Максуд, Мансур Крыймов белән тагын берничә сәнгатькяр Муса Җәлилдән башка гына сөйләшеп утыра икән. Өй хуҗасы соң гына Фәтхи Бурнаш белән кайтып керә.

— Кайда булдың, Муса? — дип сорый кунаклар.

— Театрга бардым.

— Нәрсә карадың соң?

— Островскийның «Абзый йокысы» дигән спектаклен карарга барган идем дә, Бурнаш йокысын карап кайттым.

Юлдан арып килгән Бурнаш театрда йоклап утырган икән.

СИРӘК ОЧРЫЙ ТОРГАН РИЗЫК

Мәскәүдә яшәгән чакта Муса Җәлил, Мансур Крыймов, Салих Баттал, Мәхмүт Максуд бәйрәмнәрне бергә каршылый торган була. Шундый бер олы бәйрәм табынына һәркем бер оригиналь, көтелмәгән, сирәк очрый торган берәр әйбер куярга тиеш була. Әйбер табынга куелгач, иң каты көлү булса, шул җиңүче булып чыгачак, дигән шарт куела.

Килешенгән вакыт килеп җитә. Кемдер кабыклы бәрәңге чыгарып өстәлгә куя. Кемдер сирәк очрый торган шәраб тапкан. Кемдер әче бал алып килгән. Барысы да үзенчә тырышкан, булдырган. Муса Җәлил генә өйдә юк — үзе дә юк, әйберсе дә юк. Бераздан соң, ах-ух килеп, Муса кайтып керә.

— Көне буе эзләдем, ниһаять, таптым! — дип Җәлил өстәлгә саргаеп, кәкрәеп беткән бер кечкенә кыяр чыгарып куя.

Табын янындагылар дәррәү көлә башлый. Муса Җәлил беренче урынны ала.

КЫЗЫК СҮЗЛӘР МӘҖЛЕСЕ

Мәскәүдә яшәгәндә Муса Җәлил шундый кызык кичәләр оештыра торган була. Бу кичәләрдә язучылар берберсенә тәнкыйть сүзләре генә әйтергә, нинди дә булса көтелмәгән үткенлек күрсәтергә яки тузга язмаган берәр нәрсә уйлап чыгарырга тиеш икән.

Шундый мәҗлесләрнең берсенә Әхмәт Ерикәй белән Әхмәт Фәйзи дә килеп керә.

— Җә, беренче ярышта ике Әхмәтнең кайсы җиңәр икән? — дип кычкыра Муса Җәлил.

— Әлбәттә, мин! — ди Әхмәт Ерикәй.

Мәҗлес шаулап көлә һәм тузга язмаган сүз әйткәне өчен дип, Әхмәт Ерикәйгә беренче бүләкне бирәләр.

***(Рабит Батулланың** «Тузга язмаган хәлләр» китабыннан (1997) алынды.)* ■

Мирасворд

VI-XVII йөзләрдә төрки дәүләтләрдә идарәчелек билгесе

Бөек үзбәк шагыйре

Шәриф Камал хикәясе

Шәрык әдәбиятын-да лирик шигырьләр җыентыгы

Кавказ халыкла-рында шагыйрь-җырчы

Дра-матург Шаһи-морат …

… тәмләткеч

Рим мифология-сендә урман, тау, кырлар Алласы

Махсус эшкәртел-гән тире

Линней, Либкнехт

«Ике …» романы (Идрис Туктар)

Дунаев, Гаетбаев

Кизү, эпидемия

… Ширази (фарсы шагыйре)

Ирекле шигырь

Поляк (иск.)

Наис …

Кәрим Тинчурин драмасы

Гарәп поэзиясен-дә шигырь төзелеше

«Бәянел-хак», «Вакыт», «Әл-ислах»

Көчле давыл

Сугылган башак

… - гадәт

Фәхрел-ислам … (балалар язучысы)

Башкорт-стандагы район

VII-XI йөзләрдә Азиядә яшәгән төрки телле кабилә

Перу каласы

… Байҗиев (кыргыз әдибе)

Көньяк-Көнчы-гыш Азиядәге ил

Сынчы … Нигъмә-туллина

Әйткән сүз — аткан …

Гарәп әлифба-сында диакри-тик билге

Борынгы Идел

Сәхаб …

Патша армиясендә кавалерия солдаты

Аудару

Суга юл ачу

… Насыйри

… Акъегет-задә

… Гыйләҗев

Зарар

Сәгыйть Рәмиев шигыре

Диңгез балыгы

Рәис Габдулла төзеде.

1 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: Гата, нишан, да, «Нур», Сараи, граф, ямб, Азак, Геб, Крылов, туару, сада, утлык, ябу, казна, көбә, опера, Гарвард, калфак, Фоат, Бурнаш, оры, имана.

Өстән аска: Ганг, Күк, Урарту, таразы, тубал, фал, бо, комык, Гафури, Каракорым, «Ан», Насретдинов, таян, Буа, Апак, яр, «Ася», ре, Адамар, Барда, наиб.



Бертуган Бубыйларның йорты һәм кызлар мәдрәсәсе. Иж-Бубый авылы, 1908-1910 еллар

«Безнең мирас»

елъязмасы /февраль

• 400 ел элек (1616)

Күренекле төрки-татар шагыйре Аллаһияр Суфи (1616-1713) дөньяга килә.

• 235 ел элек (1781)

Вятка губернасы **Сарапул** өязенең (хәзер Татарстан Республикасының Әгерҗе районы) Иж-Бубый авылында Бубый мәдрәсәсе оештырыла.

• 120 ел элек (1896)

1 февральдә **Алабугада** Үзәк китапханә ачыла.

• 115 ел элек (1901)

23 февральдә күренекле химия галиме Гыйлем Хәйри улы Камай (1901-1970) дөньяга килә.

• 110 ел элек (1906)

21 февральдә **Оренбургта** татар телендә «Вакыт» (1906-1918) газетасы чыга башлый. Ул алтын прискалары хуҗалары бертуган Закир (Дәрдемәнд) һәм Шакир Рәмиевләр тарафыннан оештырыла һәм алар акчасы хисабына басыла. Газетаның баш мөхәррире Фатих Кәрими була.

• 95 ел элек (1921)

25 февральдә **Казанда** Көнчыгыш халыклары өчен Югары партия мәктәбе ачыла. Аның мөселман, мари һәм чуаш бүлекләре бар.

• 90 ел элек (1926)

25 февральдән 6 мартка кадәр **Баку** шәһәрендә Беренче тюркология корылтае эшли. Галимҗан Ибраһимов «Төрки телләрнең имлясы» дип аталган нотык белән чыгыш ясый.

• 70 ел элек (1946)

10 февральдә шагыйрь Әхмәт Ерикәй СССР Верховный Советына депутат итеп сайлана.

• 60 ел элек (1956)

1 февральдә **Уральск** (элекке Җаек) шәһәрендә хәзерге Почиталин урамындагы Габдулла Тукай торган 54 нче йортка мемориаль такта куела.

• 50 ел элек (1966)

Чиләбе каласында татар-башкорт көтепханәсе оештырылуга 60 ел тула. Бәйрәм тантанасында Татарстаннан язучы Атилла Расих катнаша.

• 25 ел элек (1991)

Пермь шәһәренең 1 нче китап кибетендә татар басмалары бүлеге ачыла. ■

Рушан Шәмсетдинов

Рушан Галәф улы Шәмсетдинов 1946 елның 25 ноябрендә башкалабыз Казанда дөньяга килә. Казан сәнгать училищесын (1966), Мәскәү полиграфия институтын (1981) тәмамлый.

Рушан Шәмсетдинов — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, халык рәссамы, күпсанлы премияләр лауреаты, Татарстанның һәм Россиянең Рәссамнар берлекләре әгъзасы. Ул графика, китап графикасы, дизайн һәм нәкыш жанрларында иҗат итә.

«Казан ханлыгы. Сөембикә һәм Үтәмешгәрәй Сафа Гәрәй төрбәсе янында». Киндер, майлы буяу. 2005



«Бату ханның Болгардагы җәйге йорты. XIII гасыр. Бату ханның өлкән хатыны Баракчин оныгы Улакчи белән». Кәгазь, акв., темп. 2005

«Шагыйрь Кол Гали. XIII гасыр». Кәгазь, акв., темп. 1996

АЛДАГЫ САНДА:

«... ЯЗМЫШТАН УЗМЫШ ЮК. АНЫ СӨЙМӘГӘН КЕШЕСЕНӘ БИРЕП, 1882 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕНДА ТУЙ ЯСЫЙЛАР. ШУЛ КӨННӘН БАШЛАП, КҮҢЕЛЕНЕҢ ИҢ ЕРАК ЧИТЕНДӘ ҖЕМЕЛДӘГӘН СОҢГЫ ӨМЕТ ЧАТКЫСЫ ДА СҮНӘ. ТОРМЫШКА ОЗАТЫЛГАЧ, ГАЗИЗӘ ӨЧЕН ӨЗЛЕКСЕЗ КАРА КӨННӘР БАШЛАНА...»
Җ.АЛМАЗ. ШАГЫЙРӘ ГАЗИЗӘ БАҺАВЕТДИН КЫЗЫ СӘМИДОВА.

ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВ: «МИНЕМ ӨЧЕН БУ ҖЫЕЛЫШ ЯҢАЛЫК ТҮГЕЛ. РАЗГРОМ ЯСАЯЧАКЛАРЫН БЕЛДЕМ ҺӘМ КУРЫКМАДЫМ. КАЙБЕР ИПТӘШЛӘР СӨЙЛӘГӘНДӘ МИН ОЯЛЫП УТЫРДЫМ – АЛАРНЫҢ ӘДӘБИЯТНЫ ПРИМИТИВНЫЙ АҢЛАВЫ ӨЧЕН ОЯЛДЫМ».
«АК ЧӘЧӘКЛӘР» – 50 ЕЛ ЭЛЕК.

«ТАТАРЛАРНЫҢ КАЗАКЪЛАР БЕЛӘН БОРЫНГЫ УРТАК ТАМЫРЛАРЫ БУЛУЫ ТУРЫНДА ТАТАРСТАН ҖИРЛЕГЕНДӘГЕ КАЗАКЪ ЫРУЫ ТОПОНИМНАРЫ ДӘЛИЛЛИ».
М.КӘРИМОВ. «ЧУРА БАТЫР»ДАСТАНЫ.

Индекс:
Татарстанда – 54132
Россиядә – 70275
www.beznenmiras.ru

4 612750 670172

«Безнең мирас» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, Г.Тукай музеендагы киосктан (Г.Тукай ур., 74) , «ТАТМЕДИА» АҖ бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), Казан метросы киоскларыннан сатып алырга мөмкин.

Безнең мирас №02 / 2016